Безнең МИРАС

НАШЕ НАСЛЕДИЕ

03

март 2019

ISSN:2500-011X

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

ЛОТФУЛЛА ФӘТТАХОВ «ӘНИ КҮРМӘГӘНДӘ».

Фотолар shaimiev.tatarstan.ru сайтыннан алынды

«МӘДӘНИ МИРАС» ТАНТАНАСЫ

2 февраль көнне «Пирамида» мәдәни күңел ачу үзәгендә «Мәдәни мирас: Свияжск утрау-шәһәре һәм Борынгы Болгар» комплекслы проектының йомгаклау чарасы узды. Анда Россия Федерациясе мәдәният министры Владимир Мединский, Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев катнашты.

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.

Дәрдемәнд

Безнең МИРАС 12 +

03 (303)

март 2019

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

60

74 ӘМИРХАН АГА САГЫНДЫРА.
Әгъзам Фәйзрахманов

100 ИҢНӘРГӘ КАНАТ КУЙГАН ЕЛЛАР...

ЭЧТӘЛЕК

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 **Әнвәр Давыдов**

ТАРИХИ МИРАС

4 **Төрки халыкларның гомуми тарихы.** *Х.Габәши*
9 **Куян авылы тарихы.** *Ф.Мусин*
14 **Тәрҗеман-әл-Әнҗерәи нәселе.** *А.Нәҗми*
18 **Татарча язу машиналары**
21 **Ризаэддин Фәхреддин гыйбарәләре**
22 **Саралы мең ыруы татарлары.** *Р.Мәрданов*
30 **Милли күтәрелеш җимеше иде...** *Т.Галиуллин*
34 **Дон казаклары һәм татарлар.** *И.Газизуллин*

ТАТАР ГАМЕ

40 **Казанны данлаучы шәхес.** *Ә.Фәйзрахманов*
44 **Буа театры артисты Ильфир Солтанов: «Безнең эш урыны – дөнья»**

ДИНИ МИРАС

48 **Ислам дөньясы.** *Габдерәшит Ибраһимов*

ӘДӘБИ МИРАС

54 **Вак хикәяләр.** *Дәрдемәнд*
56 **Мәшһүр иремнең беренче хатыны**
60 **Җылынды синең учакта, җылынды ничә буын!..** *Э.Закирова*
68 **Госман Садә шигырьләре**
70 **Сөембикә.** *О.Иванова*

ХӘТЕР САНДЫГЫ

74 **Әмирхан ага сагындыра.** *Ә.Фәйзрахманов*
78 **«Зур эшләргә көч, кабилият, мәхәббәт сизелә үзегездә»**
82 **Әфган дастаны.** *М.Закир*
87 **Җырлап китте Мәңгелеккә.** *Г.Гомәр*

90 **Милләтебезнең горурлыгы.** *З.Хәйруллин*
94 **Истә, һаман да истә!**

СӘНГАТИ МИРАС

96 **Борынгы татар милли музыка уен кораллары.** *Р.Гыйләҗев*
100 **Иңнәргә канат куйган еллар…** *А.Хәкимова*

ТЕЛ КҮРКЕ – СҮЗ

108 **Сүзләр иленә сәяхәт (Лингвистик хикәятләр)** *Г.Рәхим*
111 **Яхшы хатын – ир күрке.** *Ф.Кутлу*

ХӘТЕР САГЫНДА

112 **Татарстан Республикасының Милли китапханәсе**
114 **Иске Казанда – саклану һәм һөҗүм итү кораллары**

116 **«Безнең мирас» хәбәрләре**
118 **Мирасворд**
119 **«Безнең мирас» елъязмасы.** *Март*

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары
Фирдәвес Зарифуллин
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Ирада Әюпова
(ТРның мәдәният министры)
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Айрат Зарипов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Андрей Кузьмин
(«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Васил Шәйхразиев
(ТР премьер-министры урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)
Лотфулла Шәфигуллин
(«ТАТТЕЛЕКОМ» АҖ генераль директоры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Альберт Борһанов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Данил Салихов
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов
Ирек Шәрипов

Җаваплы мөхәррир
Ленар Гобәйдуллин
89196911406

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-93)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-92)

Бүлек мөхәррире
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-92)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Безнең мирас» (Наше наследие)
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

Заказ №О-520. Тираж – 1550 данә. Формат 70х108 1/16.
Басарга кул куелды: 26.02.2019.
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми. Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм Татарстан Милли музееннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан, Кукмара туган якны өйрәнү музееннан алынган фотосурәтләр, җиде томлык «Татар тарихы»ннан рәсемнәр файдаланылды. Тышлыктагы Ә.Тумашев рәсемнәре ТР Дәүләт сәнгать музее тупланмасыннан алынып бирелде.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Тышлыкның 1 нче битендә – **«Әни күрмәгәндә»**. 1977. ***Лотфулла Фәттахов рәсеме***

Безнең мирас №3 март 2019

Әнвәр Давыдов

(21 март, 2019 – 23 июнь, 1968)

Мин туйдырдым инде сезне…

Мин туйдырдым инде сезне,
Кырлар, мактап.
Башка хакта язу иде
Бүген максат.

Ләкин, ачык тәрәзәмә
Җилләр исеп,
Китерделәр куян куган
Арыш исен.

Минем кырга мәхәббәтем
Күптән инде:
Миңа ул чак тугыз тулып
Үткән иде.

Һәм беренче тракторны
Урап алып,
Кырга чыктык без малайлар,
Чыкты халык.

Ызаннарның әремнәрен
Сытып, басып,
Без нәниләр карашына
Зур юл ачып,

Корыч батыр күкрәп узды!
Менә шунда
Киңәеп киткәндәй булды
Безгә дөнья.

Безнең юлның башы шунда
Булды кебек.
Шуннан омтылдык без күзне
Алга текәп...

Әнвәр Мортаза улы Давыдов Куйбышев өлкәсендәге (хәзерге Самара) Камышлы авылында туа. ■

Безнең мирас №3 март 2019

ТӨРКИ ХАЛЫКЛАРНЫҢ ГОМУМИ ТАРИХЫ

Хәсәнгата Габәши

БОРЫНГЫ ЗАМАН ИЛӘ ХӘЗЕРГЕ ЗАМАН АРАСЫНДА АЕРМА

Борынгы заманнарда юллар бик аз, йөрүләр бик мөшкел вә бик хәвефле иде. Бу сәбәптән, халыкларда бере икенчесе илә танышу вә аралашу аз вә бик читен иде. Язучылар да дөньяда бик сирәк, китаплар да күп түгел иде. Шул сәбәптән, халыкның белем вә мәгълүматлары күп вә киң түгел иде. Кирәк, телдән сөйләнмешләр вә кирәк, китапларга язылмышлар сыналмый вә тәҗрибә ителми, шул көе кабул ителер иде. Тәҗрибә итәргә вә сынарга ният итсәләр дә, юлы булмаганлыктан, шул көе калыр иде. Дөнья яратылышы хакында, дөньяда, медицинада, тарихта бик күп буш уй, хорафатлар хакыйкать арасында йөрделәр. Китаптан-китапка, тедән-телгә күчерелделәр. Тарих фәнендә һәр кавем үз ыругын Адәм галәйһиссәламгә илтеп ялгау тиеш кеби санап, исемнәр тезеп китәрләр вә Адәм г.с.гә илтеп җиткерерләр иде. Вә йә үзләренә аерым бер привилегия ясау кеби максат йә сәясәт өчен силсиләләр төзелер иде. Гәрчә пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.в.: «Нәселләрен бер кавемгә ялгаучылар – ялганчылар», – димештер. Әмма ислам тарихчылары да, һаман башкалардан күчереп, исемнәр тезмәктән котылмадылар.

Дин вә шәригать китапларында да, борынгылар яздыкларның дөреслеген күрсәтердәй дәлилләр булмаганлыгы кеби, ялгышлыкларны да күрсәтердәй күп эш юк иде. Аның өчен дин вә шәригать китаплары («Тәүрат»ның беренче кисәгеннән кала) тарих китабы түгел иде. Бәлки Адәм балаларының дин вә дөньяларны төзек итмәккә файда итәрдәй вәгазь, әхлак, хөкем, мисал, гыйбрәт вә күчергеч булсын өчен ара-тирә бәгъзе хәбәрләрне өйрәтер китаплар иде. Бу сәбәптән язучылар вә төзүчеләрнең язганнары вә күрсәтмеш хәлләре хакыйкатьме, хыялмы – янә беленми калыр иде.

Заманыбыз исә һөнәр вә мәгърифәт заманы булганлыктан, юллар ачылды, йөрүләр җиңеләйде, барышу, килешү, аралашу күбәйде. Халыклар гыйлем вә мәгърифәткә теш-тырнагы илә ябыштылар. Яше, карты белү вә табу сәүдәсенә төштеләр. Мәдәнияттә алгарак басканнары, теоретик фәннәрдән бигрәк, практик фәннәргә әһәмият бирделәр.

Һәр эшнең хакыйкатен дөрес танырга омтылу илә бергә, тарих вә вакыйгалар бабында да кавемнәр әүвәл үзләрен, ата вә бабаларын дөрес тануга, соңрак бере икенчесен белүгә артык һәвәс иттеләр. Дөньядагы кавемнәрнең телләрен белергә, язуларын укырга, асәрләрен (калдырган ядкәрләрен. – ***Ред.***) үз күзләре белән күрергә, мәгыйшәт

Дәвамы. Башы журналның 2019 елгы 2 нче санында. Текст берникадәр хәзерге телгә якынайтылып бирелә.

вә тарихларын өйрәнергә тырыштылар. Моның өчен бик читен вә мәшәкатьле сәфәрләр вә сәяхәтләр кылдылар. Иске шәһәр хәрабәләре вә каберләр казыдылар, гареб телләре шәрыкта укылдыгы кеби, шәрык телләре дә гаребтә өйрәнелде вә язулары укылды. Афина китапханәләрендә тузан капламыш юнан философлары әсәрләре шәрыкта укылдыгы кеби, гаребтә мөселманнарның нәфис әсәрләре Ауропа китапханәләрендә табылып укылды вә төрле телләргә тәрҗемә ителеп, нәшер ителде. Һинд вә кытай иске китаплары да укылды вә тикшерелде. Моннан тыш гыйлем һәвәслеләрнең тырышлыгы аркасында Мисыр һироглифлары, бабылның кадак рәвешле язулары (Вавилон чөй язуы. – ***Ред.***), Скандинавия рунилары, хәтта Күлтәгин ташларындагы, Енисей тирәләрендәге иң иске төрек язулары укылды. Галимнәре укыганнарын, белгәннәрен сыный вә чагыштыра башладылар. Күп эшнең өстеннән пәрдә ачылды, караңгы урыннары яктырды. Бар хисап ителгән эшләр юк булып чыктыгы кеби, юк хисап ителмеш эшләр дә бар булып табылды. Бер булачак эшләр башка-башка табылдыгы кеби, күп башка-башка күрсәтелмеш эшләр бер булып чыкты. Голәмә бу елда иҗтиһадларны туктатмый, бәлки һаман арттыра баралар. Бу сәбәптән, дөнья вә аның барышы, Адәм угыллары вә аларның әхвәле хакында фикер вә нәзарлар көн саен тугрылашадыр вә алардан алынмыш тәҗрибә вә гыйбрәтләр дә бигрәк тә ышанычлыланадыр.

VI гасырда славяннар һәм аларның күршеләренең урнашу картасы. Б.А.Рыбаков буенча

Безләр дә, голәмәнең бу тырышлыгы аркасында, үзләрен күрмәгән, телләрен белмәгән вә язуларын танымаган кавемнәрнең тарихларын вә тәрҗемәи хәлләрен укырбыз, әсәрләрен вә фикерләрен тамаша итеп ләззәтләнербез. Хәлләрен, әүвәлләрен, ахырларын белеп, тәҗрибә вә гыйбрәт алырбыз. Болар аркасында үз тарихыбызны дәрес өйрәнергә дә байтак куәт табарбыз, кем углы – кемнәр идекебезне тугры белербез. Ата вә бабаларыбызны ачык таныйрбыз. Алар хакында шәрык вә гареб тарихчыларының язганнарын сүз көче аркылы сөзеп, хыялларыннан хакыйкатьләрен аерып ала алырбыз. Башларыннан кичмеш хәлләрен, тотмыш юлларын, кылмыш эшләрен, калдырмыш асәләрен вә болардан үзләре йә нәсел вә балалары файда, йә зарар күрдекләрен дикъкать вә игътибар илә өйрәнербез. Безләрне күзе йомык хисап итеп, төрле ниятләр катыштырып, үзебезне үзебезгә аңлатучыларга вә йә үзләренең саз чалуларына *(кубызларына)*, биюләренә биетергә теләүчеләргә үз күзебезне ачарбыз да үз күзебез илә үзебезне күрербез.

Болардан безгә ышанычлы бер тәҗрибә вә аң хасил булыр ки, без алар илә алдагы гомеребездә сәламәтлек вә сәгадәт юлын ачык күрербез. Үзебез вә нәсел, вә

балаларыбызның җиңелүеннән саклана алырбыз, аягыбыз таеп егылып, башкалар аяк астында изелүдән, иншаллаһ, котылырбыз.

Ишетегез! «Бәсыйрәт»[1] сахибе сезләргә ошбу бәсыйрәтне хасил кылдыру (аң, акылны булдыру. – ***Ред.***) өчен бу китапны язадыр.

АДӘМ УГЫЛЛАРЫНЫҢ ТӨРЛЕ ЫРУГЛАРГА БҮЛЕНҮЕ

Шәригать әһелләре күрсәтүе буенча, Җир йөзендәге барча кешеләр хәзрәти Адәм г.с. нәселеннән килмештер. Әмма хәзерге заманыбызда яшәгән халыклар хәзрәти Нух г.с.нең Хам, Сам, Яфас исемле өч углы нәселеннән таралмышлардыр. Африка, Һинд, Америка кыйтгаларында тереклек итмәктә булган кара төстәге вәхши халыклар Хам ыругына нисбәт ителенәләр. Болар кара төсле халыклар һәм нигр дип аталалар[2].

Мисырилар, асурилар, килданилар, финикиялеләр, сириянилар, гыйбранилар (яһүдиләр), гарәпләр, әрмәниләр үз тарихларын Сам нәселенә нисбәт итәләр. Болар самилар дип әйтеләләр[3].

Яфәс улы ике олуг фиркагә аерылмыштыр: бер төркеме – арийя кавеме – ариания, айрания, ирания вә икенче төркеме Турания – Төркия – Монголия аталмышлардыр. Боларны, төсләренә карап, әүвәлгеләрен, ак кавемнәр, соңгыларын сары кавемнәр, дип атамышлардыр[4].

Һиндлеләр, иранилар, әфганилар, юнанилар, арнаудлар, латиннар, французлар, инглизләр, немецләр, славяннар арийя кавеменнән яки ак кавемнәрдәндер[5].

Кытайлар, һинд вә аннамнар (вьетнаманар. – ***Ред.***), японнар, финнәр, төрек ыруглары, монголлар, татарлар – төрки кавемнәр яки сары кавемнәрдәндер[6].

АРИАНИЯ КАВЕМЕНЕҢ ӘҮВӘЛГЕ УРЫНЫ

Юнан тарихчылары язуынча, арианилар кавеме әүвәлдә Бактрия дип аталган җирләрдә, Бәлех вә Һират тарафларында тереклек итмешләрдер. Соңрак, икегә бүленеп, бер төркеме көньяк-көнчыгыш тарафына – Һиндкә, икенче төркеме хәзерге Иран кыйтгасына сачелмешләрдер. Соңрак гареб вә төньяк-көнбатыш тарафларына – Ауропага һиҗрәт итмешләрдер.

АРИЛАРНЫҢ МӘГЫЙШӘТ РӘВЕШЛӘРЕ

Арианилар башка кавемнәрдән элегрәк күчмә тереклектән утырма (мәдәни) тереклеккә авышмышлардыр. Иген игәргә, юнмаган таштан өй бина итәрә өйрәнеп, авылларда вә шәһәрләрдә тереклек итә башламышлардыр. Болар, заманның күп үтүе илә үрчеп күбәйдекләреннән, әүвәлге урыннарына сыймадылар. Иген игәргә яраклы урын эзләп, кавем-кавем булып, күчеп киттеләр, күчмә тереклек итмәктә булган кавемнәр илә низаглашып, аларны җиңеп, урыннарына җирләшерләр иде. Болар бер вакытта гына аерылмый, бәлки, төрле заманнарда аерылмышлардыр. Вә бу аерылышлар арасында йөзләр илә еллар узып китмештер.

АРИЛАРНЫҢ ТЕЛЛӘРЕ ТӨРЛЕЛӘНҮЕ

Болар, ерак җирләргә китмәстән элек, Урта Азиянең вә Иранның һәр тарафына җәелеп, Урта диңгездән Тигр вә Ефрат суларына кадәр урыннарга җирләштеләр. Бер-

---

[1] Авторның басылып чыккан әсәрләреннән берседер.
[2] Хам нәселе экватор районына һәм берникадәр көньяккарак, көнчыгыш һәм көнбатыш юнәлештә урнашкан.
[3] Самилар хамиларның төньяк тарафына, шәрыктан – гаребкә вә көньяк тарафына сачелмешләрдер.
[4] Рус тарих вә этнографияләрендә «белая раса» вә «желтая раса» дип аталыналар.
[5] Самилардан төньякка, көньяк-көнчыгышта, гареб вә төньяк-көнбатышта арилар сачелмешләрдер.
[6] Ариларның төньягында, шәрык вә гареб тарафына вә төньяк диңгезләренә кадәр «туранилар» сачелмешләрдер.

берләреннән ерак киткән саен, заманнар да күп узар иде. Бу сәбәптән телләрендә дә күп аерма вә башкалык була килмештер. Башка урыннардан күчеп киттекләреннән, телләрендә дә башкалык янә артыр иде. Бу халыклар һичбере үз ихтыярлары илә күчеп китми, бәлки (туран кавеме кебек) артларындагы көчлерәкләренең куулары вә интектерүләре сәбәбеннән күчәрләр иде. Һәр күчкән урыннарында күп гасырлар утырганнар булырга кирәк. Бәгъзе урыннарда болардан аз-аз аерылып калган халыклар артларыннан килмеш икенче кавемнәрнең эчендә байтак заманга кадәр яшәрләр иде[7].

АРИЯ КАВЕМЕНЕҢ ҺИНДКА ВӘ ИРАНГА МӨҺАҖИРИЯТЕ

Ария кавеменнән иң әүвәл бер төркем көньяк-шәрык тарафына – Һиндка китеп, күп вакыт ария исемен сакламышлардыр. Бу көнге һиндулар, чөнкәнәләр (индуслар. – ***Ред.***) шулардандыр. Вә бер төркеме көньяк-көнбатыш тарафына китеп, иран халкы аталмыштыр. Бу көнге иранилар (фарсылар), әфганилар, көрдләр, әрмәннәр шулардандыр.

АРИЯ КАВЕМЕНЕҢ АРУПАГА КҮЧҮЕ

Соңрак ошбу ария кавеменнән төрле вакытта төркем-төркем халык, Кавказ тауларыннан вә Босфор[8] бугазыннан күчеп, Ауропага килеп, төрле тарафына җирләштеләр. Ария кавеменнән Ауропага күчмешләре ошбу түбәндәгеләр булынмышлардыр:

1) Пәләсеҗләр төркеме – борынгы илларианнар, хәзерге арнаудлар ошбу төркемнәндерләр. Арнаудлар үзләрен «эшкиптар» дип атыйлар һәм иң иске кавемнән булуларын хисап итәләр[9].

2) Юнан төркеме – борынгы пиласгыйлар, илланнар, юнаннар, греклар, румнар ошбу төркемнән[10].

3) Латин төркеме – итальяннар, румыниялеләр, французлар, бельгиялеләр, испаннар, португаллар ошбу төркемгә хисап кылыныр.

4) Кельт яки сельт төркеме – борынгы гал кельтлары, кимирияләр, Британия, Ирландия, Голланд халыклары – бу төркемнән.

5) Тәфтен (тевтон. – ***Ред.***) төркеме яки герман кавеме – борынгы гот яки готфлар, Германия, Австрия немецләре, Балтыйк буендагы, Русия эчендәге немецләр, борынгы Скандинавия халкы (норманнар, варяглар), даниялеләр, шведлар, норвежецлар, исландиялеләр – бу төркемнән.

6) Слав яки славян төркеме – борынгы прусслар, поляклар (ләһләр), литваннар, чехлар, сербияләр, черногорецлар, хорватлар, словаклар, славяннар, малоруслар, белыйруслар, Дунай болгарилары һәм великий руслар[11] бу төркемнән саналмышлардыр. Ләкин бу соңгы икесенә, славян димәктән, бигрәк славянланмыш кавемнәр димәк, тугрырак чыгар. Чөнки Дунай болгарилары турания кавеме вә төрек төркеме булган Кама болгарилары илә бер ыруг кавемнәр иде. Азак вә Кара диңгез тирәсеннән күчеп

[7] Кавказда аз-аз вә бер-берләреннән бөтенләй башка тел илә сөйләшмәктә булган кавемнәр ошбу Нух кавемнәре булулары гөман ителенәдер. Тел төрлеләнүе хакында исраилият (яһүдиләр. – ***Ред.***) башка сәбәп (Бабыл вакыйгасын) күрсәтсәләр дә, галимнәр аны кабул кылмадылар.

[8] Истанбул, Искәндәр бугазы.

[9] Госманлылар дәүләтенең көнбатышында тереклек итәләр. Мөселманнары вә азрак нәсарилар бардыр. Сугышчан батыр вә гайрәтле халыклардыр. Милли хисләре дини хисләреннән өстен кавемнәрдер. Ягъни дин вә мәзһәп башкалыгына игътибар итми, барча арнауд бере-берен карендәш хисап итәләр.

[10] Бабыл (вавилонлы), финикия, мисырлылардан соң Ауропа кавемннән иң элек гыйлем вә мәгърифәт, һөнәр вә сәнәгать илә үзләрен нурландырмыш, бу көнгә кадәр һәр кавемгә остаз булып, исемнәрен калдырмыш булган Әфләтүн, Сократ, Аристу, Җалинус вә гайреләрне җитештермеш кавемнәрдер.

[11] Славяннарны скит төркеменнән санамак скитләрнең кем идекләре беленмәгән заманнан калмыш хатадыр. Бу хатаны соңгы заман тикшерүчеләре төзәтте.

1000 елда Европа картасы. Фрагмент

китеп, Днестр вә Дунай елгалары тирәсендә тереклек[12] кылмышлар иде. Соңрак 679 елда Мизия исемендә славяннар тереклек итмәктә булган җирне сугышып алып, анда куәтле Болгар хөкүмәте төзеделәр. Ләкин өстен кавем була торып та, үз телләрен вә гореф-гадәтләрен саклый алмый, кул асларындагы славян кавеменең тел вә гореф-гадәтләрен алып славянлаштылар.

Бу көн великий рус аталмакта булганнары әүвәлдә гот вә славян вә чуд ыруг-кавемнәрдән хасил булмыш иде. Соңыннан да великий рус кавеменә немец, фин вә гайре кавемнәр, аеруча, төрек вә татар, вә монгол кавемнәре бик күп катышып[13], славянлашмышлардыр. Фәкать фамилияләренең күбесендә бу көнгә кадәр төрки исемнәр вә төркилек хатирәләре сакланмактадыр.

Ариялеләрнең барчасына ария кавеме, кавказ җенесе, һинд вә аурупа кавеме, һинд-герман кавеме диелмәктәдер[14].

Дәвамы бар ■

[12] Кара диңгезнең гареб вә төньяк тарафыннан коя торган мәшһүр елгалардыр. Дунай юнанча – «Истәр», төрекчә – «Туна», Днестр – «Турлә» аталмышлардыр.

[13] Яһүд вә рум, французлардан да кушылмышлар. Әмма иң күп кушылганы финнәр илә төрек-татар-монгол кавемнәредер. Шуның өчен, Шәмсетдин Сами бәк: «Руслар-татар, фин һәм башка туран кавемнәренең славянлашмышларыннан башка бер эш түгелдер», – димеш. «Камус әл-әгләм»дә әйтелгәнчә, великий рус кавеме канына күп микъдарда төрек кавеме каны да катышмыштыр.

[14] Китаптан асыл максат ария квемен бәян кылу булмаганлыктан, ошбу кадәр мәгълүматны җитәчәк күрдем.

ҖӘЛИЛЧЕЛӘР АВЫЛЫ

КУЯН АВЫЛЫ ТАРИХЫ

Фәнил Мусин*

Илләт-Кукмара – хәзерге Куян һәм Кугунур – Мазарбаш авыллары. Уржум өязе картасыннан фрагмент

Куян авылы XVIII гасыр башы-XIX гасырда Вятка губернасының Бәрәңге, соңрак Төрек волосте составына кергән. Куян халкы 1920 елдан Мари Автономияле өлкәсенең Сернур һәм Мари-Төрек кантоннарына карый. 1931 елның апреленнән – яңа оешкан Татар, 1932 елның июленнән исеме Бәрәңге дип үзгәртелгән район составында яши башлый.

Тагын да әүвәлгерәк тарихка мөрәҗәгать итсәк, Илләт-Кукмара (хәзерге Куян авылы була инде) Казан ханлыгының Алат даругасында волость үзәге булган. Шуңа мөнәсәбәтле, һич икеләнмичә, авылга 500 ел (ә бәлки аннан да күбрәктер), дип әйтә алабыз. Аңа Куян исеме шактый соңрак, 1795 елда гына тагыла.

Авылның тарихын архив документлары нигезендә 1699 елдан өйрәнергә мөмкин. Безгә мәгълүм иң әүвәлге чыганакка («Доимочная книга») мөрәҗәгать итсәк, Казан өязенең Алат даругасындагы Илләт-Кукмара авылында ясаклы 17 мари гаиләсе яшәгәнен беләбез. Дөрестән дә, бабаларыбызның: «Бу җирләрдә элек марилар

* Фәнил Мусин – Мари Иле Республикасының Бәрәңге районында чыга торган «Безнең тормыш» газетасының баш мөхәррире, Бәрәңге районының Тарихчы-архивистлар, төбәкне өйрәнүчеләр җәмгыяте рәисе.



II «Ревизские сказки»дан бер бит. Анда Кормаш Курманаев турында мәгълүмат теркәлгән. 1762 ел

яшәгән», – дигәне юк сүз түгел. Илләт-Кукмарада 1725 елга кадәр фәкать марилар гына яши. Беренче (1719) һәм икенче (1745) халык санын алу арасында ясаклы чирмешләр яши торган Илләт-Кукмарада ир-атлар саны (ир балаларны да кертеп) 85кә кими. Шулардан 36сы вафат була, 9ы рекрутлыка алына, 35е, йөзбашы Илчебай Апачевка хезмәткә күчү сәбәпле, туган авылын калдырып китә. 1725 елда 25 кеше – Уланур, 1724 елда 9 кеше – Усола авылларына, ә бер кеше Чекманур пүчинкәсенә нигез сала. 1737 елда Яшморза Ишполдин атлы чирмеш егетенең Азов крепостена да җибәрелүен искәртергә кирәк.

Кеше саны шактый гына кимегән Илләт-Кукмарага нәкъ менә шул елларда күршедәге Кукмарадан (хәзер Тоштоял) татарлар күпләп күченә башлый. Иң әүвәл Кадыйрмәмәт Әлмәмәт (1684 елда туган), Айбулат Байкин (1679), Мәмәт Әлмәмәт (1695), Бәктеки Байкин (1665) гаиләләре килеп төпләнә. 1725-1745 еллар арасында җәмгысе 24 ир-ат (әлбәттә, күбесе гаиләле) Илләт-Кукмарага күченә. Шуны да искәртү урынлы булыр: бу елларда Кукмара татар авылы дип аталса да, анда марилар да яши. Авылдан төрле тарафка 50 ир-ат күчеп китүе мәгълүм. Архив материалларыннан татар һәм мари халкының актив хәрәкәтен күзәтеп, Кукмараның ни өчен Иске авыл (маричага тәрҗемәдә – Тоштоял) дип аталганы җиңел аңлашыла.

Ә инде риваятьләргә ышансак, тарихның башы бүтәнчәрәк. Без күреп белгән өлкәннәр сөйләвенә караганда (аларга, әлбәттә, әби-бабалары сөйләп калдырган), Куян авылы халкы хәзерге Татарстан Республикасының Арча районындагы Хәсәншәех авылыннан күчеп килгән. Тарихи документлардан Куянда яшәүчеләрнең Кукмараны (хәзерге Тоштоял) калдырып китүен белүебез сәбәпле, бу риваятьнең нәкъ менә шул авылга мөнәсәбәтле икәнен аңларга мөмкин.

1740 елның 11 сентябрендә патшабикә Анна Иоановна Россия халыкларын көчләп чукындыру турындагы фәрман чыгара. Бу елларга нисбәтле чыганакта йөзбашы Алчыбай Апачев карамагында булган Илләт-Кукмара авылында 15 хуҗалык һәм бер мәчет барлыгы, яңа чукынганнарның бөтенләй яшәмәве теркәлгән. Шулай итеп, 1734 елда төзелгән мәчет җимертелә.

Өченче халык санын алу мәгълүматларына караганда, 1762 елда Илләт-Кукмарада 70 кеше яши. Алар арасында Кормашевларның борынгы бабасы – 1712 елда туган



Бикчәнтәй һәм Мурас Кормашевлар турындагы мәгълүмат. «Ревизские сказки», 1795 ел

Кормаш Курманаев та бар. Ул заманы өчен шактый дәрәҗәле кеше булган, авылның старостасы вазыйфасын башкарган. Ә аның әтисе Курманай Килмәмәтев (1694-1755), авылның башка кешеләре кебек үк, Тоштоялдан (Кукмара) күчеп килгән.

1795 елда Куянда 190 кеше яши. Бу елгы документлардан авыл янында Ляж-мучашка дип аталган яңа пүчинкә барлыкка килгәнен дә беләбез. 1807 елда аңа авылның яшь гаиләләре килеп нигез салган. Мөгаен, еллар узып, авыл зурайганнан соң, пүчинкә Куянның көнбатыш өлеше составына кереп калгандыр.

Уржум өязенең XIX гасыр башында төзелгән Генераль ызанлау планыннан күренгәнчә, куянлылар яшәгән җир мәйданы, хәзерге мәчеттән башлап, авылны икегә бүлә торган буага кадәр сузылган. 1811 елда Куянда 41 хуҗалык булып, аларда 113 ир-ат яши. Шулар арасында бертуган Бикчәнтәй һәм Мурас Кормашевлар да бар.

Кормашевлар нәселе шактый гына мал-мөлкәт тупларга да өлгерә. Алга китеп булса да шуны әйтергә кирәк: XIX гасыр урталарында сәнәгатьче Мәмәтовларның Юшто-Памаш (Студеный ключ) пүчинкәсендәге кәгазь фабрикасы һәм тегермәне алар кулына күчә. Моннан тыш, Кормашевлар Иллэт елгасы буендагы 21 дисәтинә җиргә һәм ике тегермәнгә дә хуҗа була.

Ляж елгасының сул ярында татар һәм марилар яши торган Кошпаев пүчинкәсе булган. Соңрак, зураеп, Татар Кошпае авылы дип аталса да, еллар узу белән Куян составына кереп, «Терлекчеләр урамы» дип йөртелә башлый. Ляж елгасының Ноляга койган урынында Мәмәтовларның комач фабрикасы пүчинкәсе булган. Бу пүчинкә, кеше саны арту сәбәпле, Прикум-Фабрика авылы дип атала башласа да, вакытлар узгач, Куян авылы эченә кереп, «Яшел урам» исемен ала. 1816 елда менә шушы пүчинкәдә Мөхәммәдәмин Монасыйпов-Мәмәтов идарә иткән комач фабрикасы гөрләп эшли дә инде.

Шул елның VII «Ревизские сказки» материалларына караганда, Куянда 41 хуҗалык булып, 111 ир-ат, 126 хатын-кыз яши. 1834 елгы мәгълүматка караганда, авылда 351 кеше гомер итә, ә хуҗалык саны элеккечә кала. 1825 елда 85 ел хезмәт иткән мәчет, шактый тузу сәбәпле сүтелеп, аның урынына өр-яңасын салып куялар. Мәчет янында ук ибтидаи мәктәп тә оештырыла, анда 10 ир һәм 15 кыз бала гыйлем эсти.

1850 елда Куян авылындагы 56 хуҗалыкта 526 кеше яши. Бу мәгълүматны раслаучы документта авыл старшинасы Рәхмәтулла Бикбовның имзасы тора. Шунда ук Мөхәммәтрәхим Морасов, Мөхәммәтгали Ягудин, Хәмит Кәримов, Рәхимкол Рәфыйков гаиләләренең (барлыгы – 18 кеше) Юшто-Памаш пүчинкәсеннән Куянга күчеп килгәнлеге теркәлгән. Бу елларда куянлылар дәүләт крестьяннары булып санала һәм патша армиясенә ел саен рекрут җибәреп тора. 1834-1850 еллар арасында гына да 11 егет 25 ел хезмәт итәр өчен солдатка алына. Архив документыннан указлы мулланың 1820 елда туган егет – Фәтхулла Бикчәнтәев булганын да беләбез.

X «Ревизские сказки» мәгълүматларына караганда, 1858 елда авылда 633 кеше, 63 хуҗалык булган. Крестьяннар, гадәттәгечә, игенчелек һәм терлекчелек белән шөгыльләнә. Авыл халкы 220 ат, 340 мөгезле эре терлек, 395 сарык, 46 кәҗә асрый һәм 15 оя умарта тота. Умартачылар елына 3 пот 30 фунт бал җыйган. Ике су тегермәненең дә яхшы гына эшләве мәгълүм.

1884 елда инде Куян төбәктәге иң зур авылларның берсеннән санала башлый. Биредәге 181 хуҗалыкта 1011 кеше яши. Авыл җәмәгате 2069 дисәтинә җиргә хуҗа булып, 180 ат, 166 савым сыеры һәм башка мал-туар асрый. Тегермәннең берсе 16 дисәтинә җирнең хуҗасы Төхфәтулла Сәйфетдиневнеке була.

XX йөз башында Куянда яшәүчеләрнең саны тагын да арта. 1905 елда 253 хуҗалыкта 1413 кеше – 703 ир-ат һәм 710 хатын-кыз яши. Югары очта 1906 елда төзелгән мәчет, ә Түбән очта 1913 елда салынган гыйбадәтханә эшли. Һәр мәчетнең мәдрәсәсе була. Югары оч мәчетендә мулла вазыйфасын Әхмәд Кормашев, соңрак аның улы Габделгазиз башкара.

1909 һәм 1915 елгы Урал сәүдә-сәнәгать палатасы адрес-календареннан күренгәнчә, Куян авылында мануфактура, бакалея һәм колониаль товарлар (һинд чәе, каһвә, шикәр, тәмләткечләр, мамык) сата торган кибетләр эшли. Алар барысы да Табековларның милке санала. Авыл уртасында революциягә кадәр үк кибет һәм склад өчен төзелгән таш бина да Гайсә, Сафа һәм Хәбибрахман Табековларга нисбәтле. Бәрәңгедәге тагын бер мануфактура кибете һәм Мазарбаш авылы янында тегермән дә аларга шактый гына табыш китергән.

Куян авылында 1914 елда Уржум земствосы тарафыннан русча укытыла торган бер класслы училище ачыла. Әмма крестьяннар балаларын әлеге уку йортына бирүдән баш тарта. 1916 елда анда ике укытучының нибары 15 ир балага гына белем бирүен беләбез.

Гражданнар сугышы чорында Куянда комсомолның беренче ячейкасы оешып, аны Бәрәңге районының булачак беренче секретаре Сафук Салихҗанов җитәкли. Биредә үк районның беренче комсомолкасы Нәфисә Юсупова сәяси белем һәм тәҗрибәсен чарлый.

Казан гимназиясен тәмамлап туган авылына кайткан Хәсәнә Кормашева 1918 елда кызлар өчен дөньяви белемнәрне укыта торган мәктәп ачып җибәрә. 1922 елда авылда беренче дәрәҗә мәктәп эшли башлый, анда 40 бала укый. Дүрт елдан соң укучыларның саны – 134 бала, шуларның 43ен кыз бала тәшкил итә. 1923 елда авылдагы 258 хуҗалыкта 1592 кеше яши. 1925 елның апрелендә крестьяннарның бер өлеше кулланучылар җәмгыятенә берләшеп, җитештерү һәм сәүдә эшен җайга сала. Куян халкының 66,2 %ы – ярлы, 30,3 %ы – урта хәлле, 2,6 %ы – бай һәм 0,9 %ы батрак дип санала. Алда искә алынган Табековның – ун аты, Сәгетдин Шәмсетдиновның сигез аты булса, күпләрнең бер аты да булмый. 1928 елда утызлап ярлы гаилә Үзара ярдәмләшү җәмгыяте оештырып җибәрә. Мари-Төрекнең кредит җәмгыяте аларга ашлык сугу җайланмасы һәм җилгәргеч алырга ярдәм итә.

Җир аз булу сәбәпле, крестьяннарга ерак араларга, хәтта 7-8 чакрымга кадәр ба-

Гайнан Кормашев (1919-1944). Туган җире Акмулла өлкәсен (КазССР) калдырып, Мари Иленең Бәрәңге районында педагогика техникумын тәмамлагач, туганнары яшәгән Куян авылына кайта һәм укытучы булып эшли. 1937 елда кулак дип гаепләнеп комсомолдан чыгарылганнан соң, янәдән Акмуллага китә, 20 яшендә мәктәп директоры хезмәтен башкара. 1944 елның 25 августында башы чабылган 11 җәлилченең (аларның «кормашчылар» дип аталуын беләбез) беренчесе.

рып эшләргә, басуда шалашлар корып, кунып та калырга туры килә. Мәсьәләне уңай хәл итәргә теләп, 1928 елда хакимиятнең ярдәме белән 94 гаилә Купай басуына килеп төпләнә һәм Игенчеләр авылына нигез сала. Күчеп килүчеләр әлеге адымнарына шактый үкенгәннәр булса кирәк, соңрак авыл исеме дә халык телендә Никкилдем дип атала башлый.

1929 елда оешкан Куян авыл советы составына Тат-Кошпай һәм Игенчеләр халкы да кертелә. 1930 елда «Кызыл сабан» исемле күмәк хуҗалык оеша: 234 крестьян хуҗалыгыннан (1117 кеше) иң ярлы 50 гаилә (406 кеше) колхозга керә. Егермегә якын хуҗалык, кулак тамгасы сугылып, репрессия золымына дучар ителә, аларның барлык мал-мөлкәте яңа оешкан күмәк хуҗалыкка тартып алына. Шуның нәтиҗәсе буларак, 1931 елда колхозчы хуҗалыкларның саны 160ка җитә. 1934 елда авылга беренче трактор кайта һәм яңа тормыш башлана...

PS: 1920 нче еллар башында Куян авылында 1592 кеше яшәсә, хәзер исә теркәлеп көн күрүчеләрнең саны – 530 кеше. Шулай итеп, бер гасыр эчендә гади генә татар авылының халкы 66,7 %ка кимегән булып чыга.

Мәкаләне әзерләгәндә күрсәткән ярдәме өчен, Бәрәңге төбәген өйрәнүчеләргә – ***Рафаиз Гайнанов*** *һәм* ***Наил Бариевка*** *олуг рәхмәтемне һәм чиксез ихтирамымны белдерәм.*

Чыганаклар:

Россия дәүләт борынгы актлар архивы: Ф.141, Приказные дела старых лет, кн.592, 1699 г. – Доимочная книга Алатской дороги, лл. 1-75.; Ф.350, Оп.2, Д.1151, 1157.
Киров өлкәсенең дәүләт архивы: Ф.176, Оп.2, ДД.183, 612, 908, 1362; Оп.12, Д.1865; Оп.18, Д.1526;
История сел и деревень Параньгинского района Республики Марий Эл. – Йошкар-Ола, 2004. ■

ТӘРҖЕМАН-ӘЛ-ӘНҖЕРӘИ НӘСЕЛЕ

Алсу Нәҗми

Тәрҗеманиларның Әнҗерә авылыннан таралган нәселе

Тәрҗеман хәзрәтнең борынгы бабалары хәзерге Әлки районындагы Әнҗерә авылында яшәгән. Тарихи документлардан күренгәнчә, бу авыл 1711 елда барлыкка килгән. Аңа нигез салучы ясаклы егерме татар – хәзерге Алексеевск районының Ямкә (Ямкино) авылыннан. Тәрҗеманның карт бабасы (ягъни бабасының әтисе) Йосыф та авылга нигез салучылар арасында була. Бу кешеләрнең һәрберсе, Казан губернаторы Апраксин боерыгы буенча, егермешәр дисәтинә печәнлек җир ала.

Ямкә авылы халкының туган нигезләрен ташлап китүенә Идел һәм Чулман кушылган урындагы уңдырышлы болын-тугайга русларның көчеп килүе һәм аларның җирле халыкны эзәрлекләве сәбәп була. 1710 елда халык санын алганда Ямкә авылында 29 йорт хисапланып, аларда 130 кеше яшәгән. 1716 елгы теркәү кенәгәсендә бу авылның бушап калуы, ә халкының бер өлеше 1713-1715 елларда үлеп бетүе һәм көчеп китүе турында мәгълүмат китерелә. Шул ук документтан яңа барлыкка килгән Әнҗерә авылында 17 йорт булуын һәм 131 кеше яшәвен дә беләбез.

Авылга нигез салыну белән бер үк вакытта аның мәчете дә төзелә. 30 ел чамасы вакыт узгач, 1742-1744 елларда, башка татар авылларындагы кебек үк, Әнҗерәнең дә мәчете җимерелә. Бу вакытта авылда 35 йорт булганы мәгълүм. 1748-1750 елларда безнең яклардагы рус булмаган халык көчләп чукындыру афәтенә дучар ителә. 1884 елгы ревизия материалларында күрше-тирәдәге татар авылларының күпчелегендә чукындырылган кешеләр яшәгәне күренә. Әмма Әнҗерә авылы халкының барысы да чукынмаган ясаклы татар, дип теркәлгән.

Тәрҗеман бабай

Нәселебезгә исем бирүче Тәрҗеман бабай 1772 елда дөньяга килә. Аның Җәгъфәр исемле абыйсы, Хәбибулла һәм Сәйфелмөлек исемле энеләре булуы билгеле. Әтиләре Колшәриф бабайның нигезендә кече туганнары Сәйфелмөлек яшәп кала. Моны әниләре Зөләйха Габделкәрим кызының шушы йортта яшәгәненнән чыгып белергә мөмкин. Калган туганнары үз йортларын төп нигез янәшәсендә кора.

Тәрҗеман бабай – әнҗерәлеләр нәселендә мәдрәсә бетергән беренче укымышлы кеше. Аның яшүсмер һәм егет чагы Әби патшаның мөселманнарга дин иреге биргән чорга, ягъни XVIII гасырның азагына туры килә. Шушы сәясәтнең нәтиҗәсе буларак, Казанда беренче уку йортлары – «Апанай», «Ахун» һәм «Әмирхания» мәдрәсәләре эшли башлый. Тәрҗеман бабай да шуларның берсендә белем эстәгән булса кирәк. Аның уллары һәм оныкларының да әлеге мәдрәсәләрдә укуы шуны искәртә.

Абдулла Алишның әтисе Габделбарый һәм әнисе Газизә

Тәрҗеман мулла 24-25 яшьләрендә Мәдинә исемле кыз белән никахлаша. Алар барлыгы тугыз бала – дүрт ул һәм биш кыз тәрбияләп үстерә, кызганыч, арадан бер уллары дүрт яшендә бакый дөньяга күчә. Бу балалардан туган онык-тураннарга татар дөньясына күренекле шәхесләрне тудыру һәм тәрбияләп үстерү тәкъдир ителгән булса кирәк.

Тәрҗеман хәзрәтнең кызлары Шәфкыйзадә һәм Гайшәдән туган бала-оныклар

Тәрҗеман хәзрәтнең кызы Шәфкыйзадә Яңа Әлмәт ишаны Нигъмәтулланың улы Гатаулла муллага кияүгә чыга. Нигъмәтулла Әлмәти – данлыклы Алиш баба нәселеннән. Шиһабетдин Мәрҗани китергән шәҗәрәдән күренгәнчә, Алиш баба тумышы белән Тау ягындагы Шонгаты исемле авылдан. Аның улы Әлмәт бабай – 1670 нче елларда хәзерге Иске Әлмәт авылына нигез салучыларның берсе. **Әлмәт Алиш улы (Әлмәмәт Алишев)** тарихи документларда йөк ташу хезмәтен башкаручы йомышлы татар буларак телгә алына. Әлмәт бабайның улы – Сөрмәт (1656 елгы); аның улы – Ибраһим; Ибраһимның улы – Җәгъфәр; Җәгъфәрнең улы, данлыклы Кизләү мәдрәсәсе мөгаллиме – Гобәйдулла ишан; Гобәйдулланың улы – Нигъмәтулла; Нигъмәтулланың улы – Гатаулла. Гатаулла белән Шәфкыйзадәнең Нурулла исемле улыннан Габделбарый исемле оныклары туа. Габделбарыйның улы исә – фашист тоткынлыгында Муса Җәлил белән бергә шәһит киткән милләт батыры, танылган балалар язучысы **Абдулла Алиш**.

Тәрҗеман бабайның кече кызы Гайшә Татар Борнае авылының имамы Камалетдин Борнаевка кияүгә чыга. Аларның балалары да мулла хезмәтен башкара.

Тәрҗеман хәзрәтнең уллары Хөснетдин һәм Мифтахетдиннәр нәселе

Тәрҗеман бабайның олы улы Хөснетдин, энеләрен солдат хезмәтеннән коткару максаты белән, Оренбургка китә һәм шунда яшәп кала. Аның Ярулла, Әһлиулла, Газиз, Сәяхетдин, Хафизетдин исемле уллары туа. Оренбург ягында Тарзеев фамилиясен йөртүчеләр – Хөснетдин бабай нәселеннән.

Тәрҗеманның икенче улы Мифтахетдин Әнҗерә авылында яши. Аның улы Сәлахетдин Тәрҗеманов Урта Әлки авылының мулласы була. Сәлахетдиннең Түбән Әлки авылындагы Габдулла мулла кызы Мәрфуга белән никахыннан Габдерәшит һәм Габдерәхим исемле уллары туа.

Габдерәхимнең бер улы Әхмәтша Әлкидә чирек гасыр буе волостной старшина вазыйфасын башкара. Аны 1918 елда ак чехлар атып үтерә. Икенче улы Мөбарәкша Түбән Әлки авылында яшәгән һәм мөгаллим булган. Аның балалары да укытучы.

Сәлахетдин хәзрәтнең икенче хатынынннан туган тагын бер улы **Вәлимөхәммәт Тәрҗеманов,** әтисе кебек үк, мулла хезмәтен башкара. Ул 1908 елдан кооперация эшчәнлеге белән шөгыльләнә башлый, кредит ширкәте һәм кулланучылар җәмгыяте оештыра. 1917 елда Үзәк Дини идарәдә – Диния нәзарәтендә эшли. 1919-1920 елларда татар теле мөгаллиме була. Шуннан соң наданлыкны бетерү курсларында укыта һәм ачлык елларында төрле җаваплы вазыйфалар башкара. 1928 елга кадәр Дини идарә чыгара торган «Ислам мәҗәлләсе» журналының җаваплы сәркатибе булып эшли. Колхозлаштыру чорында эзәрлекләнә һәм фаҗигале төстә һәлак була.

Вәлимөхәммәтнең беренче улы **Фоат Тәрҗеманов** 1919-1957 елларда ТАССР, Тула, Мәскәү һәм Куйбышев өлкәләрендәге мәгариф бүлекләрендә хезмәт итә. Педагогик һәм методик мәсьәләләрне яктырткан 200гә якын хезмәт яза. Фоатның улы **Рөстәм Тәрҗеманов** СССР Тышкы сәүдә министрлыгында бүлек мөдире булып эшли. 1986-1987 елларда Бельгия һәм Люксембургта, 1987-1992 елларда Франциядә СССРның сәүдә вәкиле (торгпред) вазыйфаларын башкара. Рөстәм хәзерге вакытта гаиләсе белән Парижда яши. Вәлимөхәммәтнең икенче улы Марат Мәскүдә төрле дәүләт оешмаларында эшли.

Мифтахетдин Тәрҗемановның икенче улы Борһанетдин 1902 елда Гарәбстанның Мәдинә шәһәренә китә. Анда күпмедер яшәгәч, Төркиягә күчеп, фотограф булып эшли һәм шунда төпләнеп кала. Борһанетдиннең Әнисә, Җәһит, Салих, Нәҗми исемле балалары туа. Тәрҗеманиларның Төркиядәге нәселе шулардан тармаклана.

Тәрҗеман хәзрәтнең ул Камалетдин нәселе

Камалетдиннең олы улы Кыяметдин Казандагы Мәрҗани мәдрәсәсендә белем ала.

Кыяметдин мулланың олы кызы Галия үзенең өченче буын туганы Вәлимөхәммәт Сәлахетдин улы Тәрҗемановның хатыны була.

Икенче кызы Мәликә Мораса авылының морзалар нәселеннән чыккан Гариф Черкасовка кияүгә бирелә. Аларның оныгы **Рафаэль Әсгать улы Черкасов** – химия фәннәре докторы, РФнең атказанган фән хезмәткәре, ТРның атказанган фән эшлеклесе, КФУның югары молекуляр һәм элементоорганик кушылмалар кафедрасы профессоры.

Камалетдиннең кече кызы Зәйнәп күренекле тел галиме, фольклорчы, дәреслекләр авторы **Хуҗа Бәдигый**ның хатыны була.

Кыяметдиннең улы **Кәшәфетдин Тәрҗеманов** (1877-1940) Казанның унберенче мәхәллә мәчетендә имам-хатыйп һәм мөгаллим булып хезмәт итә, татар халкының күренекле дин һәм җәмәгать эшлеклесе булып таныла. Кәшәфетдин хәзрәт 1917 елгы Февраль революциясеннән соң Үзәк Дини идарәгә казый итеп билгеләнә. 1924-1928 елларда «Ислам мәҗәлләсе» журналының мөхәррире һәм нәшире, Р.Фәхреддиннең сәркатибе була. 1936-1937 елларда аның урынына мөфти вазыйфасын башкара. Кәшәфетдин хәзрәт 1937 елда «халык дошманы» дигән яла белән төрмәгә ябыла һәм 1943 елда шунда һәлак була.

Кәшәфетдин мулла, Габделгалләм хаҗиның кызы Хөснеруй белән тормыш корып, биш бала үстерә. Уллары Габдрахман һәм Габделәзәл сугышта югала. Кызлары Наҗия, Рафига, Саҗия Донбасска китеп, шунда гаилә коралар.

Кыяметдин мулланың икенче улы Әфтәхетдин, абыйсы Кәшәфетдин Дини идарәгә киткәч, унберенче мәчетнең имамы итеп тәгаенләнә. 1929 елда мәчет дәүләт органнары тарафыннан ябылганчы, шунда хезмәт итә. Әфтәхетдин хәзрәтнең хатыны Һаҗәр – күренекле сәясәтче, дәүләт эшлеклесе **Галимҗан Шәрәф**нең кардәше.

Олы улы **Габбаз Тәрҗеманов** – Воронеж политехника институты доценты. Аның «Основы автоматизированного проектирования агрегатных станков» (1978), «Основы конструирования агрегатных станков»(1982), «Проектирование металлорежущих станков»(1986) исемле китаплары дөнья күрә. Икенче улы Нух Тәрҗеманов – инженер-конструктор. Өченче улы **Әнвәр Тәрҗеманов** – КАИ доценты, ЭВМ заводында директор урынбасары булып эшли. Нух Тәрҗемановның хатыны **Мәрзия Фәйзуллина** – атаклы балалар язучысы, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

Аларның энеләре – **Җәвад Әфтәхетдин улы Тәрҗеманов** (1920-1995) та күренекле язучы, техник фәннәр кандидаты, галим. Ул Казан дәүләт химия-технология институтын тәмамлый һәм шунда ук металлар технологиясе кафедрасында чирек гасырдан артык доцент булып эшли, институтта чыгарыла торган «Гыйльми язмалар»да озак еллар буе җаваплы сәркатип һәм мөхәррир вазыйфасын башкара. Әдәби әсәрләреннән тыш, үз белгечлеге буенча язган дистәләгән гыйльми хезмәтләре, китаплары дөнья күрә. Фән һәм техника өлкәсендәге хезмәтләре өчен, Җ.Тәрҗеманов 1981 елда «ТАССРның атказанган фән һәм техника эшлеклесе» дигән мактаулы исемгә лаек була. Җәвад Тәрҗемановның кызы Гөлшат Тәрҗеманова – КФУ доценты. Улы Камил Тәрҗеманов – КДТУ доценты, «Салават» туристлык агентлыгы генераль директоры.

Әфтәхетдин мулланың кече улы **Әмин Тәрҗеманов** 1924 елда туа. 1943 елда Ленинград артиллерия училищесын тәмамлап, лейтенант дәрәҗәсен ала. 1943-1945 елларда Бөек Ватан сугышында катнаша. Сугышчан батырлыгы өчен «Кызыл Йолдыз», «II нче дәрәҗәдәге Бөек Ватан сугышы» орденнары һәм «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнә. 1950 елда Казан химия-технология институтының «Химическое машиностроение» факультетын тәмамлый. 1950-1956 елларда инженер, Казан компрессорлар заводының җитәкчесе булып эшли. 1957-1962 елларда, аспирант буларак, Мәскәүнең Бөтендөнья теплофизика институтына кече фәнни хезмәткәр булып урнаша. 1960 елда, техник фәннәр кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә алу өчен, диссертация яклый. 1962-1978 елларда КХТИда доцент, Компрессор машиналары кафедрасы профессоры булып эшли. 1972 елда техник фәннәр докторы исемен алу өчен «Иследование теплопроводности газов в широкой области параметров состояния» дигән темага диссертация яклый. 1978-1988 елларда – КХТИның гидравлика кафедрасы җитәкчесе. 1979 елда аңа «ТАССРның атказанган фән һәм техника хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелә. 1988-2000 елларда Казан дәүләт технология университетында профессор була.

Камалетдин хәзрәтнең кызы Мосафа Олы Тигәнәле авылындагы укымышлы нәсел вәкиле Вазыйф Богдановка кияүгә чыга. Уллары Гариф Казанда Татар укытучылар мәктәбендә укый, мөгаллим һәм тәрҗемәче булып эшли. Гарифның уллары Наил һәм Билгус – офицерлар. Ә кече улы **Нияз Гарифович Богданов** – биология фәннәре докторы, профессор. 1966-1973 елларда Ижевск дәүләт медицина академиясенең биология кафедрасын җитәкли.

Камалетдин хәзрәтнең кече кызы Мәсрүрә Ташбилге авылының Мөхәммәтвәли Габбасов дигән кешесенә кияүгә чыга. Аларның уллары Шәһит Беренче бөтендөнья сугышы вакытында Австро-Венгрия әсирлегендә була һәм анда укытучы булып эшли. 1919-1920 елларда Татар укытучылар мәктәбендә укыта.

Ахыры киләсе санда ■

Безнең мирас №3 март 2019

ТАССР

ТАТАРЧА ЯЗУ МАШИНАЛАРЫ

Петербург император университетының физика факультетын тәмамлаган инженер-конструктор Әскәр Шәехгали (1885-1968) 1924 елда ислам, төрки дөньясында зур ачыш ясый: гарәп графикасында яза торган машина уйлап таба. 1925 елның 17 гыйнварында яңа товарны күпләп җитештерү өчен Казан шәһәренең хәзерге Чернышевский урамында «Татарча язу машиналары мастерское» ачыла. Әскәр Шәехгали аның җитәкчесе итеп тәгаенләнә. Шулай итеп, СССРда иң беренче язу машиналары җитештерә торган «Тизяз» (соңрак – «Тизязмаш», «Татязмаш», «Пишмаш» заводы) фабрикасына нигез салына. Шул елларда ук заказлар бөтен союздаш республикалардан, Кытай, Иран, Ливан һәм Һиндстаннан кабул ителә.*

Беренче татар язу машиналары нинди булган? Алар төрки дөньяга алып килгән яңалык нидә? Болар турында алда тәкъдим ителә торган язмадан укырга мөмкин. Мәкалә «Безнең юл» журналының 1925 елгы 2 санынннан алынды (93-94 битләр).

Редакция



Әскәр Шәехгали

Татарча язу машиналары мастерскоен ачканда катнашкан Өлкә партия комитеты, Халык мәгариф комиссариаты, Үзәк Комитет хозурындагы Татар телен гамәлгә кую комиссиясе, Матбагачылар союзы һәм Фабзавком вәкилләре белән бергә алынган рәсем

Татарстан матбугат һәм нәшрият комитеты 17 гыйнварда тантаналы рәвештә татарча язу машиналары мастерское ачып, күпләп машиналар хәзерләү эшенә нигез салды. Хәзергә кечкенә генә шикелле күренгән бу мастерскойның ачылуы миллият мәсьәләсен хәл кылуда, бер Татарстанда гына түгел, бәлки гарәп хәрефләре кулланыла торган бөтен шәрык халыклары арасында ана теленең чынлап гамәлгә куелуында зур тарихи роль уйнаячак. Чөнки бер халыкның теле дәүләт теле төсен алсын өчен һәм шул телдә сөйләүчеләр үзләренең бөтен эшләрен, язуларын шул телдә йөртә алсыннар өчен, мәмләкәт аппаратларының хезмәт ияләренә иң якын тора торганнарында шул телне кулланмый мөмкин булмаганлыгы һәркемгә ачык билгеле. Хәлбуки, язу машинасы булмаганда аны гамәлгә куярга мөмкин түгел. Мәсәлән, һәр көнне әллә никадәр циркуляр, форматлар, кулланмалар җибәреп торырга тиеш булган авыл, волость, кантон, губерна оешмалары кул белән язып, ничек шул эшне башкарып бара алсыннар. Моның өчен һәр оешмада әллә никадәр күчереп язучылар асрарга кирәк булыр иде.

Менә шуларны игътибарга алып, комитет күпләп язу машиналары хәзерләргә тотынды. Әлегә кадәр дә гарәп

*Әскәр Шәехгалинең әтисе патша армиясендә генерал-майор, атаклы хәйрияче Али Дәүләт улы Шәехгали була. Аның Гатаулла Баязитовка «Нур» газетасын чыгарышуы, «Сырател-мөстәкыйм» партиясе әгъзасы икәне дә мәгълүм. Әнисе Гөлсем – атаклы чыңгызыйлар нәселе вәкиле Җәңгир хан оныгы. Әскәр Шаһбазгәрәй Әхмәровның кызы Суфия белән гаилә кора. Инженер 1927 елда гарәп язуын яклап, Сталинга язылган хатка кул куйган 82 кешенең берсе була. 1931 елда аны кулга алып, ГУЛАГка җибәрәләр. Медвежьегорскта катлаулы гидротехник проблемаларны хәл иткәне өчен вакытыннан алда азат ителә, соңрак Волжск шәһәрендә конструктор булып эшли. 1959 елда гына аклана һәм Казанга кайту хокукы ала.

Татарстан матбугат һәм нәшрият комбинатының татарча язу машиналары мастерское

хәрефләре урнаштырылган машиналар бар иде һәм төрле җирләрдә шундый машиналар хәзерләү белән шөгыльләнүчеләр бар, ләкин боларның һичберсе теләкне үтәрлек түгел. Комбинат тарафыннан эшләнә торган машинаның аермасы, артыклыгы нәрсәдә соң?

1) Яуропа хәрефләре утыртылган бөтен машиналарда хәрефләрнең үлчәве бертигез булганлыктан, клавишка басу белән машина һәммә хәрефләр өчен бер үлчәүдә генә сикертмә ясый. Хәлбуки, татар хәрефләренең киңлеге төрле үлчәүдә. Әгәр шул машиналарга гына татар хәрефләрен урнаштырсак, хәрефләр йә берсе өстенә берсе төшә яки шулай төшмәсен өчен, хәрефне басканның соңында, хәрефнең киңлеге үлчәвендә буш сикертмә ясарга туры килә. Комбинат машинасын эшләүче, шул сикертмәне табу өчен ике-өч еллар баш ватып, ниһаять, шул машиналарның конструкциясен үзгәртеп, клавишын басу белән хәрефнең киңлегенә карап автомат рәвештә сикертмә ясарлык хәлгә китерүче иптәш Әскәр Шәехгали бик күп осталарның баш ваткан проблемасын хәл кылды.

2) Безнең аппаратларда күп вакытта, ана теле белән бергә, рус телендә дә эш йөртергә туры килгәнлектән, ике машина һәм ике язучы тоту кирәклегеннән котылу өчен, бер машинаны һәр ике телдәге хәрефләр белән язарлык хәлгә китерү һәм шулай итеп, хөкүмәт аппаратларын артык расходтан коткару күздә тотылып, беренче машиналар шул рәвештә эшләнә башлады.

3) Төрле урыннарда төрле шәкел хәрефләр кулланылганлыктан, машинаның конструкциясен төрле хәреф урнаштырырга ярарлык хәлгә китерергә кирәк булды һәм бу эш тә муәффәкыятьле *(уңышлы)* рәвештә хәл ителде. Комбинат машинасында аерым хәрефләр белән язарга мөмкин булган шикелле, баш, урта, ахыр һәм ялгыз хәрефләрнең һәммәсен дә урнаштырырга мөмкин.

4) Иң әһәмиятле булганы – арзанлык. Күпләп эшләү аркасында, комбинат бу юлда да зур адым атлады. Әлегә кадәр муәффәкыятьсез машиналарга 1000 сумнар бәя тәгаен ителдегеге хәлдә, комбинатның ике телдә баса торган машиналары 400 сум чамасыннан артык булмаячак.

Хәзергә комбинатның эш планы һәр көнне бер машина чыгарып бару үлчәвендә төзелгән. ■

Ризаэддин Фәхреддин
гыйбарәләре

● Тәрбиядән яраладыр тәрбия.

● Изге хатын – бетми торган хәзинә булганы кебек, бу дөнья сәфәрендә иренә юлдаш, мәшәкатьләрдә юатачак юаныч, авырлыкларда таяныч булыр.

● Хатыннары тәрбияле булган милләт – тәрбияле; хатыннары тәрбиясез милләт – тәрбиясез; хатыннары тырыш вә идарә итүчән милләт – бай; хатыннары ялкау вә исраф итүчән милләт – фәкыйрь буладыр.

● Ана булу – бөек бер нигъмәт-муллык вә тиңдәше булмаган бер хөрмәттер.

● Хатын – фәкыйрьлеккә каршы бер гаскәрдер: ватаны – өй, хәрби ныгытмасы – тырышлык, хәрби фәне – йорт белән идарә итү, коралы – энә белән кайчыдыр.

● Бала тәрбиясе хакында булган хезмәтләрнең иң бөеге – аналар өстендә.

● Хатын үзең тота белсәң, үзең матур тәрбия бирсәң генә яхшы хатын булыр, юкса, яхшы тәрбия итә белмәсәң, хатын түгел, җан хәсрәте булыр.

● Хатыннарның бизәкләре – энҗеләре, хәтфә камзуллары, ефәк күлмәкләре, алтын беләзекләре түгел, бәлки тәрбияләредер.


سوکیلی قزم اسماء غه:
علم اوگره ن علم ایزگوگه تارتور
علم بولغان کشی ده ذهن آرتور.
فرصتنی غنیمت بلسه ک، اوزنگا کیره ک بولاچق نرسه لری
حاصل قیلسه ک (اوگره نسه ک)، کشیلرگه آچیق یوزلی
بولسه ک، سوزنگنی یومشاق سویله سه ک شول وقت
سین بولورسن «عقللی» قز، یاخشی کشی. سزگه دعاچی
اتکاکز رضاء الدین بن فخر الدین. ۲۴ جمادی الاولی ۱۳۳۷، اورنبورغ

Р.Фәхреддиинең кече кызы Әсмага (1906-1993) нәсыйхәте:
«Сөекле кызым Әсмага. Гыйлем өйрән, гыйлем изгегә тартыр, гыйлеме булган кешедә зиһен артыр. Үзеңә кирәк булачак әйберләрне хасил кылсаң, кешеләргә ачык йөзле булсаң, сүзеңне йомшак сөйләсәң, шулвакыт син булырсың акыллы кыз, яхшы кеше. Сезгә догачы Р.Фәхреддин».

Журналга Диләрә Гыймранова әзерләде. ■

САРАЛЫ МЕҢ ЫРУЫ ТАТАРЛАРЫ

Раиф Мәрданов

13. Рус хакимлегенә кергәч, элекке аксөяк һәм йомышлы сословиесендәге татарларны гади ясаклы катлавына күчерү күренеше XVII-XVIII гасырларда дәвам итеп килгән. Мәсәлән, патша Пётр I нченең әмере белән 1697 елда элекке тархан һәм морза нәселләре ясаклы татарлар итеп язылган. Элекке татар морзалары һәм бүтән аксөяк затларының шактые 1720 нче еллардагы исәп алу документларында ясаклы татар, дип язылганнар. Саралы авылыннан таралган Мең ыруы татарлары тармаклары да төрлечә: ясаклы татар, башкорт-вотчинник, башкорт-припущенник яки типтәр булып теркәлгән. Мәсәлән, Бәзәкә, Турай, Әтәс, Тогыҗа һәм бүтән авыллардагы ырудашларның Саралыда яшәгән борынгы бабалары XVI гасырда ясаклы татарлар буларак язылып йөртелгәннән соң, үзләренең киң мәйданнардагы элекке ата-бабаларыннан килгән биләмәләрен саклау авырлаша барганга, XVII гасырда күбрәк хокукларга ия һәм ясакны да азрак түләүче «башкорт» катлавына язылуга ирешкәннәр.

Чулман һәм Ык елгалары буендагы элек-электән бер үк ыру кешеләре биләгән җирләр Мең һәм Байлар волостьларыныкы буларак язылып килгән һәм үзара бәхәсләре дә булмаган. Ләкин бу якларга башка төбәкләрдән күпләп күчеп килүчеләр урнаша башлагач, биләмәнең аерым өлешләре сатылуы сәбәпле, XIX гасыр башында үткәрелгән генераль ызанлау вакытында Сарайлы Мең һәм Байлар волостьларына кергән авыллар арасында җир бәхәсләре чыгып, тикшерүләр үткәрелгән. Нәтиҗәдә, элек Сарайлы Мең волосте авылларындагы халыкның күпчелеге (ясаклы татарлар, типтәрләр) һәм Байлар волостеның һәр тарафы (башкорт, типтәр, ясаклы) XVII гасырда бер үк грамоталарны үзләренең бабаларыныкы итеп күрсәтүләре һәм биләмәләре элекке чорда уртак булганлыгы ачыкланган. Ягъни алар аерым волостьлар буларак аталсалар да һәм төрле катлау вәкилләре булсалар да, тамырлары бер икәнлеге аңлашылган. Төп хикмәт ырудашларның вакытлар уза барган саен табигый аерымлануларына, шулай ук баштарак күбесенең ясаклы татар булып, Чулман аръягына чыккач башкорт яки типтәр булып язылганына да бәйле.

Чулман аръягындагы Сәмәкәй авылында яшәгән татарларның припущенник дип саналганнары 1856 елда әйтүләренчә, үзләренең Бәзәкәдәге бабаларына 220 ел элек грамота бирелгән булган. (Әгәр дә 200 яисә 250 рәвешле сан әйтелгән булса, якынчалык күздә тотылган, дип уйларга мөмкин булыр иде, әмма 220 ел дигән сүз төгәлрәк датага ишарә итә). Әлеге 220 елны 1856 елдан хәзерге календарь исәбе белән чигерсәк, 1636 ел килеп чыга. Әмма ул елда Бәзәкәгә бәйле грамота документы турында архивларда бернинди дә мәгълүмат юк. Ләкин 220 ел элек дигән мәгълүматны биргән кеше укымышлы (димәк, мулла заты) булуын игътибарга алсак, дин әһелләре, гадәттә, һиҗри, ягъни мөселманча ел исәбен кулланганнар. Менә шуны истә тотып, 1856 елдан мөселманча календарь буенча 220 елны киметсәк, нәкъ 1642 ел килеп чыга. (Хәзергечә григориан календаре буенча 33 ел мөселманча 34 елга туры килә). Белгәнебезчә, Бәзәкә авылына шул елда рәсми документ («оберегательная грамота») алганнар. Димәк, сәмәкәйлеләр Бәзәкә авылының иң әүвәлге грамотасына ишарә иткәннәр.

Ахыры. Башы журналның 2019 елгы 1 нче санында.

Чулман аръягындагы кайбер авылларда яшәгән ырудашлар үзләренең биләмә хокукларын раслатуны сорап XVIII гасыр ахырында үтенечләр язсалар да, уңай нәтиҗәсе булмаган диярлек. Мәсәлән, 1795 елда Минзәлә өязенең Саралы Мең волостендагы Котысаз (Иман) авылы мулласы Сәйфулла Тимеркәев Котысаз (Иман), Сарсаз Тәкермән, Чураш, Иске Дөреш, Мерәс, Сәет, Чыршылы (Шанды Тамак), Өчиле Саклауда яшәгән кардәшләре исеменнән Минзәлә өяз судына үтенеч язган. Ул үзләренең Саралы Мең волостеның борынгы бабалары Уфа өязенең Нугай һәм Казан даругаларындагы биләмәләренә 1646 елда бирелгән грамота буенча хуҗа икәнлекләрен язган. Әлеге грамотаның борынгы бабалары Мәхмүт Дистан улы, Җанбакты Кадыш улы, Уразлы Уразман улы һәм Камачык Җаексыбы улы (архив документында: «Махмут Дитасов, князь Янбахта Кадышев, Уразлы Уразманов, Камачик Яискубин») исемнәренә язылганлыгы күрсәтелгән. Элекке биләмә хуҗаларының әйтеп үтелгән сигез авылдагы дәвамчылары 1725 елда, ни сәбәптәндер, ясаклы татар сословиесенә теркәлгәннәр. Бу мәсьәлә турында 1779 елдагы мөрәҗәгатьләре дә хәл ителмичә калдырылган. 1795 елда шул авылларда яшәүчеләр, мондагы җир-суларның төп хуҗалары буларак, үзләрен «башкорт» катлавына язарга сораганнар. Мәсьәлә хәл ителмәгәч, шул ук Иман авылының Тимеркәй Йосыф улы 1798 елда ясаклы катлавыннан башкорт сословиесенә күчерүне сорап тагын үтенеч язган. Ул үзенең Бәйрәмхуҗа исемле борынгы бабасына 1596 (7104) елда бирелгән грамотасы буенча җир хуҗасы икәнлеген һәм бабаларының исемнәрен белдергән: Габделҗәлил, аның атасы Аит, аннан элекке буыннар: Иман – Тугай – Исәк – Аккуҗа – Бәйрәмхуҗа. Ләкин аңа ясаклы катлавыннан чыгарга рөхсәт бирелмәгән һәм ул нәселнекеләр XX гасыр башына кадәр ясаклы булып йөртелгәннәр. Дамир Гарифуллинның язуынча, «шулай да элек-электән җир биләүгә грамотасы булган әлеге нәселнең «аксөякнекеләр» дигән кушаматы соңгы көннәргә кадәр Тимеркәйнекеләргә ябышып кала. Тимеркәйнекеләр шәҗәрәсен хәзер дә Иске Имән авылында да, Яңа Имән авылында да дәвам итүчеләр бар». Монда күрсәтелгән Иман дигән кеше исеме иске архив документларында һәм Кучкар би шәҗәрәсендә Айман буларак теркәлгәнен исәпкә алганда, Иман авылы атамасы Айман исемендәге беренче авазның сөйләм телендә төшеп калуыннан чыккандыр. Архив документларыннан аңлашылуынча, Иман авылында яшәгән Тимеркәйнең борынгы бабалары Аккуҗа Бәйрәмхуҗа улы белән Тогыҗа авылында XVII гасыр башларында торган Тугыҗак Бәйрәмхуҗа улы бер-



Саралы ыруының җир бәхәсенә багышланган архив эше. 1803 ел

туганнар булган. 1619 елгы документта исеме теркәлгән Саралы авылының Байхуҗа Бәйрәмхуҗа улы да аларның бертуганы булган дип уйлыйбыз. Димәк, хәзерге Сарман районындагы Иске Имән (Иман) авылына Чулман елгасының уң ягында яшәгән Мең ыруы вәкилләре күчкән.

Әйтеп үтелгән 8 авыл кешеләре кебек үк, 1795 елда Дүсем авылының мулласы Рәфыйк Сәмәкаев тә (бабасы Сәет һәм аннан әүвәлге бабасы Рыс Юныс улы) «башкорт» итеп яздырырга сорап караган. Ул Саралы Мең волостендагы Саклаубаш, Саралы Бикмәт һәм Келәнче Тамак авылларында кардәшләре яшәвен белдергән.

Татар Туембашы авылының Госман бабай уллары Хәлил белән Уразман шулай ук 1795 елда, үзләренең биләмә хокукларын ныгыту йөзеннән, хөкүмәт оешмаларына мөрәҗәгать иткән булганнар. Алар, Тогыҗа авылындагы нәселдәшләре белән, Минзәлә өязенең Сарсаз Тәкермән һәм Иман авылларындагы ырудашлары кебек үк, борынгы бабалары Канзафар Муса улының дәвамчылары икәнлекләрен тануны сораганнар. 1811 елның 28 декабрендәге архив документының бер өлеше бу рәвешле: «...изъяснили, что предки их, а по них и потомки близкие родственники их состоят в башкирцах и жительствуют в Мензелинской округе Саралиминской волости в деревнях Сарсас Такирмень, Имановой на жалованных землях. А они, неизвестно почему, вписаны в род ясашных татар... Земской суд донёс, что родственники их Саралиминской волости башкирцы 6 человек утвердили, что просители происходят от одного поколения пращура их – Канзафара Мусина. Показание подтверждено 14-ми посторонними... На утверждение рода их в башкирском звании доказательств не представили». Нәтиҗәдә, аларга да ясаклы сословиесеннән чыгарырга рөхсәт бирелмәгән.

Чулман елгасының уң як төбәгендәге һәм Чулман аръягындагы Мең ыруы кешеләренең XVII гасырдагы Канзафар бигә бәйле булулары турындагы сүзләре, чынлыкта, элеккерәк чордагы ырудашлыкны күздә тоткандыр. Бу, күрәсең, исеме шактый мәгълүм булган Канзафар бигә бәйләп әйтелгәндер. Кучкар бидән башланып дәвам иткән һәм 18 нче буынында Казанфар би язылган «Кучкар би» шәҗәрәсенә тукталып үтик. Анда Казанфар бинең улы Дистан баба, аның улы Әхмәд, аның уллары: Шәех Хәсән, Гали, Балтач һәм Балтачның бер улы Бәйрәмхуҗа дип язылган[1]. Бу шәҗәрәдәге кеше исемнәре дөрес булса да, алардагы буыннар үзара буталганлыгы аңлашыла. Чөнки архив документыннан күренгәнчә, XVI гасырның икенче яртысы-XVII гасырның башында Саралы авылында яшәгән Бәйрәмхуҗа Балтач улының ике улы: Байхуҗа белән Тукхуҗа шәҗәрәдә аның бертуганнары итеп ялгыш язылган. Ә архив документыннан билгеле Акхуҗа исемле улы шәҗәрәдә дә Бәйрәмхуҗаның улы итеп дөрес күрсәтелгән. Шәҗәрәдәге элекке буыннарның кайсы чор кешеләре булганлыгын якынча исәпләгәндә, Бәйрәмхуҗаның әтисе Балтачның бабасы Дистан XV гасыр урталарында туган, ә Дистанның әтисе Казанфар би аннан да әүвәлгерәк заман кешесе булып чыга. Әмма тарихчылар ачыклаганга караганда, Казанфар би – XVII гасырның беренче яртысында гомер иткән шәхес. Димәк, Кучкар би шәҗәрәсендә язылган Бәйрәмхуҗа һәм аның әтисе Балтач исемнәреннән әүвәлгерәк буыннарда ялгышлык бар. Саралы авылының 1625 елда биләмә грамотасы алган һәм шуны 1643 елда яңарткан кешеләре арасында Җанбакты Җансәет улы исеме Кучкар би шәҗәрәсендә дә бар (Йанбакты һәм аның әтисе Йансәед дип күрсәтелгән). Кучкар би шәҗәрәсенә карата М.Әхмәтҗанов язган искәрмәдә болай диелгән: «Нугай Урдасы татарларының нәсел тарихын чагылдырган бу борынгы шәҗәрә күчермәсен Татарстанның Сарман төбәгендә яшәүче, җирле тарихны өйрәнүче Дамир Гарифуллин эзләп табып, матбугатта чыгарырга рөхсәт белән безгә тапшырган иде. Кульязма

[1] Әхмәтҗанов М. Татар шәҗәрәләре: II том. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2014. – Б.172-173.

– гарәп графикасында. Сакланышы бик үк яхшы түгел. Заманында юешләнеп, күп урында язулар укый алмаслык хәлгә килгән. Зур форматлы кәгазьнең бөкләнгән урыннары бик нык таушалган. Бу хәл аны укуда шактый кыенлыклар тудыра»[2]. Менә бу искәрмәдә әйтелгән объектив сәбәпләр аркасында, ягъни кулъязма начар хәлдә саклангага күрә, шәҗәрә буыннары китапта буталып басылган.

14. Татар шәҗәрәләренә багышланган китапларда Меңнәр кабиләсе, Канзәфәр би шәҗәрәсе, Шәехдирбеш шәҗәрәсе, Гирәйет (Кирәйет) би шәҗәрәсе, Кучкар би нәселе, шулай ук Азнакай төбәгенең Карамалы авылы шәҗәрәсе, Бәзәкә авылы нәселләре дип исемләнгән шәҗәрә материаллары, нигездә, бай тарихлы Сарайлы Мең ыруының тармакларын тәшкил итә.

Нәсел-ыруга караган һәр мәгълүмат, һичшиксез, кыйммәтле. Әмма электән кулдан язылып һәм күчерелеп яисә буыннан-буынга телдән сөйләнеп килгән шәҗәрәләрне архив чыганаклары белән чагыштырып өйрәнгәндә, борынгырак чордагы буыннар тәртибе һәм исемнәрнең буталган булуы күренә. Бер төбәктән икенчесенә һәм авылдан-авылга күчеп йөрүләргә бәйле рәвештә, шәҗәрәләрдә бөтен кардәшләр дә (әйтик, бер атаның барлык уллары да) язылмаган.

Әмма һәр язма чыганак үзенчә әһәмиятле. Әйтик, электән килгән язма шәҗәрәләр һәм аларга бәйле истәлекләрдә архив документларын тулыландыра торган кызыклы хәбәрләр бар. Шәҗәрәләрнең андый хасияте аеруча мөһим. Азнакай районының Урсай һәм Чалпы авылларында яшәүчеләрнең шәҗәрәләрендәге борынгы «Исәнгол Сарыбай угылы» дигән буыннары элек Алабуга янындагы Саралы авылында яшәгән Мең ыруы вәкилләреннән Туймыш бабайның улы Сарыбай белән аның улы Исәнгол икәнлеге аңлашыла. Галим Марсель Әхмәтҗанов «Кирәйет шәҗәрәләре» исеме астында бу зур нәселнең алты версиясен бастырган. XIX гасырда әлеге шәҗәрәне язган Әбелфәттах мулланың әүвәлге бабалары «Урсай Җийаш угылы, Җийаш Исәнгол угылы, Исәнгол Сарубай угылы, Сарубай Бүләк угылы, Бүләк Аккүз угылы, Аккүз Арслан угылы, Арслан Алгунчы угылы, Алгунчы Кугынчы угылы, Кугынчы Кирәйет би угылы. Кирәйет би Нугайдан килгән» дип язылган[3].

Кирәйет шәҗәрәсе версияләрендәге Исәнгол Сарыбай улының Саралы авылында яшәгән татарлардан чыккан булуы «Кучкар би нәселе шәҗәрәсе»нә карата язылган өстәмә мәгълүматтан ачыклана: «Без – Сарай иле башкордларының үткән 1715 йылда, әүвәлге падишаһ Михаил Фёдоровичдән грамот алган бабаларымызның исемләре: әүвәл – Туктамыш бине Шәех Дирбеш, II нче – Тукай бине Котый, III нче – Йанбатай бине Йансәйед, IV нче – Сармас, V нче – Бигәш, VI нчы – Туймышдыр»[4]. Тик мондагы 1715 ел дигән дата дөрес түгел. Чынлыкта, андагы саннарның урыннары алмашынган. Ягъни дөресе – рус дәүләтендәге искечә ел хисабы буенча 7151 ел булып, ул хәзерге 1643 елга туры килә. Патша Михаил Фёдоровичның да тәхеттә утырган вакыты 1613-1645 елларда булганлыгы моны раслый. Кеше исемнәренә килгәндә, Саралы авылының Туктамыш Шәехдирбеш улы һәм иптәшләре исеменә чынлап та 1643 елда биләмә хокукын белдергән рәсми документ (грамота) бирелгәнлеге архив документларында күп очрый. Туктамыш бабай – Менделеев районындагы Турай авылы халкының күпчелегенең борынгы уртак бабасы. Җанбакты Җансәет (Йанбатай Йансәет) улының да исеме 1643 елгы биләмә грамотасында теркәлгән. Ә менә Сармас, Бигәш һәм Туймыш дип аерып язылган өч кеше чынлыкта Туймыш бабай һәм

[2] Шунда ук. – Б.175.
[3] Әхмәтҗанов М. Нугай Урдасы: татар халкының тарихи мирасы. – Казан: «Мәгариф» нәшрияты, 2002. – Б.32.
[4] Әхмәтҗанов М. Татар шәҗәрәләре: II том. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2014. – Б.175.

аның ике улы – Сарыбай[5] белән Бигәш. Алар да 1643 елгы грамотада язылганнар. Алабуга янындагы Саралыда яшәгән татарларның язма шәҗәрәдә исемнәре телгә алынган булуы әүвәлге бәйләнешләрне ачык раслый.

15. Борынгы ташъязма истәлекләр турында да искәртик. Мең ыруы вәкилләреннән XVII гасырда яшәгән Чуашай бабайның кабер ташы сакланган дигән идек. Хәзерге Менделеев районындагы Турай авылы зиратында 1679 елда вафат булган Турай улы Чуашай һәм шул ук нәселнең Бибулды улы Мәсгутькә 1680 елда куелган кабер ташлары бар. Чуашайга ташны хатыны Туйсолтан остабикә куйдырган һәм анда уллары Йосыф белән Ишали исемнәре дә теркәлгән, ә Мәсгутькә ташны агасы Биморза куйдырган һәм анда Бибулдының атасы Байсыбы булуы язып куелган. Менә бу затлар барысы да Мең ыруының шәҗәрәләрендә язылган һәм архив документларында да исемнәре очрый торган шәхесләр. Алар белән бер үк кабилә-ырудан булган Йөзекәй бабайның 1689 елгы кабер ташы Бәзәкә авылы зиратында хәзергәчә сакланган, аны улы Айман куйдырган. Тогыҗа авылындагы 1692 елгы кабер ташы, архив документларына нигезләнеп фикер йөрткәндә, шул ук ыру кешесенеке икәнлеге аңлашыла. Ул – Байкилде улы Әкил исемле кешегә улы Балтач ясатып куйдырган таш.

Хисаметдин Мөслиминең XVIII гасыр ахырында язылган «Тәварихы Болгарийә» (Болгар тарихы) әсәре фәнни кыйммәте ягыннан шактый тәнкыйтьләнгән булса да, анда XVI-XVIII гасырларда яшәгән кайбер татар укымышлыларының исемнәре теркәлгән. Әлеге китапның «Болгардагы изге шәехләр һәм бөек әүлияләр турында» дигән бүлегендә күпчелеге реаль шәхесләр булган укымышлы затлар арасында «Алабугада Бәйрәмхуҗаның кабере» дигән сүзләрдә архив документларында һәм шәҗәрәдә язылган Бәйрәмхуҗа Балтач улы күздә тотылган, дип уйлыйбыз. Ул Алабуга шәһәре янындагы Саралы авылында яшәгән һәм, архив язмаларыннан ачыклануынча, 1619-1641 еллар арасында вафат булган. Кабере Саралы зиратында булгандыр. Галимә Гөлзадә Әхтәмова язуына караганда, Саралы авылының элекке мөселман зираты өстенә 1960 нчы елларда колхоз фермасы төзегәндә гарәп язулы өч кабер ташы табылган. Ләкин ул ташларны нишләткәннәрдер – билгеле түгел[6]. Әлеге ташъязмалар Саралы Мең ыруы кешеләренең каберләренә куелып, ихтимал, берсе Бәйрәмхуҗа бабайныкы булгандыр.

16. Алдарак нәсел тамгалары турында әйтеп үткән идек. Алабуга шәһәре янындагы Саралыдан таралып, Бәзәкә, Турай һәм бүтән авылларда яшәгән ырудашларның XVII гасыр башыннан XX гасыр башына кадәр кулланган нәсел тамгалары, нигездә, берничә төрле: төп өлешләре Т, Н, Х рәвешләрендә, кайчагында аларга өстәмә элементлар гына ялганган. Мәсәлән, 1690 елгы архив документында Бәзәкә авылының Йөзекәй һәм аның өчтуган кардәше Атнагол Ырыс улы «Н» кыяфәтендәге нәсел тамгаларын салганнар. Димәк, Йөзекәй белән Атнаголның бабалары – бертуган Бигәш белән Сарыбай шундый ук тамга кулланганлыгы ачыклана. Аларга исә әтиләре Туймыштан күчкән бер үк төрле нәсел тамгасы XVI гасырда яшәгән Туймыш бабайдан алып, аның токымнарында ун-унбер буында үзгәрешсез дәвам иткән һәм XX гасырга – совет чорына хәтле кулланылган. Туймыш бабайның бертуганнары яки аннан әүвәлге буыннарда тоташкан кардәшләре – Турай авылының төп нәсел тармакларында бертөрле үк тамгалар кулланылган булу факты исә, нәсел тамгаларының кайбер төрләре Туймыш бабайдан да элеккерәк буыннардан килгәнлеген раслый.

Архив документларыннан күренгәнчә, Чулман елгасының аргы ягындагы Сарай-

[5] Сарыбай – Сарыймөхәммәт исеменең кыскартылмасы. Архив документларында аның Сарбаш, Сармаш дип язылган очраклары булган кебек, Кучкар би шәҗәрәсендәге «Сармас» та бер үк кешенең исеме. Әлеге исемнең Сарман рәвешендәге кыскартылган варианты да кулланылган.
[6] Әхтәмова Г. Борынгы Алабуга // Казан утлары. – 2007. – №7. – Б.126.

Бәзәкә авылы зиратында Йөзекәй Таңай улының кабер ташы. 1689 ел

лы Мең волосте авылларының тамгалары да еш кына Бәзәкә һәм Турай авыллары тамгалары кебек үк.

Элекке архив документларында куелган нәсел тамгалары алдарак тасвирлап үтелгән Сахибгәрәй хан тарафыннан 1523 елда бирелгән ярлык турындагы фикерләребезне дә куәтли. Ул ярлык дәлил итеп кулланылган Ык буендагы биләмә эше артыннан йөргән Ишмәт Ырыс улы 1680 елның 26 февралендә карар документын кулына алгач, Х-сыман тамгасын салган. Аның фәкать бер очында өстәлгән сызыкчасы башкачарак. Шул ук хан ярлыгы нигезендә үз хокукларын раслаган, Ык елгасы буендагы Исламбакты авылы тирәсендәге биләмәләрнең хуҗалары – XVIII гасырда яшәгән өч бертуган: Исламбакты, Уразбакты һәм Уразман Атнагол улларының тамгалары Бәзәкә һәм Турай авылларындагы ырудашлары кулланган Х рәвешендәге кебек үк. Шул ук нәсел дәвамчыларыннан 11 кешенең 1836 елгы архив документында теркәлгән тамгалары да, Бәзәкә һәм Турайда яшәгән нәсел-ыруларныкы кебек, Х, Т һәм Н рәвешләрендә. Әлеге тамгаларның сурәтләрен Уфа шәһәрендә 1996 елда уздырылган конференция тезислары җыентыгында да күрергә мөмкин[7]. Әйткәнебезчә, Исламбакты авылы нәсел тамгаларының Бәзәкә һәм Турайда яшәгән нәселдәшләр һәм ырудашлар гасырлар буе кулланып килгән тамгаларга тәңгәл килүе 1523 елгы хан ярлыгының шушы ыру-нәселгә бәйлелеген раслый торган ышанычлы чыганак.

17. Тагын бер өстәмә дәлилгә тукталыйк. Галимә Зәйнәп Максудовада сакланган «Алабуга бәете»н галим Марсель Бакиров беренче мәртәбә 1979 елда бастырган иде. Аннан соң ул бүтән китапларда да дөнья күрде. Бу бәетнең тексты түбәндәгечә:

Алабуга – ак шәһәр, тарихы озак яшәр,
Дошманга, яуга бирелмәс, юлына каршы төшәр.
Алабуга урыс кулына Сәүгән ханнан калгандыр,
Сәүгән ханның маҗарасы тарихта язылгандыр.
Атлар җиктем яратып, Саралыга каратып,
Саралы, Сәйтәк чукынган, кәфер утын таратып.
Алабуга олылары – Туйгуҗа белән Аккуҗа сөрлектеләр иленнән,
Сарай белән Сәеттәкбәк чыктылар ислам диненнән[8].

[7] Символы и эмблемы в истории Башкортостана: Тезисы докладов и сообщений третьей республиканской научно-краеведческой конференции. – Уфа: «Восточный университет», 1996. – С.49.
[8] Яхин А., Бакиров М. Фольклор жанрларын система итеп тикшерү тәҗрибәсе: мәзәкләр, бәетләр. – Казан: университет нәшрияты, 1979. – Б.126-127.

Мондагы соңгы юлда Сарай дигән атаманың дөресе Саралы булгандыр. Аның ялгыш язылышы элекке гарәпчә язудагы «й» хәрефе һәм «лы» иҗеге охшашрак булудан чыкканга охшый.

Халык арасында йөргән риваятьләр белән тарихи чынбарлык кушылган бу бәет фрагменты Сарайлы Мең ыруының аксөяк катламына да багышланган, дип әйтә алабыз. Чөнки алда язганнарыбыздан аңлашылганча, Алабуга үзе Мең ыруы биләмәсендә булган. Бәеттә «Алабуга олылары», ягъни аксөякләре дип аталган Туйгуҗа белән Аккуҗа исемнәре Мең ыруының XVII гасырда яшәгән вәкилләре – Бәйрәмхуҗа улларының исемнәренә туры килә. Алда язылганнардан күренгәнчә, руслар Казан ханлыгын алганнан соң да Мең ыруы татарлары бу төбәктәге биләмәләрен сакларга тырышканнар һәм аларның төп яшәгән урыннары бәеттә телгә алынган Саралы авылы булган. Бәйрәмхуҗа улы Аккуҗаның нәсел дәвамчылары Чулман аръягына күчеп Иман (хәзерге Сарман районындагы Иске Имән) авылына урнашканлыгы архив мәгълүматлары белән раслануын алда язып үттек. Шуны да искәртик, Д.Исхаков һәм кайбер башка тарихчыларның «Алабуга бәете»ндәге Туйхуҗа исеменең бүтән нәсел-ыруга бәйләнеше булуы турындагы фаразлары дәлилсез.

Бәеттәге Сәүгән хан дигән исем Казан тарихчысы Хөсәен Әмирханның 1883 елда басылган «Тәварихы Болгария» исемле китабында телгә алынган. Анда Казан ханлыгы чоры турында язганда «Алабугада Илбакты угылы Сәүгән бик хан» булган, дип, аңа бәйле уйдырма маҗаралар тасвирланган. Бу шәхеснең реаль кеше булганлыгы тарихта билгеле түгел. Һәрхәлдә, сүз бара торган бәеттә Х.Әмирхан китабында язылган Сәүгән күздә тотылган.

Бәет текстындагы «Саралы, Сәйтәк чукынган» һәм «чыктылар ислам диненнән» дигәндә, күрәсең, Саралы белән Сәйтәк авылларында чукынган кяферләр – беренчесендә руслар һәм икенчесендә керәшен татарлары яшәү факты гына күздә тотылгандыр. Чөнки Саралыда элек яшәгән мөселман татарлар XVII гасыр башларында аннан күчеп беткәннәр. Күчеп китүләренең сәбәпләреннән берсе – көчләп чукындыру куркынычы булган. XVII-XIX гасырларда Саралыда керәшен татарлары яшәгәнлеге турында архив мәгълүматлары юк. Саралы авылына карата «чукынган» сүзен кулланган бәет авторлары ул авылда элек татарлар яшәгәнен ишетеп белгәнгә күрә, аларны чукынып-урыслашып беткәннәр дип фаразлаганнардыр. Сәйтәк авылы очрагында да, анда әүвәл яшәгән мөселман-татарлар чукынган дигән сүз түгел. Чөнки, архив документларыннан күренгәнчә, Сәйтәк башта мөселман татарлар авылы булып, алар күченеп киткәннән соң, керәшен татарлары 1640 нчы елларда шунда урнашканнар һәм аларга әүвәлдәге Сәйтәк дигән исем генә берегеп калган.

Туйгуҗа белән Аккуҗаның илдән (Саралы авылыннан) сөрлегүе, ягъни Саралыдан ихтыярсыз читкә күчеп китүләре архив чыганаклары белән дә раслана. Бу вакыйга исә, архив документларыннан күренгәнчә, XVII гасырның башларында булган.

«Алабуга бәете»нең иҗат ителгән вакытына килсәк, аның нигезе борынгырак чордан килгәндер. Әмма татар халкының милли үзаңы көчәйгән чорда: XIX гасыр ахыры-XX гасыр башында иҗат ителгән булу ихтималы зуррак. Аның авторлары шул төбәктә яшәгәнлеге аңлашылып тора. Монда китерелгән бәет өзеге, әлбәттә, күләмле әсәрнең сакланып калган хәтлесе генә. Ахырдагы ике юллык башкаларыннан иҗек саны һәм ритмик корылышы белән аерылып торуына караганда, бәлки, Алабуга төбәгендәге татарларның тарихи үткәненә багышланган ике төрле бәет юллары монда бергә кушылгандыр.

***

Архив мәгълүматларын һәм башка төр материалларны тикшергәч, борынгы Мең ыруына нисбәтле татарлар Казан ханлыгы чорында Алабугага якын-тирә җирләргә һәм Чулман аръягындагы Ык буйларына хуҗа булып яшәгәнлеге күзаллана. Әйтеп киткәнебезчә, Чулманның бу төбәктәге уң һәм сул якларындагы биләмәләргә электән (ата-бабалары ханлык заманнарыннан ук) хуҗа булып, шуны сакларга һәм югалтмаска тырышулары, бәхәсләр чыккач Сахибгәрәй ханның тарханлык ярлыгын да дәлил итеп кулланулары шундый фикергә этәрә. Шул рәвешчә, күп санлы архив документларыннан һәм нәсел шәҗәрәләреннән Чулманның уң ягындагы Саралы, Татар Чаллысы, Турай, Бәзәкә, Әтәс, Тогыҗа, Татар Туембашы, Песәй авыллары белән Чулман аръягындагы һәм Ык елгасы буендагы Байлар, Илбакты, Сарайлы, Иман, Сарсаз Тәкермән, Иске Турай, Исламбакты, Мөшеге һәм башка шактый авылларның үзара бәйләнеше раслана. Чулман елгасының ике ягындагы ырудашлар биләгән һәм яшәгән урыннарда бертөрле үк елга-инеш һәм авыл исемнәре: Саралы, Чаллы, Турай, Дөреш, Сарсаз һ.б. булуы да әһәмиятле.

Үзләре Алабуга ягында яшәгән Мең ыруы бабалары Чулманның сул ягындагы җирләргә һәм гомуми озынлыгы 571 километрны тәшкил иткән Ык елгасы буйларында зур территорияләргә хуҗа булганлыгы бүгенге замандашларыбыз өчен ышанмаслык бер хәл кебек тоелырга да мөмкин. Ләкин татар тарихында бу ялгыз очрак кына түгел. Әлеге уңайдан Казан ханлыгы чорында Казан артында яшәгән татар тарханнарының Чулман аръягында зур мәйданнарны биләгән бүтән фактларны искә алып үтик. Мәсәлән, хәзерге Балык Бистәсе районы территориясендә борынгы Чаллы шәһәрчеге булганлыгы мәгълүм. Шул төбәктәге Күгәрчен исемле зур авылда яшәгән һәм ул тирәнең хуҗалары булган татар тарханнары Манашевларның ерактагы Кенәле елгасы буенда (Кинель, хәзерге Оренбург һәм Самара өлкәләрендә) шактый киң мәйданнардагы җир-сулары һәм урманнары булган. Әүвәлдән килгән биләмә хокукларын XVII гасырдагы рус патшалары заманында раслатып, бу төбәкнең тархан нәселләре, Кенәле буена күчеп, авыллар корганнар. Аларның берсе – хәзерге Самара өлкәсенең Похвистнёво районындагы данлыклы Гали исемендәге зур татар авылы. Әлеге Гали авылының борынгы бабалары Күгәрчен Манашевлары токымы булганлыгы архив чыганаклары һәм шәҗәрә язмалары белән дә раслана, анда хәзер дә Манашев фамилиясен йөртүчеләр бар[9].

Казан артында яшәгән татар аксөякләренең тагын бер нәсел-ыруы Чулман елгасының сул ягындагы Зәй, Шушма, Сок һәм башка елга буйларының хуҗалары булган. Казан ханы Мөхәммәдәмин исеменнән 1515 елда һәм Сафагәрәй исеменнән 1527 елның 17 май көнендә тарханлык ярлыклары бирелгән нәселнең дәвамчысы Нәдер Үрәзмәтев XVIII гасырда кардәшләре һәм ырудашлары белән бергә Әлмәт, Азнакай, Бөгелмә якларына күчеп, шактый татар авылларын нигезләгәннәр. Бу нәсел 1678 елгы исәп алу вакытында Адай авылында (хәзерге Кукмара районында) ясаклылар катлавында теркәлгән булуын ачыклап язган идек[10]. Әлеге мәсьәлә турында башка тарихчыларның хезмәтләрендә дә күп язылды.

Татар тарханнарыннан Манашев һәм Үрәзмәтев нәселләренең дә кайбер тармаклары ясаклы татар яки типтәр катлауларына язып йөртелгән. Ә аерым өлешләре, элекке биләмә хокукына ия кешеләр буларак, XVIII гасырдан алып «башкорт» катлавына кертелгәннәр. Ягъни Манашев һәм Үрәзмәтев нәселләренең тарихы Мең ыруы бабалары язмышына охшаш. ■

---

[9] Гали авылы тарихы / төзүчесе – Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2014. – 164 б.

[10] Мәрданов Р., Һадиев И. Нәдер Үрәзмәтев һәм аның нәселе // Хезмәт даны (Кукмара). – 2003. – 6, 10 сентябрь. Бу мәкалә русчага тәрҗемә ителеп, «Кукморский край» (Казан, 2008, 41-44 битләр) китабында да басылды.

КДУДА ТАТАР ФИЛОЛОГИЯСЕ, ТАРИХЫ ҺӘМ КӨНЧЫГЫШ ТЕЛЛӘР ФАКУЛЬТЕТЫ ОЕШУГА 30 ЕЛ

Милли күтәрелеш җимеше иде...

Тәлгат Галиуллин

Милли факультет... Ул, татарлар яшәгән төрле төбәкләрдән сәләтле балаларны җыеп, барча фәннәрне диярлек саф, үзебезнең Тукай телендә укыту турында ничә буын хыялланып, авыз суларын корытып йөргән бер мәлдә ачылып, дөрләтеп эшләп китмәсенме! Фани дөньядагы гомере кыска булса да, аның рухы йөрәкләрдә калды, кылып өлгергән гамәлләре легенда-риваятьләрдә, шунда чирканчык алган студентлар, укытучылар йөрәгендә әле дә яшәвен дәвам итә.

Ә аның тәварихы болайрак...

СССР дип аталган империянең юкка чыгуы, 19 миллион әгъзалы коммунистлар фиркасенең таралуы нәтиҗәсендә илдә демократик үзгәрешләр пәйда булуы буйсынган милләтләргә иркенрәк сулыш алырга, үз хокукларын даулап урамнарга, мәйданнарга ташып чыгарга мөмкинлек бирде. Узган гасырның сиксәненче еллар ахыры, соңгы унъеллыгы милләтебезне олуг мәсьәләләр тирәсендә берләштергән юнәлешләрне, киләчәк яшәешебез турындагы фикерләрне ачыклауны таләп иткән чор булды.

Тарихларында дәүләт төзүгә ирешә алмаган халыклар тулы мөстәкыйльлек алды. Русиянең кыл уртасында калган татарның алдынгы зыялылары, сәясәтчеләре ике хакыйкатьне ачык аңлады. Беренчесе – тамак ярып кычкырып, күкләргә кизәнеп, Мәскәү тарафларына йодрык күрсәтеп кенә күпкә ирешеп булмый. Бу – югалткан

Тәлгат Галиуллин, Ибраһим Нуруллин, Әмирхан Еники

дәүләтебезне кайтару турындагы изге хыяллар мавыктыргыч булса да, аны гамәлгә ашыру өчен көрәшү үзәкне котырту гына икәнлегенә төшенү иде. Икенчесе – сәяси дилбегәнең кыска вакытка гына булса да йомшаруыннан үз мәнфәгатьләребезгә файдаланып калу. Шуларның иң мөһиме – ул заманда кечкенә күренгән, бәяләп тә бетерелмәгән, чынлыкта үзаңлы балаларыбызны тәрбияләүдә караңгы төндә якты йолдыз булып балкыган татар факультетын булдыру иде.

1986 елда Алабуга пединституты белән саубуллашып, данлыклы Казан педагогия институтының урыс әдәбияты кафедрасында тыныч кына укытып, әдәби образлар дөньясында үземә юаныч табып, вакытлыча тулай торакта буйдак тормыш талгынлыгында хозурланып яткан бер көнне, төгәлрәге, 1988 елның язында КДУның укыту эшләре буенча проректоры Миркасыйм Госманов минем «эзгә төште». Ул әүвәл мине телефоннан тапты, ике көннән соң машинасын җибәреп, үз янына алдырды. Бу мине гафләт йокысыннан уятып, язмышымны үзгәртеп җибәргән вакыйга булды.

Миркасыйм Гәбделәхәт улы белән очрашкалаган булсак та, якын танышлыгыбыз турында мактанырлык мөхлислегем юк иде. Исәнләшеп, кул бирешкәч, ул: «Аргы урамнан әйләнеп, ләтчә сатып утырырга вакытым юк!» – диде дә ни өчен чакырганын әйтеп салды: «Сиңа белем биргән татар теле һәм әдәбияты бүлеген факультет дәрәҗәсенә күтәрү хыялыбыз бар. Анда татар теленә, мәдәниятебезгә, динебезгә якынрак башка белгечлекләрне дә ачып җибәрә алырбыз, дип хыялланабыз. Яңа берәмлекне оештырып аякка бастыру өчен, белемле, фәһемле, булдыклы кешеләр кирәк. Декан булырга теләүчеләр күп булса да, синең дә шул тирәдә, кул астында йөрүең лязим. Озакка сузмыйча, безнең урыс әдәбияты кафедрасына күч, мин анда синең өчен өстәмә профессор урынын булдырдым».

Факультетны оештыру менә шулай башланып китте. Тарих-филология факультетын өчкә бүлү һәм бигрәк тә 1944 елда ачылган татар бүлегенең статусын күтәрү буенча шактый катлаулы сөйләшүләр әүвәл ректорат утырышында, икенче көнне үк зур гыйльми советта каралды һәм фатиха алды. Яңа берәмлекнең исеме, белгечлекләре турында бәхәсләр шактый дәвам итте. Чит телләрдән төрек, гарәп лөгатьләре буенча махсус төркемнәр ачу да бәхәс уятмады. Үзе шунда туып-үскән кеше буларак һәм Кытайның киләчәк сәясәттә зур урын алачагын искәртеп, М.Госманов яңа факультетта кытай теле дә укытылачак, дип белдерде. Үзе шуннан белгечләр, берничә гаилә китертеп, алар өчен Совминнан капчык-капчык дөге дә юнәтте. Алдан килешү буенча, яңа берәмлекнең озынрак булса да, мәгънәле исеме дә расланды: «Татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләр факультеты». Мине декан һәм яңа ачылачак методика кафедрасының мөдире итеп, ул чордагы ректор А.Коновалов тәкъдим итте, академик И.Таһиров һәм башка чыгыш ясаучылар да хуплап чыкты.

Гыйльми советта мин бертавыштан декан итеп сайландым һәм эшкә керештем. Унике ел (1989-2001) дәвамында вазыйфаларымны хәлдин килгәнчә тырышып, яратып башкардым. Инсульт китереп бәргәч кенә, декан вазыйфаларын И.Гыйләҗевкә тапшырып, әүвәл кафедра мөдире, соңрак профессор булып калдым.

Деканат беренче мәлне факультет тормышы, фәнни юнәлешләре белән җитәкчелек иткән штабка әйләнде. 1989 елның мартыннан эшли башлап, шул елны ук беренче студентларны кабул иттек. Урынбасарларым итеп, әдәбият галиме Таһир Гыйләҗев һәм тарихчы Альта Мәхмүтова билгеләнде, «диспетчер» вазыйфасына татар һәм рус телләрен камил белгән Нурия Мөхәммәтшина тәгаенләнде.

1994 елда КДУдагы татар бүлегенең илле еллыгын зурлап уздырдык. Урыс әдәбияты, галимнәр язганча, Гоголь «шинеленнән чыкса», татар сүз сәнгате татар бүлегенә бурычлы. Ә инде яңа факультет чын мәгънәсендә милли күтәрелеш,

уяну җимеше булды. Татар теле, әдәбияты, гомумән, филологиясе факультетлары, бүлекләре Алабугада, Чаллыда гына түгел, Уфа, Стәрлетамак, Төмән, Тобол, Ижевск, Оренбург һәм Мәскәү шәһәрләрендәге мәртәбәле уку йортларында да ачылып, алар югары белемле укытучылар, журналистлар, җәмәгать эшлеклеләре әзерләүгә керештe. Арча, Минзәлә, Тәтеш, Чистай төбәкләрендә эшләп яткан педучилищелар турында әйтеп тә торасы юк. КДУның татар факультеты шуларның барысы өчен дә гыйльми-методик үзәк, сыену, киңәш-табыш итү үзәгенә әйләнде.

Татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләр факультеты гадәти генә берәмлек түгел иде. Демократик үзгәреш, яңарыш чорында ул халкыбызның киләчәк үсеш, аң-белем дәрәҗәсен күтәрү, яңа буын зыялыларын әзерләү үзәге буларак кабул ителде. Төрле төбәкләрдән, ерак районнардан методик ярдәм сорап килүчеләрнең иге-чиге булмады. Аның абруен инде бакыйлыкка күчкән профессорлар Д.Тумашева, М.Госманов, В.Хаков, Ф.Хисамова, Ф.Сафиуллина, хәзер дә исән-имин хезмәт итүче Ф.Юсупов, Ф.Галимуллин, М.Бакиров, Х.Миңнегулов, Р.Юсупов кебек фән докторлары, кандидатлары күтәрде. Факультет галимнәре һәм студентлары барысы да алтын балык, кош тоткандай очып йөрде. Нинди милләт кешесе булуына карамастан, көндәлек аралашуда «Татфак» дип атап йөрткән үсмеребез, әкияттәгечә, төн үсәсен көнгә ялгап, дәрелфөнүнебез ректорының, милләтнең җылы карашын, ара-тирә матди ярдәмен дә тоеп (шул исәптән Төркиянең), уку йортыбызның иң эре вә абруйлы факультетларының берсе дәрәҗәсенә күтәрелде.

Татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләр факультеты КДУның иң куәтле юрфагы белән «син» дип сөйләшә алды, үзешчән сәнгатьтә, спортта алдынгы сафка күтәрелде. Әлбәттә, иң зур күрсәткеч – студентлар санының елдан-ел арта баруы, конкурсның бер урынга биш-алты кешегә кадәр җитүе иде. Җөмләдән, 1992 елда бюджетлы урынга 100 талиб-талибә кабул иттек, читтән торып укучыларның санын гомумән чикләмәделәр. 150 кешедән артыграк балага студент билеты тапшырган елларыбыз тарихыбызның иң бәхетле сәхифәсе иде. Бер елны (ялгышмасам, 1995 елда бугай) факультетта уку өчен урын алуга дәгъва итә алган, ягъни тиешле баллны җыйган 20 балага урын җитмәде. Ректорат та өстәмә урыннар белән тәэмин итә алмады. Татар теле һәм әдәбияты буенча белем алу хыялы белән килгән егет-кызларны кире тарату гафу ителмәслек гамәл булыр иде. Кабул итү комиссиясе рәисе Флера Ганиева белән, киңәш, ярдәм сорап, үзебезнең Мәгариф министрлыгына, аерым алганда, министр урынбасары Флера Илдархановага мөрәҗәгать иттек. Бергәләп, төрле мөмкинлекне эзләдек, Казан, Алабуга, Чаллы югары уку йортларына тәкъдим ясап карадык, аларның да буш урыннары, табигый ки, калмаган иде. Бу «авыр» хәлне мин татар халкы ирешкән, телебезнең абруе иң югары ноктасына күтәрелгән бәхетле еллар дип саныйм. Ахыр чиктә министрлык (ул чорда министр булып милли җанлы Васил Гайфуллин эшләде): «Студентларга – стипендия, укытучыларга сәгатьләп хезмәт хакын түләүне үз өстебезгә алабыз. Сездән аудиторияләр һәм педагоглар белән тәэмин итү сорала», – дип, уңай җавап бирде.

Әлеге студентларны уку-укытуны, яшертен-орынтын диярлек, факультет урнашкан уку бинасының 11-13 катларында кичләрен оештырдык. КДУ администрациясе, бу хакта белсә дә, моны күрмәмешкә салышты. Ә икенче елны аңа махсус бина бирелеп, бер-ике ел көллият статусында йөргәч, ул бар фәннәрне дә (рус һәм инглиз телләреннән башка) татар телендә укыта торган Гуманитар институт дәрәҗәсенә күтәрелде. Институт ун елдан аз гына артык гомере дәвамында берничә мең белгеч әзерләп калырга өлгерде.

Ул чорда укыган студентларның сәләтенә, кыюлыгына, үзләрен яклый алуларына, бердәмлекләренә шаккатырлык. 1990 нчы еллардагы шикелле әзерлекле, милли рух-

Рифат Сверигин, Тәлгат Галиуллин, Рәдиф Җамалетдинов, Рүзәл Йосыпов, Мирфатыйх Зәкиев, Марсель Бакиров

лы һәм тәвәккәл татар студентлары булмагандыр һәм киләчәктә андый шәкертләрне тәрбияләрлек вазгыятьнең янәдән кайтуына ышанып та булмый.

Факультетның иң кыю студентларының берсе (хәзер ул Йошкар-Олада татар иҗтимагый үзәге лидеры) Рамай Юлдашевны (кушаматы – «Татар Чапае») Ирек мәйданында, Ленин бабай һәйкәле тирәсендә тулы мөстәкыйльлек таләп иткән өчен кулга алалар. Бу хәбәр факультетка яшен тизлегендә килеп җитә. Егетнең фикердәшләре, дуслары, бүлмәдән-бүлмәгә йөреп, студентларны митингка чакыралар. Кыскасы, факультетның бар булган егетләре-кызлары, дәрескә киләсе урынга, Ирек мәйданына, опера һәм балет театры каршына җыела. Мин иртән ректорат утырышында идем, аннан чыгып, икенче уку бинасының унберенче катына күтәрелсәм, гадәттә тәнәфес вакытында умарта күче кебек гөжләп торган коридорда үлем тынлыгына тап булдым. Ишек төбендә милиция полковнигы көтеп тора икән, ул мине шунда алып китте. Моңарчы студентларымның шулай колонна булып тезелеп торганнарын күргәнем булмады, араларында армиядә хезмәт итеп кайткан егетләр дә шактый иде. 600дән артык студентның шулчаклы төз, матур итеп сафка басып, иптәшләрен азат итүне таләп итүләрен күреп шатланырга да, ахыры нәрсә белән бетәсен чамалаганга, кайгырырга да белмичә, сокланып басып торам. Сөйләшү дә, көлешү дә ишетелми... Сәер тынлык. Менә алар – милләт балалары, халкыбызның йөзек кашлары, хакыйкый байлыгыбыз, дип озаклап сөенеп тора алмадым, полковникның егетегезне төштән соң чыгарабыз, дигән вәгъдәсеннән соң унберенче катыбызга юл тоттык.

XXI гасыр башында сәяси вазгыять үзгәргәч, татар факультетын күпсенү, һәр адымда рәнҗетү, хәтта «талау» башланды. Аерым алганда, «востоковедение»не торгызабыз, дип, чит телләр өйрәнүче бүлекне тартып алдылар, студентларын да шунда күчерделәр. Ә бит яңа факультетны безгә бәйләнмичә дә, мөстәкыйль рәвештә дә ачып була иде. Аннан татар теле, әдәбияты белгечлегенә ихтыяҗ кимеде, дигән сылтау белән кабул итүнең санын киметү башланды. Ректораттагы төп терәгебез М.Госманов та Фәннәр академиясенә эшкә күчте.

КДУның татар факультеты җиһанда нибары 20 елдан аз гына артык яшәп калды. Олы тарих өчен кыска вакыт аралыгында да ул халкыбызга, телебезгә, мәдәниятебезгә тугрылыклы фидакарь белгечләр, укытучылар, язучылар, белемле журналистлар, күп телләр белгән айдыннар, кыскасы, чын татар зыялыларын әзерләп калдырды. 2011 елда аны күпсенделәр һәм үзебезнең милләт кешеләре юкка чыгардылар. ■

Дон казаклары һәм татарлар

Илнур Газизуллин*

Полина Чернышова һәм Евгений Ткачук «Тихий Дон» сериалын төшергәндә. Фото ruskino.ru сайтыннан алынды

«Казак» терминының килеп чыгышы турында фәндә берничә фараз бар. Урта гасырларда «казак» сүзен, кагыйдә буларак, буйдак, ялгыз кешеләргә карата әйткәннәр. Бу төшенчә белән төрле сәбәпләр аркасында үз «социумыннан» аерылган, берәр хөкүмәт кул астыннан чыккан кешене дә атаганнар.

Алтын Урда һәм соңрак барлыкка килгән төрки дәүләтләрдә «казак» төшенчәсе акчага яллана торган гаскәриләрне яисә «дала рыцарьлары»н белдергән. Ә инде XVI-XVII гасырларда кыргый далада «казаклар» дип төрле качкыннарга (алар арасында рус крестьяннары да булган) әйткәннәр. Бары тик XIX-XX гасырларда гына казак катлавына (сословиесенә) кергән кешене шул исем белән атый башлыйлар. Бу чорда «казак» дип Россия империясенә хезмәт иткән иррегуляр сугышчылар аталган. Алар атлы гаскәр һәм атлы артиллериядә хезмәт иткән.

Күптән түгел музей эшләре белән Вешенская станицасында өч көнлек командировкада булырга туры килде. Бу мәкаләдә Казан татарлары һәм Дон казаклары этнографиясенең кыска арада ясалган чагыштырмача анализын сезнең игътибарга да тәкъдим итәргә булдык.

***

Татарларда «казак» сүзе белән бәйле ике сүзтезмә еш кулланылышта йөри: «атлы казак» һәм балалар уены – «казаки-разбойники». Аңлашыла ки, «атлы казак» – фразеологик берәмлек, мәгънәви җәһәттән казакка бераз тискәре карашны, кешенең түземсезлеген белдерә. Мәсәлән: «Нигә монда атлы казак кебек биеп (яки басып) торасың?» – диләр. «Казаки-разбойники» уенында да балалар ике командага бүленә: берсе – «казаклар», икенчесе – аларны тотучылар. Биредә дә казакларга тискәре мөнәсәбәт бар.

---

*Илнур Газизуллин – этнограф-тарихчы, ТР Милли музееның этнография бүлеге мөдире

Татар галимнәренең хезмәтләреннән казак тормышына һәм татарларга кагылышлы берничә кызыклы факт ачыкланды. Әдәбият галиме Марсель ага Әхмәтҗанов фикеренчә, XVII гасырда да рус патшалары казакларга хатларны татар телендә язган. Тарихчы Фәйзелхак Ислаев та М.Шолоховның «Тын Дон» романыннан төрки этнография элементларын шактый күп таба. (Романны редакцияләгәнче, анда төркитатар сүзләре тагын да күбрәк булган, дип фаразлана.) Журналист Илдар Кыямов КДУда укыганда «Тын Дон» романын өйрәнеп, анда мишәр һәм казаклар өчен уртак этнографик һәм филологик берәмлекләрнең бик күп икәненә игътибар иткән.

Бу командировкада безгә төрле тарихи урыннарны – М.Шолохов музей-тыюлыгын, шәхси «Казак тарихы» музеен, «Урта хәлле казак утары» музей комплексын һәм 2015 елда режиссер Сергей Урсуляк «Тын Дон»ның соңгы версиясен төшергән Еланская станицасын күрергә насыйп булды.

Иң беренче күзгә ташланганы – казакларда җир күп. Йортлар, Казан арты татарларыныкы белән чагыштырганда, аеруча иркен утыра. Хезмәт иткән өчен, патша казакларга җир биргән. Басулары – киң, дала табигый зонасы исә акрынлап чүлгә әйләнеп бара. Без ишетеп белгән «кыргый дала» шушы җирләр буладыр инде.

Тору урыннарының атамасы безнең яктагы терминнардан аерыла. Бездә авыл, шәһәр булса, аларда – *станица.* Иң зур торак урыны булган Вешенская станицасында 10 меңләп кеше яши. Станица – «ыстан» төшенчәсеннән, ул фарсычадан тору урыны дигән сүз. Татарстан, Башкортстан, Үзбәкстан кебек атамалар да шуннан ясалган. «Хутор» термины исә татарның «утары» белән тәңгәл килә. Иң беренче булып аерым хуҗалык килеп төпләнә. Соңрак исә, берничә хуҗалык тупланып, кечкенә авылга әйләнә. Һичшиксез, бу төшенчә төрки-татар тамырдан чыккан.

Тораклар. Беренчедән, «мазанка» атамасын алыйк. Бу иң гади тору урыны: башлап тал чыбыкларыннан читән үрелә. Казаклар аны «краснотал» диләр. Бу да безнең «тал» сүзенә якын. Соңрак ул кызыл балчык белән сылана, киптерелә һәм агартыла. Кагыйдә буларак, түбә җирле табигый материал – камыш белән каплана, бездә исә юкә кайрысы яисә салам кулланылган.

Зуррак йортлар *«курень»* дип йөртелә. Казаклар, бу термин белән аеруча кызыксынып: «Татар телендә моңа охшаш сүз бармы?» – дип сорадылар. Шунда хәтергә татар теленең *«каралты, кура җиләге, каралты-кура, курай»*лары искә төште. Барысы да әйтелеш буенча охшаш һәм коры үсемлеккә ишарә ясый. Фәнни әдәбиятта «курень» термины урыс теленә монголлардан кергәнлеге турында мәгълүмат бар. Аларда ул гаскәр ыстанын аңлата. Без нәкъ шундый йортта – кунакханәдә яшәдек. Түбәләр – дүрт кыеклы. Мәгълүмдер ки, кайбер татар авылларында, аеруча Сергач мишәрләре йортны дүрт кыеклы түбә белән каплыйлар. Гадәттә, һәр казак өендә дә тәрәзә капкачы – ставни бар. Казаклар моны: «Бездә җәйләр бик эссе, өй эче җылынмасынга, без аларны ябабыз», – дип аңлата. Казан арты татарларында, сирәк булса да, тәрәзә капкачлары очрый, ә элек алар һәр йортта диярлек булган. «Курень» дип аталган бу йортлар гадәттә ике катлы. Казакларның тыштан тәрәзәләр буйлап эшләнгән үзенчәлекле верандалары да бар. Казаклар аларны «балясины» дип атый («балякать» – «сөйләшү» дигән сүздән). Бу исә элекке баерак татар өйләрендәге «болдыр»га бик якын.

Интерьер (йорт эче). Мичләре урысныкына охшаган, татар миченә караганда зуррак. Чаршау белән капланган ятагы бар, мичләрендә татарлардагы кебек казан юк. Мич алды зур, аста урын күп. (Элек татарларда да шулай иде). Анда төрле кирәкяракны урнаштырырга була (мәсәлән, утын, чүлмәкләрне). Җәй көне ашарга ишегалдында пешерәләр. Татарларда җәйге ашханә сирәк очрый. Иң кызыгы – җәйге кух-

Курень

няда кулланылган савыт казакларда да казан дип атала, рус телендәгечә *котел* дип түгел. Шулай ук, мич алдында өч аяклы «казанок» та тора. Бу әйбер татар «өчаяг»ына тәңгәл килә.

Безне йөрткән казак «поземка» сүзен искә алды. Аның аңлатуынча, бу термин бинаны идән астыннан җылытуны аңлата. Үзебез күрмәдек, ләкин бу гаять үзенчәлекле күренеш. Билгеле булганча, Болгар һәм Биләрдәге җәмәгать мунчалары җир асты мичләре белән төзелгән. Аларны тыштан якканнар, төтен һәм җылы һава идән астындагы махсус каналлар буйлап барган.

Казакларның кухнясын, милли ризыкларын, ашамлыкларын өйрәнгәндә дә, күп уртаклыклар барлыгы ачыкланды. Мәсәлән, «каймак» атамасы татарныкына тәңгәл, ләкин казаклар аны мичтә тоталар. Этнографик белешмә – сүзлектән *«сөзмә»*, *«әйрән»* сүзләренең дә казакларда булганы ачыкланды. Шулай ук алар, ат итен бик яратып ашый. Ник дигәндә, ат ите – ут-күршедә генә яшәгән калмыкларның милли ризыгы. Ә менә Мәскәү ягындагы урыслар ат итенә бераз җирәнеп карый.

Казакларның антропологик типлары. Фотографияләрен карагач һәм казакларның үзләре белән аралашканнан соң, шундый нәтиҗә ясарга була: казаклар – бик тә матур халык. Аларның ир-атлары чандыр гәүдәле, озын буйлы, чәч-сакаллары кара. Төркиләрдәге «кылыч борын» (бу инде һич кенә дә славян тибы түгел), «карчыга борын» бик еш очрый. Борын яфраклары бик тә нечкә, нәфис. Чәчләре күбрәк көдрәләнеп тора.

Микротопонимнар. Татарларга аңлаешлы булганнары – Такмаково, Казанская станицалары, Казанка елгасы, Крутой Яр дигән урын һ.б. Бу әле безгә юлда яисә музейларда очраган атамалар гына.

Үзаңнары (самосознание). Казаклар көндәлек тормышта үзләрен урыслардан аералар, сөйләмдә аларны «кацап» дип әйтергә мөмкиннәр, ә күршедә яшәгән украиннарны «хохол» дип йөртәләр. Аларга күп тапкырлар: «Сез нинди милләт соң?»– дип сорау биргәләдек. Казаклар бу сораудан бераз югалып калды һәм: «Без бит төрледән җыелган халык һәм күбрәк катлау (сословие) дип карарга кирәктер», – дип аңлата башладылар. Бары тик музей хезмәткәре генә: «Казаклар – урыс милләтенең аерым

Курень интерьеры

субэтносы, димәк, урыс халкының бер кисәге», – дип шәрехләде. Аңлашылганча, бу рәсми кеше җавабы иде.

М.Шолоховның «Тын Дон»ында ике кеше аралашканны искә төшерик. Берсе: «Казаклар кемнәр алар?» – дип, сорау бирә һәм үзе үк: «Казаклар урыс түгел!» – дип әйтә. Шунда бер коммунист: «Күбрәк ирекә качкан урыс крестьяннары!» – дигән фикерне белдерә. Алда китерелгән уртаклыклардан чыгып фикер йөртсәк, казаклар төрки тамырдан чыккан, дип уйларга нигез бар. Мәшһүр М.Шолохов моның шулай икәнен белгәндер, ләкин «урыс милләтеннән» дигән версияне алга сөрүе Сталин чорында казакларны кырылып бетүдән коткарырга тырышудан булгандыр, дип фаразларга мөмкин.

Казакларның җырлары, көйләре. Казак җырларын, көйләрен аңлар өчен, аларны тыңларга кирәк. Озын көйле җырлар күп, шулай ук күптавышлы җырлары да шактый. Музыка коралларыннан барабан, тромбон, сыбызгы киң кулланыла. Бик тә үзенчәлекле, сугышчан, маршка охшаган, гаскәри, шул ук вакытта ниндидер «драйв», көч бирә торган музыка! Көйләрдә дала мотивлары да сизелә. Әмма, нихәтле генә тырышсак та, татар көйләре белән турыдан-туры параллель табып булмады. Фәкать: кара козгын («Черный ворон») һәм камыштан күпер салу («Мосты из камыша») турындагы ике җырда гына охшаш эчтәлек-мәгънә очрады.

ТР Милли музее фондында кызыклы экспонат саклана. Кер юу өчен кулланыла торган кырлы бәләкнең ике ягына да, уеп, гарәп хәрефләре белән татарча җыр сүзләре язылган:

«Без китәбез, сез калырсыз,
Камышлардан басма салырсыз
Һәм сагынып җылап калырсыз».

Шул ук мәгънәви сүзләр казакларның җырында да кабатлана. Бу җырда сюжет түбәндәгечә: казаклар сугышка китә һәм үзләрен озатучы кызларга: «Из камышей построите мост...» – дип әйтеп калдыралар.

Биредә яшәүче казаклар өчен камыш ягулык та, төзү чималы да булып хезмәт

итә, ул аларда биегрәк тә булып үсә. Аның белән йорт түбәләрен каплыйлар, бездә исә камыштан намазлык үрәләр. Ә менә «Камышлардан басма салырбыз» дигән мотив татар җырларында, күбрәк сугышка-армиягә китүчеләр репертуарында очрый. Әлеге мотивны казаклар кайдан алды икән? Әллә инде бу борынгы төрки дөньядан киләме?!.

Икенче җырда – казак һәм татар халкы өчен уртак булган «козгын» («черный ворон») образы. Бу инде бик популяр «Черный ворон» җыры. «Казаклар өчен козгын тискәре образмы?» – дип сорагач: «Юк!» – дигән җавап ишеттек.

Ә менә татар халык авыз иҗатында «козгын» образы заманында бик тә киң таралган, популяр булган. Мәсәлән, Марсель Әхмәтҗанов бу темага «Мәдәни җомга» газетасында берничә мәкалә язып чыкты. Хәзерге көндә дә татарлар козгыннан курка, янәсе, ул – начар хәбәр китерүче кош. Галим, төрле төбәкләрдә дә яшәүче татар халкының, шулай ук Польшада һәм Себердә яшәгән милләттәшләре – безнең фольклор материалларын кулланып, шундый нәтиҗәгә килә: борынгы заманда козгын фани һәм бакый дөнья арадашчысы булган. Грек мифларын искә төшерегез – Аполлонның җилкәсенә гел козгын утырып йөри. Галим үз мәкаләсендә төрки дөньяда XVIII гасырда популяр булган легендар Афрайсан хан турындагы риваятьне искә ала. Бу хан, Сөләйман пәйгамбәр кебек үк, кош-корт телен аңлаган һәм үзенең хөкүмәт эшләрен акыллы сәркатибе Козгын ярдәмендә башкарган. Нәтиҗә ясап, козгынның татар һәм казак мәдәниятендә охшаш образ икәнен әйтергә кирәк. Ә сораулар ачык кала. Бу образны казак кайдан алган? Күчеш процессы кайсы чорда булды икән?

Киемнәре. «Безнең кием көнчыгышныкы», – ди казаклар. Кавказ янәшә, хатыннарны шуннан урлаганбыз, шуңа күрә киемнәребез Кавказ халкыныкына охшаган, дип аңлаталар. Безнең уйлавыбызча, монда да төрки халыкларның тәэсире сизелә.

Татар һәм казак киемнәрендә тагын берничә охшаш күренешне атап үтик. Этнограф күзлегеннән караганда, казакларның «папаха»лары безнең татар «кара бүрегенә» тәңгәл килә. Казак хатын-кыз күлмәгендә дә татар хатын-кыз кияме белән кайбер охшашлыклар бар. Мәсәлән: бала итәк.

Ә менә аларның бер кием детален – *«шлычка»*ны аерып әйтәсем килә. Үзенчәлекле чәч каплавычы (чәч-толым каплавычы) шулай дип атала. Бу элемент татар калфагына бик тә якын. Ничек кенә булса да, аларның функцияләре бер – хатын-кызның чәч толымын өлешчә каплау. Шлычканы казаклар башлык сүзенең (ягъни «башлычка»ның) кыскартылган формасы дип аңлата. Ә ул, берсүзсез, төрки атама дип санала.

«Тын Дон» фильмын янә искә төшерик. Анда шундый күренеш бар: печән өстендә хатын-кызлар авызларын яулык очы белән каплый. Кайчандыр безнең татар әбиләре дә, ә элегрәк кызлары да чит кеше янында үзләрен нәкъ шулай тота иде. Казак хатын-кызы киемендә «кубелек» (күбәләк?) дигән элемент та бар. Бу – бала итәкле күлмәккә кагылышлы термин. Тагын бер зур охшашлык – күн итекләре төркичә каеп ясала, нәкъ татарлардагы читек яисә тула оек каю кебек үк.

Болар барсы да казакларда төрки тамырлар бик тирән икәнен ачык күрсәтә, казаклар белән татарларның тыгыз бәйләнештә яшәвенә зур дәлил булып тора.

***

Казакларда шундый риваять сакланган. Имеш, XVI гасырда Явыз Иван тарафыннан Казан каласы басып алынганда, яуда 10 мең казак гаскәрие катнаша (шул ук күләмдә Шаһгали сугышчылары да, димәк, үзебезнең татарлар да һөҗүм итә). Риваятьтә атаман Ермакның татар телен белгәнлеге дә әйтелә. Ул, татар киемен киеп,

Казак хоры. Алгы рәттә мәкаләнең авторы – этнограф Илнур Газизуллин

Казан каласына үтеп керә һәм үзенә күрә «разведка» ясап чыга, русларга шәһәрнең нык булмаган җирләрен күрсәтә. Ермакның татар булуы турында тарихчылардан да фаразлар ишетелгәләде. Мәшһүр тюрколог Л.Р.Кызласов та «атаман Ермак себер татарларыннан булган», дигән фикерне әйтә. Моны лингвистик тикшеренүләр дә куәтли. Мәсәлән, татарда казакка охшаган кешегә «Ярмәк» дигән кушамат тагыла. Ул сугышчан, ваемсыз, курыкмый торган, дигәнне аңлата. Монда Киров өлкәсенең Малмыж районындагы Иске Йөрек авылында шундый сыйфатларга ия «Ярмәкләр» нәселен дә атарга була.

Берничә ел элек атның татарлар тормышында тоткан урыны турында телевизион сюжет төшерергә туры килде. Кайчандыр «галәмне дер селкеткән» халкыбызның хәзерге заманда тынычланып һәм юашланып калуына атның көнкүрешебездән юкка чыга баруы сәбәп түгелме икән, дигән фикер әйтелде анда.

Тарихта билгеле: бабаларыбызда сугыш эше бик югары дәрәҗәдә куелган. Гаскәриләрне сугышка әзерләү методикасы да булган, әмма без инде боларны, тарихи сәбәпләр аркасында, биш гасыр элек үк югалтканбыз. Ә менә казакларда бу ысуллар элекке чордагыча ук сакланган, дип уйларга нигез бар. Борынгы гаскәриләребездәге сугыш техникасын өйрәнергә теләсәк, һичшиксез, казаклар тарихына мөрәҗәгать итәргә була!

Иппотерапия дигән заманча дәвалау ысулы да бар. Начар хәрәкәтләнә торган балаларны атка утыртып йөртәләр һәм шулай дәвалыйлар. Татарга да әлеге ысулны үзләштерү вакыты җитмәдеме икән? Казаклар әле атны югалтып бетермәгән һәм без бу эштә дә алардан күп әйбергә өйрәнә алыр идек.

Тагын бер өстәмә: хәзерге көндә татар казаклары, нагайбәкләр мәсьәләсе дә актуаль булып кала. Оренбург, Урал татар казакларында ватанпәрвәрлек хисләре уяна башлады. Алар үз тарихларын барлый, бу хакта махсус хезмәтләр яза. Кыскасы, үзебезнең татар казаклары тарихын, мәдәниятен өйрәнгәндә дә Дон буе казакларын истә тотарга һәм төрле чагыштырулар ясарга кирәк. ■

КАЗАННЫ ДАНЛАУЧЫ ШӘХЕС

Әгъзам Фәйзрахманов

Мөгаен, Камил Исхаковны Казанда белмәгән кеше юктыр. Андыйлар булса да, бик сирәктер. Камил Шамил улы 17 елга якын Казан мәры булып эшләде. Моннан егерме ел элек, мәрга 50 яшь тулган көннәрдә, аның эш бүлмәсендә әңгәмә корып утырганда: «Сез, мөмкинлек бирелсә, яшәү өчен дөньяның кайсы шәһәрен сайлар идегез?» – дип сораган идем.

– Мин бары тик Казанда гына яшәргә телим, ул минем өчен иң кадерле шәһәр, – дигән җавап ишеттем.

Моны аңларга да була. К.Исхаков биредә туып-үскән, белем алган, һөнәр үзләштергән, хезмәт юлын да биредә үткәрә. Дөрес, бераз соңрак Мәскәүдә дә, Ерак Көнчыгышта да, Согыд Гарәбстаны корольлегенең Җиддә шәһәрендә дә эшләп алырга туры килде аңа. Күрәсең, язмышында шулай язылган булгандыр. Әмма ул, ахырда, барыбер туганнары, дуслары, ватандашлары янына кабат Казанга кайтты.

Олыгая барса да, Камил Шамил улының гәүдәсе әле дә егетләрнеке кебек төз, ул бик хәрәкәтчән, йөзеннән елмаю китеп тормый. Мөгаен, бу Исхаковның гомер-гомергә спорт белән дус булуы нәтиҗәседер. Казанның 38 нче мәктәбендә укыганда ук тренер

Татарстан Югары Советы депутаты, студент Камил Исхаков лекция вакытында

Станислав Исаев җитәкчелегендә спорт гимнастикасы күнекмәләрен үзләштерә ул. Университетта укыганда СССРның спорт мастеры программасы буенча ярышларда катнаша. Татарстан чемпионатларында алдынгы урыннарны яулый.

Камил Исхаков хәзер дә, буш вакыты булуга, чаңгыга баса, спорт залында буыннарын яздыра, ә җәйге ял вакытларында, акваланг киеп, диңгезгә чумарга ярата. Ул Казанда үткәрелә торган зур ярышларны карамыйча калдырмый. Казанны хаклы рәвештә Россиянең спорт башкаласы дип йөртәләр. Моның өчен ныклы нигез нәкъ менә К.Исхаков шәһәр мэры булып эшләгән чорда салынды. Кайсы гына спорт корылмасы төзелешенә барсаң да: «Монда прораб Исхаков үзе!» – дигән сүзләрне ул елларда еш ишетергә туры килә иде.

Күп балалы эшче гаиләсенә хас булганча, Камил кечкенәдән үк хезмәт итәргә күнегә. Әтисе Шамил абый шофер иде. Хәтерлим әле, 70 яшенә кадәр йөк машинасын йөртте ул. Соңгы елларда да өйдә утырмады. Яңа Савин бистәсендәге бер мәхәлләне («Казан нуры» мәчетен) җитәкләде. Мәчет бик зур булмаса да, борчу-мәшәкатьләре җитәрлектер, шәт. Камилнең әнисе Илһамия тегүче иде. Бу һөнәре аңа, билгеле инде, дүрт баласына өс-баш киемнәре юнәтергә ярап куйгандыр.

Гаиләдәге икенче бала – Камил Исхаков – уналты яшендә үк Куйбышев исемендәге химия заводында элемтә монтеры булып эшли башлый, бер үк вакытта эшче яшьләр мәктәбендә белем ала. Аннары элемтә электротехникумын, Казан дәүләт университетының физика факультетын тәмамлый. Нәкъ менә студент елларында Камилнең тормышын физика законнарыннан читкәрәк этәреп җибәрүче бер вакыйга була. Студент Исхаковны Татарстан Югары Советы депутаты итеп сайлыйлар. Мондый уй кемнең башына килгәндер һәм ни өчен нәкъ аның кандидатурасына тукталырга булганнардыр? Хәзер моны ачыклавы авыр. Әмма бу кешенең геннарына оештыру сәләте салынуын ул чагында төгәл сиземләгәннәр, күрәсең.

Университетны тәмамлагач, яшь белгечкә оештыру-тәрбия эше тапшырыла. Ул си-

К.Исхаков «Шәһри Казан» газетасы редакциясендә

гез ел дәвамында комсомолның Совет райкомында беренче секретарь вазыйфасын башкара. Аннары, «Алгоритм» берләшмәсендә фәнни-укыту үзәге директоры урынбасары, директоры, хисаплау техникасы һәм информатика фәнни-тикшеренү берләшмәсендә генераль директор буларак, кешеләр белән эшләү, оештыру, җитәкчелек итү тәҗрибәсен чарлый. Үсеш баскычлары да дәвам итә. КПССның Совет райкомының беренче секретаре булып бер ел эшләп алгач, 1989 елда Шәһәр Советы башкарма комитеты рәисе камытын кия. 1991 елда исә Казан шәһәр хакимияте башлыгы итеп билгеләнә.

Миллионнан артык кеше яшәгән шәһәрнең хуҗасы булу җиңел эш түгел. Җитмәсә, Казан – бөтен татарның мәркәзе дә бит әле. Милләттәшләребез Казанны, милли мәдәниятебезне, милли ашларыбызны сагынып кайта. Андый милләттәшләребезгә кадер-хөрмәт күрсәтү шәһәр мэрының турыдан-туры вазыйфасына кермәсә дә, кемнең инде кунаклар алдында йөзен кызартасы килсен! Хуҗа кешенең бигрәк тә инде. Казанда республика, Россия, Европа, дөнья күләмендәге киңәшмәләр, симпозиумнар, спорт ярышлары да даими үткәрелә. Шәһәр башлыгы бу эшләрдән һич кенә дә читтә кала алмый инде.

К.Исхаковка шәһәр белән җитәкчелек иткән чорда кунаклар алдында кызарырга туры килмәде. Шәһәребез төзекләндерелде, матурая төште. Татар дәүләт академия театры, тимер юл вокзалы, Зур концерт залы кебек уникаль корылмалар – башкалабызның горурлыгы. Аларны бераүгә дә күрсәтергә оят түгел. Казан шәһәренең 1000 еллыгын үткәрүдә дә, метрополитен төзи башлауда да Камил Исхаков инициатор булды.

Камил Шамил улы башкалабызда чыгып килүче «Шәһри Казан» һәм «Казанские ведомости» газеталарын оештыручы буларак та тарихка кереп калды. Редакцияләргә биналар, җиһазлар табуда, финанслауда күп көч куярга туры килде аңа. Мэр булып эшләү чорында К.Исхаков шәһәр газеталары редакцияләрендә даими булды. Гадәттә очрашуларны ул: «Сезне тыңларга килдем. Эшегездә нинди авырлыклар бар? Нинди мәсьәләләрне бергә хәл итәргә кирәк? Бәлки бу очрашу тормышыгызны бераз җиңеләйтергә булышыр!» – дигән сүзләр белән башлый иде.

Ерак Көнчыгыш федераль округына вәкаләтле вәкил итеп билгеләнеп, Мәскәүдән кайткан көнне Казан аэропортында К.Исхаков бу язманың авторына интервью биргән мәл. Ноябрь, 2005 ел

Журналист булып эшләү чорында миңа К.Исхаков үткәргән чараларда күп тапкыр катнашырга туры килде. Район хакимияте башлыкларына хөрмәт белән каравы һәрвакыт сизелеп торды. Ул еш кына: «7+Я – одна семья», – дип әйтергә яратты. Мөгаен, бу сүзләргә бераз аңлатма биреп китәргә кирәктер. Шәһәрдә җиде район бар. Шул җиде районның башлыкларына Исхаковның үзен дә өстәгәч, «Семья», татарча әйткәндә «гаилә» килеп чыга. Ә гаиләдә барлык эш бергәләп, киңәеп башкарыла. Шунсыз җитештерүне арттыру, хезмәт ияләренең тормыш дәрәҗәсен күтәрү, халыкның аз тәэмин ителгән катлавын социаль яклауны гарантияләү кебек мөһим мәсьәләләрне хәл итеп булмый шул.

Камил Исхаков 2005 елның 14 ноябреннән 2007 елның 2 октябренә кадәр Россия Федерациясе Президентының Ерак Көнчыгыш Федераль округындагы вәкаләтле вәкил вазыйфасын башкарды. Әлбәттә, шундый еракта, бөтенләй таныш түгел урында эшләү җиңел булмагандыр. Хәтерем ялгышмаса, башка бер генә федераль округка да Президентның вәкаләтле вәкиле итеп шәһәр башлыклары билгеләнмәде. Гадәттә алар үзәк аппаратта эшләүчеләр, федераль министрлар яисә губернаторлар иде. Мэрыбыз бу уңайдан да искәрмә булып торды.

Аннары К.Исхаков Россия Федерациясенең Төбәкләр үсеше министры урынбасары, 2008 елның 14 июленнән 2011 елның 6 сентябренә кадәр Россия Федерациясенең Согыд Гарәбстаны корольлегенең Җиддә шәһәрендә урнашкан Ислам конфедерациясендәге даими вәкиле буларак хезмәт куйды.

Туган ягына кайткач та, Камил Шамил улы өендә генә утырмады: башта Татарстан Президентының ярдәмчесе, аннары Болгар Ислам академиясенең Учредительләр советы рәисе вазыйфасын башкарырга кереште. Зур тормыш мәктәбе узган К.Исхаков үзенә нинди бурыч йөкләнсә дә, аны колачын киң җәеп, җигелеп тарта. Күренекле шәхесебез 70 яшь тулу көнен билгеләп үтте. Киләчәктә дә аның халкыбызга зур игелекләр кылуына өметләнәбез. Шулай булыр да!.. ■

БУА ТЕАТРЫ АРТИСТЫ ИЛЬФИР СОЛТАНОВ: «БЕЗНЕҢ ЭШ УРЫНЫ – ДӨНЬЯ»

Ильфир Солтанов авылда яши, ул Буа татар дәүләт драма театрының автобусына утыра да туп-туры гастрольләргә – дөнья гизәргә чыгып китә. Аның сәхнәсе – еш кына чит шәһәрләр, чит илләр театрларында. Ильфирның рольләре – Куяннан алып милли характерларга кадәр.

Ильфир Солтанов Башкортстанның Кушнаренко районындагы Байталлы авылында туып үскән. Мәктәптән соң Уфа сәнгать училищесында вокал классын, аннан соң З.Исмәгыйлев исемендәге Уфа дәүләт Сәнгать академиясенең вокал бүлеген

тәмамлаган. Укып бетергәч, Стәрлетамак филармониясендә эшли башлаган. 2012 елда Буа театрының сәнгать җитәкчесе Раил Садри аны театрга чакырып ала. Моңа кадәр бары тик җырчы булырга гына ниятләгән егет театр дөньясына кереп китә...

– Ильфир, гадәттә, Уфадан Казанга киләләр. Син – Стәрлетамактан туп-туры Буага. Ничек соң сиңа Мишәрстан?

– Безнең авылда да Буадагыча сөйләшәләр. Республикаларда гына түгел, районнарда гына да түгел, хәтта күрше авылларда да сөйләм теле аерыла бит ул. Ә монда шулай килеп чыкты: безнеңчәрәк «сүләшәләр». Гадәт-холыкка килгәндә дә, бирегә килү белән үземне иркен тоттым, килгәндә, булачак коллективым белән таныш идем. Һәрхәлдә, «кая килеп эләктем», дигән үкенечле тойгылар булмады *(көлә)*.

Буага килер алдыннан бер елга якын икеләнеп йөрдем. Стәрлетамакта яшәү урыным юк, үрләр яулау өчен мөмкинлекләр тиз генә булырга охшамаган... Ул вакытта өйләнмәгән дә идем әле. Ә китү хыялы бар! Балачагымнан ук: «Мин Казанда яшәячәкмен!» – дип әйтә торган булганмын. Шулай Уфада бер концерт вакытында Раил абый, театрга җырлый торган артист кирәк, дип чакырды. Бер карасаң, чакырмаган җиргә киткәнче, чакырган урынга бару яхшырак. Икенче яктан, 600-700 чакрым ераклыктагы чит җиргә чыгып китү өчен тәвәккәллек тә кирәк. Шуннан Раил абый мине үзләре белән гастрольләргә чыгып карарга үгетләде. Ике атна Әлмәт, Чаллы якларында йөрү барысын да хәл итте.

– Син җырчы булырга укыгансың. Театрда исә рольләр төрле...

– Алай гына да түгел, мин элек театр уйнаудан кача идем. Училищеда актерлык осталыгы курсларында этюдларны да теләмичә генә башкардым. Шулай бервакыт гастрольләрдә бер егет авырып китте дә Раил абый аның урынына мине куйды. «Утын пүләне» дигән спектакльдә Хамисны уйнарга туры килде. Театраль белемем булмагач, спектакльдә уйнауның үзенең катлаулы кагыйдәләре бардыр, мин белмимдер, дигән курку бар иде. Хәзер инде башкачарак фикердә. Теоретик белеме булган, әмма практикада кулланып карамаган кеше – акыллы сүзләрнең мәгънәсен аңламыйча гына сөйләгән кеше кебек ул. Сүз дә юк, укыган кеше – укыган кеше инде, әмма һәр образны үзең аша үткәрмичә генә уйнап булмый икән.

Академиядә укыганда, мин Уфаның опера театрында хорда җырладым. Шунда миңа бер карт артист, киңәш итеп: «Кач син театрдан, бер кереп китсәң, чыга алмыйсың, сазлык кебек үзенә йота», – дигән иде. Ул вакытта җырчы булам, дип тәгаен максат белән яшәгәндә, аның нәрсә әйтергә теләгәнен аңламаганмын. Театрда җиде ел эшләү чорында гына төшендем аның сүзләренә.

– Ягъни театрның тәмен белә башладың?!.

– Әйе. Өстәвенә, берьюлы берничә театр мәктәбен үткән кебек. Ни өченме? Чөнки безнең театрга төрле мәктәпләрне үткән режиссерлар күп килә. Мәсәлән, Санкт-Петербургтан, Уфадан, Глазовтан. Менә әле Кемероводан өлкә дәүләт театрының баш режиссерын көтәбез. Ул җәй көне Буага театраль лабораториягә килгән иде, анда «Женитьба»ның беренче бүлеген куйдык, хәзер шуны эшләп бетерәчәкбез. Миңа калса, төрле режиссерлар белән аралашу бик зур тәҗрибә бирә. Алар спектакль генә чыгарып калмый, безгә бик күп белем дә биреп китә. Гастрольләргә баргач, бигрәк тә зур шәһәрләрдә буш вакыт була калса, театрларга йөгерәбез.

Хәзер инде үземне театрдан башка күрмим. Ролем өчен генә түгел, ә тулаем спектакль өчен кайгырам. Спектакль иҗат итү – ул бер генә кешенең түгел, ә команда эше. Шуңа да һәр уйнаган саен спектакльнең сәхнә бизәлешен, музыкасын һәм башка якларын да кайгырта башлыйсың.

– Җиде ел театрда узып та киткән. Артист кешедә амплуа була. Синдә дә барлыкка килгәндер ул.

– Беренчедән, бәлки, бер генә режиссер белән озаклап эшләсәң, барлыкка киләдер дә ул. Икенчедән, безнең театр төрле тамашачыга йөз тота: тамашачыны үзе әзерли, үзе зәвык тәрбияли. Куян һәм Әтәчтән башлап, яңа драмалардагы тилемсәләргә кадәр башкарган рольләрем бар. Традицион спектакльләрдә характерлы рольләрдән, мәсәлән, «Кодалар-кодачалар»да мин – бер коданы, Раил абый – икенчесен уйныйбыз. «Концлагеристлар» спектаклендә мин бер ирнең хатыны ролендәге ирне уйныйм. Сәер яңгырый, шулай бит?! Ә ул менә шундый катлаулы спектакль. Ирек турында. Дөресрәге, без кайда да читлеккә эләгәбез – шуны күрсәтә.

– Тормышта син үзеңне иректә хис итәсеңме?

– Чынлыкта, адәм баласына тулы ирек кирәкми дә. Кешеләр арасында яшисең, төрле социаль рольләрең бар икән, димәк, син барыбер үзеңнениндидер кысаларда тотарга мәҗбүр. Ирек ул кайвакыт үз-үзең генә калып уйланырлык, уйларыңныфикерләреңне тәртипкә салырлык микъдарда гына кирәк. Үзеңне шул дәрәҗәдә ирек белән тәэмин итә алуың бары тик үзеңнән генә тора. Мин, мәсәлән, гаилә адәм баласының иреген чикли, дип әйтә алмыйм. Бала вакытта әти-әни гаиләсе, балаларың тугач, үзең корган гаилә кеше җанының бер өлешен тәшкил итә, дип уйлыйм. Әлбәттә, төрле гаиләләр буладыр. Кайсыннан качасы килә, кайсына кайтасы гына килеп тора. Спектакльләрдә дә күбрәк шуны уйныйбыз бит инде.

– Буа театры республиканың иң йөремсәк театры буларак билгеле. Арытмыймы?

– Озаграк йөргәндә, арыта. Ике ел рәттән, Казакъстанда берәр ай йөреп кайттык. Андый вакытта йончыта. Шәһәр аралары да бишәр-алтышар йөз чакрым, күп вакыт автобуста уза. Әмма без мосафирларны якты йөз белән каршы алсалар, болар барысы да онытыла. Безнең эш урыны – дөнья *(көлә)*. Театр коллективы – зур бер гаилә кебек. Утрак тормышта гаиләләрдә ире-хатыны囗 эштә йөреп кайта, ә без гастрольләрдә тәүлек әйләнәсе бергә. Ә иң кыены – гаилә сагындыра. Кызым Диләрәгә өченче яшь, улым Кәримгә – бишенче. Бер атнага гастрольләргә китәсең, кайтканчы алар инде үсеп, үзгәреп өлгергән булалар.

– Балачакта әйткән сүзеңне тормышка ашыру теләгең юкмы? Казан, Казан, дигәнсең, башкалага омтылмыйсыңмы?

– Ю-у-ук! Буа, зур булмаса да, барыбер шәһәр бит инде ул. Икенчедән, мин бит авылда – Толымбайда яшим.

Кечкенә чакта авылда яшәгәндә, төпчек малай булсам да, абыйлар белән яшь аралары зур булу сәбәпле, эш күп була иде. Авылда буш вакыт юк, эш бетми дә бетми... Шул чакта бала-чага акылы белән «шәһәрдә рәхәт, анда эш юк, тизрәк авылдан чыгып китәсе иде», дип уйлый идем. Укыганда тулай торакта яшәдем. Әмма шәһәр тормышы тиз туйдырды, ярый әле нәнәй (Башкортстанда дәү әниләрне шулай дип йөртәләр) Уфа янындагы Затон бистәсендә үз йорты белән яши иде – шунда күчеп яши башладым. Кыш көне кар көрәп керсәң дә, рәхәт булып китә.

Бүген яраткан эшең белән шөгыльләнү хакына шәһәрнең кысан фатирында үз-үзеңне чикләп яшәү мәҗбүри түгел.

– Син бит әле Раил Садри дигән «бренд» кул астында да эшлисең. Монысы үзе бер тарихтыр?

– Чыннан да аның яңа килгән кешегә таләпләре башкачарак. Килгән уңайга аңлашмаган чаклар да булгалады. Һәм шулай дөрес тә. Ул миңа: «Сез, Башкортстаннан килгән кешеләр, әкренрәк», – дия иде. Чыннан да, Башкортстанда тормыш сал-

Артур Соломоновның «Благодать» спектакленнән күренешләр бирелде. Анна Ванямова фотолары.

маграк бара сыман. Мин инде хәзер мондагысына ияләштем, туган якка кайткач, салмак тормыш ритмын үзем дә сизәм.

Раил абый максат куя һәм шуңа ирешә белә. Бу җәһәттән ул бары тик үрнәк кенә була ала. Бүгенге көндә Буаны да Буа театры таныта. Халыкара фестивальләр үткәрә башлагач, безне Мәскәүдә, Санкт-Петербургта белә башладылар. Бездә театраль тормыш кайнаганны күрәләр. Ә бу, миңа калса, әйбәт күрсәткеч: провинциаль шәһәрләрнең һәркайсы да театраль тормышы белән мактана алмый.

– Әле нинди образ иҗат итәсең?

– Ильшат Мөхетдинов яңа гына Артур Соломонов пьесасы буенча «Благодать» дигән спектакль чыгарды. Премьерасы март аенда. Без аны русча уйныйбыз. Менә шунда мин тилемсәрәк рольдә. Бу спектакль белән фестивальләргә йөрмәкче булабыз.

– Рольләреңнән канәгать каласыңмы?

– Миңа калса, хәтта бөек артистлар да канәгать була алмыйлардыр. Һәр спектакльдән соң: «Тукта, җиренә җиткереп уйнап бетердемме соң әле мин бүген?» – дигән анализ була. Мәсәлән, Егор Чернышов Ркаил Зәйдулланың «Мишәр хикәяләре» буенча куйган спектакльдә без үзебез уйныйбыз да, сөйлибез дә. Менә шунда мин үзем нәрсәнедер эшләп җиткермим кебек тоям.

– Бәлки чыннан да мишәр булмавыңнандыр?

– *(көлә)* Бәлки...

Әңгәмәне ***Ландыш Әбударова*** *алып барды.* ■

Безнең мирас №3 март 2019

ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ

Габдерәшит Ибраһимов

КӨНЧЫГЫШ КЫТАЙ ТИМЕР ЮЛЫ

Маньчжуриядән алып Владивостокка кадәр, Көнчыгыш Кытай тимер юлы буйлап, бөтен станцияләрдә, эшчеләр һәм хезмәткәрләр күреп аптырашка калырлык дәрәҗәдә күп. Һәр станция үзе бер авыл кебек һәм биредә яшәүче халыкның бөтенесе – тимер юл эшчесе. Берәр ят кеше килеп очраса, бу шул эшчеләр өчен биредә кибет ачкан берничә татар яки яһүд кешесенең берсе булып чыга. Шәһәрләрдә яшәүчеләрнең дә күбесе тимер юл эшчесе. Харбинда бүгенге көндә 70 мең кеше яши, тик боларның өчтән ике өлеше – тимер юл эшчесе, калган өчтән бере – сәүдәгәр. Болары да бары тик шушы тимер юл һәм аның эшчеләре аркасында гына сәүдәсен алып бара, акча җыя.

Русия хөкүмәте Харбинда рәсми рәвештә бары тик тимер юл эшчеләрен һәм хезмәткәрләрен генә тота, болардан башка берәүне дә тотмый. Шуңа күрәдер, Харбинда дәүләт милке хезмәткәрләре, губернатор-фәләннәр юк. Полиция идарәләрен, хәтта губернатор вазыйфасын да шул ук тимер юл идарәсе өстенә өйгәннәр. Шул рәвешле, тимер юл хезмәтендәге бер түрә, кирәк булса, губернатор да була, полиция

Көнчыгыш Кытай тимер юлының (көньяк линия) «Тьелин» станциясе

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

Харбин станциясендә тиз йөрешле поезд

мөдире дә була, кирәге чыкса, командир да була ала – мондагы кешеләрне менә шулай эшләтәләр.

Беренче карашка, берничә кешенең эшен бер кеше башкарган кебек күренсә дә, чынбарлыкта исә, киресенчә, бер кешенең вазыйфасында күп кеше эш башкара. Төп максат – бу кешеләрне тимер юлда эшләтү түгел, Маньчжуриядә төпләнеп яшәргә калдыру. Бу тимер юлны руслар Кытай хөкүмәте акчасына төзегәннәр, Кытай хөкүмәте акчасына эшләтәләр. Менә шундый сәясәт аркасында, Көнчыгыш тимер юлы, һәр ел ике миллион сум тирәсе файда китерәсе урынга, китерми кала.

ХАРБИННАН ВЛАДИВОСТОККА КАДӘР

Һиҗри 1327 елның мөхәррәм-әлхарамның беренче көнендә[1] мин Харбин шәһәреннән китеп бардым. Харбиндагы дус-иш мине станциягә кадәр килеп озатып калдылар. Шулай итеп, кичке азаннан соң, мин, соңгы тапкыр Русия поездына утырып, сәяхәтемнең алдагы өлешен башлап җибәрдем.

Мин бу якларда татарларның һәр станциядә булуын беләм. Чынлап та, бөтен җирдә татар бар, барысы да сәүдә белән шөгыльләнә. Без Харбиннан кузгалып киткәннән соң, төн урталарында, безнең вагонга татар кыяфәтле бер кеше менде. Минем каршымдагы урында бер хатын утырып бара иде, бу кеше шул хатын янына килеп утырды. Мин мондый вәкарьле рус хатыны белән нинди дер бер сәүдәгәр татар кешесе арасында самими мөнәсәбәт була аладыр, дип башыма да китерә алмыйм. Ятып йокладым.

Таң атарга аз калгандыр, теге яшь татар белән хатын арасында гаять житди сөйләшү барганын хис иттем. Йоклаган булып ятам. Тик сүзләре бик ишетелми, кайберсе ишетелсә дә, аңлашылмый. Шулай итеп, көн туды. Болардагы җитдилек һәм самимилек бөтен зиһенемне яулап алды. Бер уңайлы мәлне файдаланып, үзем белән таныштырдым. Яшь егет шунда ук аягүрә торып басты һәм минем белән ике куллап күреште. Аннан соң:

– Мин алдагы станциядә төшәм. Мине үзегезнең читтән торып белем алучы укучыгыз, дип саный аласыз. Кем икәнемне һәм ни сәбәпле бу күрешүгә килүемне Сезгә бу ханым сөйләр, – диде.

– Бу ханым кая бара? – дип сорадым.

– Владивостокка, – диде. – Миңа

[1] 1909 елның 1 сентябре (тәрж. иск.).

Мяньдухэ депосы агентлары

телеграф аша хәбәр иткән иде. 200 чакрым юл үтеп, махсус килдем. Күрешеп сөйләшәсе кайбер нәрсәләр бар иде.

Бик нык аптырадым: бу дәрәҗәдә үк сәясәт белән шөгыльләнүче яшьләр барын белми идем.

– Иптәшләрегез бармы?

– Бик аз, – диде. – Иң яхшыларын, әле соңгы вакытларда гына, кулга алдылар, мәхкәмәсез-нисез Нерчинск дигән җиргә каторгага җибәрделәр.

Ул арада поезд станциягә килеп туктады һәм бу әфәнде поездан төште. Вагонда кеше шулкадәр күп ки: сөйләшеп утыру турында уйлыйсы да юк. Тик бу яшь кеше миндә искиткеч зур кызыксыну уяткан иде инде. Хатын миңа:

– Владивостокка барып җиткәч, мин Сезнең кунакханәне табып, килермен. Бу иптәш турында сөйләрмен, – диде.

Берни эшләп булмый: алда әле тагын 24 сәгатьлек юл бар, сабыр итәрбез. Хатын исә гаять вәкарьле, җитди, гаҗәеп тәрбияле, затлы гаиләдән булуы аңлашылып тора. Ул көнне кичкә кадәр бергә идек, миңа олы ихтирам белән карады, хөрмәт күрсәтте. Кич җиткәч, шул өстендәге киемнәре белән йокларга ятты. Мин бу ханымның хәленә-торышына игътибар иттем, мөгамәләсе бик тәрбияле, җитди иде – хупламый мөмкин түгел.

12се көнне иртән иртүк вагон күршем булган әлеге ханым мине уятты да: «Владивостокка килеп җитәбез», – диде. Шунда ук тордым да әйберләремне җыя башладым. Ханым миңа: «Вагоннан чыгуга, бик күп фәкыйрь йөк ташучы күрерсез. Корея кешеләре. Йөгегезне шуларга бирерсез, кунакханәгә кадәр илтәрләр. Ат арбасы яисә машинаның кирәге юк, җәяү генә барырсыз. Арбачыга 40 тиен бирсәгез дә, аз, диячәк. Әмма бу кореялылар, күпме бирсәгез, шуңа риза булып, рәхмәт әйтәчәкләр. Кунакханә дә якында гына урнашкан, мин Сезгә күрсәтермен. Мин үзем туганымның өенә барам, Сезнең кунакханә ишеге төбенә кадәр бергә барырбыз», – диде.

ВЛАДИВОСТОК

Поезд Владивосток вокзалына килеп туктады. Вагоннан төшүгә үк игътибар иттем: чынлап та, юлчыларның йөген ташучыларның бөтенесе дә корея кешесе иде. Сыртларында йөк ташу өчен куллана торган кәрҗин бар. Һәммәсе дә бик мөлаем кешеләр. Юлчыларның яннарына курка-курка гына киләләр. Мин дә әйберләремне бер кореялыга биреп, сыртына төядек тә китәргә җыендык. Вокзал капкасыннан чыгуга ук күзгә ташланган нәрсә – каршыдагы үр. Бу үрнең бөтен җире сукмаклар белән ермачланган. Җәяүле юлчылар, күзләре кая төшсә, шунда юнәлгән, артларыннан йөк ташучылар да үргә күтәрелгән, шул рәвешле сукмаклар салынган булса кирәк. Бу үрнең биеклеге 12 аршын[2] тирәсе булыр, монда бик яхшылап баскыч ясарга мөмкин булыр иде. Үрне менеп җиттек, дигәндә, алдыбызда пычраклык белән тулы бер мәйдан ачылды! Әлеге кореялы йөкчеләр дә, үтеп-сүтеп йөрүче сәрхушләр дә, кайда кысталса шунда туктап, бу мәйданны пычратканнар. Егерме адым гына алда – зур урам, каршысында – чатта – Владивостокның беренче дәрәҗәле кунакханәсе булып саналган Гранд Отель урнашкан. Бу җирләр Владивосток шәһәренә килүчеләрнең иң башлап күзләре төшәчәк урын булганга, теләсәләр дә, теләмәсәләр дә боларны күрергә мәҗбүрләр. Әгәр бу пычраклык Ислам дөньясының берәр җирендә булса, христиан кешесе булган язучыларның һәрберсе, һичшиксез, бу турыда язачак һәм гаепне дә Исламият өстенә атачак. Ләкин бу хәл-торыш христианлык дөньясында һәм руслар кулында булганга күрә, бу турыда язучы түгел, моны күрүче дә юк.

Шуннан илле адым тирәсе алдарак урнашкан Карымск кунакханәсенә туктадым.

Мин хәзер Ерак Көнчыгыш капкасы һәм иксез-чиксез Русия мәмләкәтенең соңгы, ә Зур Себер юлының башлангыч ноктасы һәм мәркәзе, дөньяның иң зур һәм иң матур сугыш портларының берсе, русларның иң зур дошманнарына каршы бердәнбер саклану көчләре урнашкан Владивосток шәһәренә килеп җиттем. Бу шәһәрнең сәүдә, сәясәт ягыннан караганда беренче дәрәҗәдәге әһәмияткә ия булуы икеләнү тудыра алмас. Шуңа күрә, мондый шәһәр турында бераз сөйләп аңлатмыйча калсам, дөрес булмас иде.

Әлбәттә, бөтен кеше дә сүзен үзенең игътибарын җәлеп иткән нәрсәләрдән башлап җибәрә. Мин дә шулай.

ВЛАДИВОСТОКТА КОРЕЯЛЫЛАР

Владивостокта Корея кешеләре шулкадәр күп ки, саны бары тик Аллаһы Тәгаләгә генә мәгълүмдер. Бу кеше көтүен кызганмыйча мөмкин түгел, мәрхәмәткә бик нык мохтаҗ хәлдәләр. Әмма, нишләмәк кирәк, «мәдәни инсаннар» этләрне кызганалар, ә менә җан ияләренең үз төрдәшләре булган кешеләрне кызганмыйлар шул! Авазың чыккан кадәр кычкыр – игътибар итүче дә булмас! Теләсәң, бөтенләй тавыштыныңны чыгарма, барыбер кызганучы табылмас! «Мәдәниятнең кирәге бу – гаепләргә ярамый».

Ләкин Көнчыгыш холык-фигыле таләп иткәнчә, кешеләргә мәрхәмәтле булу – кешелек сыйфатларының берсе булганга, мин кореялыларны бу хәлдә күреп, җаным бик нык, бик нык әрнеде.

Владивосток вокзалында күргән кореялы йөкчеләрнең санын якынча гына да әйтеп булмый. Ник дигәндә, һич арттырмыйча әйтәм, поездан төшкән юлчылардан ике тапкыр күбрәк иделәр. Вокзалда игътибар иттем: йөк күтәргән никадәр кореялы булса, алардан ике тапкырга күбрәге йөк эләктерә алмыйча буш калды. Әйберләре күп булган

[2] Аршын – якынча 68 сантиметрга тигез булган озынлык үлчәү берәмлеге (тәрҗ. иск.).

кайбер юлчылар йөкләрен хәтта икеөч йөкчегә бүлеп күтәрткәннәр иде, югыйсә.

Әле тагын кунакханә ишеге төпләрендә дә, һичшиксез, дүрт-биш йөкче кореялы һәрвакыт бар. Күбесендә хәтта сигез-ун кеше дә була. Тик ишек янында ук тора алмыйлар, кунакханә хезмәткәрләре рөхсәт итми. Бичара кореялы (сыртында кәрҗине), күзләрен ишеккә төбәп, бераз арырак, аягөсте торып көтә. Теге ишектән бер мәрхәмәт иясе чыгачак та бу бичара кореялыга әйберләрен ташытачак, 2 тиен, иң күбе 5 тиен бирәчәк, әле бирсә!

Болар гел ач, ишектән чыгып, бер ипи сыныгы күрсәтсәң, биш-ун кеше бергә йөгереп киләчәк. Мәдәни европалы бик күпләр бу бичараларга ишәк йөге кадәр йөк төяп, Владивостокның бер башыннан икенче башына шуны ташытып, 2-3 тиен акча бирсәләр, мескеннәр, акчаны әйләндерә-әйләндерә карыйлар, сөенәләр. Мин әйберләремне вокзалдан Карымск кунакханәсенә илткән кореялыга 10 тиен биргән идем, бичара, ышана алмыйча торды. Бер минем йөземә карый, бер акчага карый, ул елмаю, ул сөенеч – шаккатырсың. Бу кореялылар арасында рус телен белүчеләр юк, шуңа күрә сатулаша да алмыйлар. Теләгән кадәр йөк төя, күпме түләү – инсафыңа бәйле.

Әгәр Владивостоктагы кореялылар турында бер әсәр язарга уйласаң, күз яшьләренә буыла-буыла укырлык берничә йөз битлек роман язарга мөмкин булыр иде. Мин аларны бик нык кызгандым, һич хәтеремнән чыкмыйлар. Беркөнне аз гына русча сөйләшә алучы бер кореялыны очраттым, хәләхвәл сораштым.

– Ник бу кадәр күп йөк ташучы бар арагызда?

Күз яшьләрен сөртә-сөртә, кореялы болай дип җавап бирде:

– Дөньяда безнең кебек бәхетсез берәр милләт күргәнегез булдымы?! Йөк ташу эшеннән башка нинди эш эшли алабыз соң? Ватанның кыйммәтен белмәгән милләт өчен бу җәза да аз әле. Ватаныбызны чит-ятларга бирдек, үзебез менә шушы хурлыкны сайлап алдык, моңа сәбәпче булганнарга Аллаһ җәзаларын бирсен!

– Сезнең гаиләгез, бала-чагаларыгыз кайда? Кай җирләрдә көн күрәсез?

– Безнең гаиләләребез... Менә шул шәһәрнең чит-читләрендә үз өйләребез бар, гаиләләребез шунда яши.

– Сез бу йөк ташучы булып эшләвегез белән акча таба аласызмы соң? Көнгә ничә тиен акча эшлисез?

– Кайбер көннәрне 5-10 тиен алып кайтабыз, кайчак бер тиен дә булмый. Бик сирәк кенә елга бер-ике тапкыр, бәлки, көнгә 20-30 тиен эшли алабыз. Анысы да читтән килгән мәрхәмәт иясе берәр кеше килеп очраса гына була.

– Сезнең кореялылар арасында бай кешеләр юкмы?

– Үз илебездә бар инде, тик биредә берәү дә юк һәм була да алмас. Тел белмәвебез аркасында, бер эшкә дә ярамыйбыз. Тел белүчеләребез дә эчүгә сабышкан, алар да бер эшкә дә ярамый.

– Үз илегездә генә яшәсәгез, яхшырак булмасмы?

– Анда тагын да начаррак. Бер яктан, ачтан үлү куркынычы яный, икенче яктан, миссионерлар җанга тия, христиан итәр өчен каныгалар. Алар тәкъдим иткәнне кабул итмәсәң, аракы бирмиләр, кабул иткәннән соң да бирмиләр, әлбәттә, бары тик кабул иттергәнчегә кадәр генә бирәләр. (Мескен кеше: елыйсы урында, көлгән була.)

– Христианлыкны кабул иткән кешеләр күпме?

– Фәкыйрьләр арасында күп. Башка чара юк. Бер шешә аракы өчен христиан булган бик күп кеше бар. Кичтән миссионер аңа аракы бирә, тик иртән тамчы да бирми. Шешәне күрсәтә: «Христианлыкны кабул итсәң, бирәм», – ди. Шуннан соң теге бичара нишли? Теләмәсә дә, хри-

стиан була. Мондый христианнар күп.

– Инде христиан булгансыз, алайса балаларыгызны мәктәпләргә бирегез. Һич булмаса, алар бу хәлдән котылсыннар.

– Белмим шул. Безгә үлемнән башка юл юктыр инде. Намуслылар бөтенләй чыгып йөри алмыйлар, өйләрендә, ачлыктан бик күп кеше кырыла.

Бу миңа бик нык тәэсир итте. Кореялы бу кешене яныма алдым да боларның мәхәллә кебек җирләренә киттем. Шәһәр читендә, балчыктан ясалган, килешкыяфәтләре бик сәер алачыклар тора. Һәр алачыкта 8-10 кеше. Тәрәзә-фәлән юк. Түбәдән чыгып торган бер торба бар, уртада ягылган учакның төтенен дә суыра, яктылык та кертә. (Әгәр үлем, фән белдергәнчә булса, үләр өчен бу өйнең эчендә берничә сәгать тору җитәдер.) Менә бу бичара кореялылар шундый өйләрдә яшиләр. Мин бу өйләрнең берничәсенә кердем, карадым, күрдем. Бер өйгә кереп барганда, уема килде дә: «Сәер, сезнең болай яшәп ятуыгызны полиция хезмәткәрләре беләме икән?» – дип сорадым. Бер карт: «Кәеф-сафа корып яшәгән кешеләрнең җәфа чигеп яшәгән кешеләр хакында хәбәрләре була димени?» – дип җавап бирде.

Кешегә, кешеләрнең вәхшәтен күреп аңлар өчен, менә мондый рәнҗетелгәннәрнең, кимсетелгәннәрнең яшәвенә гыйбрәт алып каравы җитәдер, мөгаен. Аннары, кешелек дигән булып, Хайваннарның тереклек хокукларын саклау җәмгыяте, фәлән җәмгыяте, төгән җәмгыяте диюнең Париж ачларының озын кара сигара тартуларыннан, Лондон ялангачларының зур цилиндр башлык киюләреннән берничнди дә аермасы калмый. Төрдәшләре булган кешеләрне кызганмыйлар, ә этләрне-фәләннәрне кызганалар, имеш.

Владивостокта йөк ташучы кореялыларның һәм алар көн күрә торган өйләрнең рәсемнәрен почта белән гаиләмә [Русиягә] җибәргән идем, тик Русиядә почта хезмәткәрләре берничнди җаваплылыкны да кабул итмиләр шул. Шулай чарасыз калып, күрелергә тиешле бу күренешләрне хөрмәтле укучыларыма җиткерә алмадым. Югыйсә, алар арасында мәдәни дөньяга күрсәтергә кирәк, дип тупланган, гыйбрәт алырлык рәсемнәр күп иде.

Төрекчәдән ***Асия Рәхимова*** *тәрҗемәсе*

Дәвамы бар ■

Безнең мирас №3 март 2019

ВАК ХИКӘЯЛӘР

Дәрдемәнд

КОЯШНЫҢ НУРЛАРЫ

Матур кояш иртә белән кызарып күк йөзенә күтәрелде. Җир йөзен татлы йокысыннан уятыр өчен, алтын кебек сары якты нурларын таратып, төрле якларга җибәрде.

Башта бер нур очты. Барып-барып сабан тургаеның өстенә төшкән иде, сабан тургае йокысыннан уянып тирбәнде, чыгып күк йөзенә күтәрелде. Шуннан матур тавышы белән чырлап сайрап җибәрде.

Икенче нур очты. Монысы татлы йокыда яткан бер куян өстенә барып төште. Куян, урыныннан торып, озын колакларын селкетте. Шуннан сикерә-сикерә яшел тугай эченә төшеп, йомшак үләннәрне керт-керт өзеп ашамага кереште.

Янә бер нур очып тавык кетәгенең эченә кергән иде, өлкән әтәч, күзләрен ачып, канатларын язып, гайрәт белән тилпенде, «Кикри-и-и- и-кү-ү-ү-к!» кычкырып җибәрде. Тавыклар куначаларыннан очышып төштеләр. Кытыйклашып төрлесе төрле якка таралды җим эзләргә.

Дүртенче нур килеп умарта өстенә төшкән иде, бал корты, балавыз сараеннан чыгып, канаткайларын төзәтте. Шуннан «Без-з-з-з!» китте очып хуш исле чәчәкләрдән татлы бал җыйнарга.

Бишенче нур балаларның йокы бүлмәсенә кереп, бер кечкенә ялкауның түшәгенә, туп-туры күзкәенә төште. Йа Рабби, кыздыра! Әмма кечкенә ялкау әйләнеп икенче ягына ятты да тирән йокыга талып китте.

ИКЕ ТУГАН

Борын-борын бар иде ике туган: сеңеле белән абзый – тавык белән әтәч. Көннәрдән беркөн бакча эчендә йөргәннәрендә, әтәч карлыган күрде. Күрде дә, пешмәгән яшел карлыганнарны чукып ашамага кереште. Сеңлесе тавык кычкыра:

– Туганым, куй, ашама! Карлыган пешеп өлгерсен, сабыр ит! – диде. Тыңламады әтәч, чукыды ашады, чукыды ашады. Тәмам туеп булгачтын гына, ава-түнә өйләренә кайтты.

– Уф! – диде, әтәч әйтә. – Эчем авырта!

Менә бәргәләнеп сызлана башлады. Менә үкереп елый...

– Уф Алла! – ди. – Сеңлем, үләм инде!

Сеңлесе тиз шкафтан шешәләр карап, абзасына дарулар тамызып эчерде, эченә горчица япты. Берничә көннәр узгачтын гына, әтәчнең, сәламәтләнеп, күзләре ачылды.

Әтәч инде тәмам сәламәтләнеп булган иде, беркөнне кырга чыктылар. Кырның өстен хәтфә кебек йомшак үләннәр каплаган. Ямь-яшел! Төрле чәчәкләр үсә, матур күбәләкләр оча, чикерткәләр сикерә...

– Әйдә, йөгереп уйныйк! – ди, тавык әйтә.

– Әйдә, йөгереп уйныйк! – ди, әтәч тә.

Әй йөгерәләр, әй уйныйлар! Әй йөгерәләр, әй уйныйлар!

– Беләсеңме? – ди, тавык әйтә. – Йөгереп уйнау бик файдалы була... Мин абыстаемнан ишеттем, – ди.

– Мин дә хәлфәмнән ишеттем, – ди әтәч, – йөгереп уйнау бик файдалы була...

– Әйдә, тагын йөгерик!

– Әйдә, йөгерик!

Әй йөгерәләр, әй уйныйлар! Әй йөгерәләр, әй уйныйлар! Тирләделәр, пештеләр. Бик сусадылар. Якында гына бер болак бар иде, суы салкын! Таштан ташка чалтырап ага... Йөгерде әтәч су эчәргә!

– Тугансаем, куй! – ди, тавык кычкыра, – Тирең кипми торып, эчә күрмә! Сабыр ит, – ди, – тирең кипсен.

– Йә, ни булыр дисең? Янып барамын ич, – ди әтәч.

Эчте дә эчте салкын суны тирле көенчә! Менә инде үзен бизгәк калтыратып селкетә башлады – тешләре шакылдый! Хәле бетте... Бичара, көчкә өйләренә кайтып егылды, тавыкның җилкәсенә таянып.

«Шәфкатьле сеңлесе тиз докторга йөгерде. Дарулар алып кайтты, әч-че! Йә, нинди тәмсез! Әмма эчмичә хәл юк – үләсе килми бит! Бичара әтәч! Айлар буенча түшәк өстендә калды, кузгалмастан. Әтәчнең сәламәтләнеп тышка чыга башлаганында тәмам инде көз булып җиткән иде. Беркөнне әтәч карый – күлнең өстен боз каплаган... Шоп-шома, йа Рабби, ялтырый – көзге кебек!

– Иһ-һу-у-м! – ди, әтәч әйтә. – Тукта, коньки шуыйм!

– Куй, батырым! Әйтә күрмә. Боз әле бик юка, – ди сеңлесе тавык. – Сабыр ит, боз бераз калынайсын.

Тыңлыймы соң тискәре! Йөгерде каршы боз өстенә. Шуып кына киткән иде, «булт!» итте: төште-китте суның төбенә! Мескеннең йон гынасы калды ике бөртек боз өстендә...

БОГЪДАЙ

Бер игенче, сигез яшендәге углы Хөсәенне янына алып, игеннәрнең ни хәлдә икәнен күрер өчен басуга китте. Юлда бер игенлеккә очрадылар, богъдайларның барысы да башакларын җиргә карап игәннәр, арада берничәсе генә башларын югары күтәреп, теп-текә торалар иде. Хөсәен бу хәлне искәрде. Әтисенә әйтте:

– Әти! Карачы бу богъдайларны: мискиннәр! Ничек муеннары бөгелгән... Машалла, әнә тегеләре! Ниндәй теп-текә, егет сыман торалар!

Атасы атны туктатты. Арбадан төшеп, богъдайларның ике төрлесеннән дә өзеп алды. Бөртекләрен чыгару өчен башакларын учлары эчендә угалады. Шуннан Хөсәенгә әйтте:

– Кара, угълым! Боларның эчендә никадәр күп богъдайлар бар! Менә шуның өчен дә боларның башлары иелгән... Инде шул, текә торганнарны кара – эчләрендә бер әйбер дә юк! Болары бер тиен дә тормый. Моннан гыйбрәт ал, угълым: текә башлы булу гакылсызлыктан килә. ■

БАЛАЛАР ЯЗУЧЫСЫ РОЗА ХАФИЗОВАНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

МӘШҺҮР ИРЕМНЕҢ БЕРЕНЧЕ ХАТЫНЫ

Билгеле булганча, Роза ханым Хафизова – күренекле балалар язучысы. Аның күп санлы хикәя һәм мавыктыргыч повестьларын безнең балалар да укып үсте.

Ләкин минем максатым авторның иҗатына бәя бирү түгел – анысы белгечләр эше. Хикмәт шунда: Роза ханым Хафизова – минем ирем, язучы Нурихан Фәттахның беренче мәхәббәте һәм беренче хатыны. Алар 1947-1951 елларда Казан дәүләт университетының татар филологиясе бүлегендә биш ел буе бер төркемдә укый. Укуларын тәмамлаганнан соң, ЗАГСка барып язылышалар да (имеш, бер-берсен югалтмау өчен) икесе ике җиргә эшкә китә: кыз – Төмән өлкәсенең Тобольск шәһәренә җибәрелә. Ул андагы татар мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли. Егет – Чистай шәһәрендә «Сталин байрагы» дип аталган өлкә газетасы редакциясендә тәрҗемәче вазыйфасын башкара.

Шуннан бер ел буе хатлар аша аралашу башлана. Розадан Нурихангa килгән бер өем хат бүгенге көндә безнең китап шкафы тартмасында саклана.

Ул хатларда тормыш-көнкүрешнең авырлыклары да, мохтаҗлыктан зарланулар да, коллективта килеп туган төрле гаделсезлекләр дә урын алган. Аларда сугыштан соңгы елларның сәяси-икътисади хәлләре дә чагылган, яшьләрнең тормышка үз карашлары формалашкан һәм иң мөһиме – Себердә татар мәктәпләренә карата начар караш булуы, җитәкчеләрнең ачыктан-ачык татар теленә, татар теле укытучыларына һөҗүмнәре белән шушы япь-яшь кызларның батырларча көрәше! Билгеле инде, яшьләр укыган китаплары турында фикер алышкан, үзләре иҗат иткән «шедеврлар»ны анализларга да онытмаган. Менә шул хатларның берсен мин «Безнең мирас» журналы битләренә тәкъдим итәргә булдым. Хатлар бик күп. Озыннар.

Өзекләрне журнал редакциясе хезмәткәрләре үзләре сайлап алыр, дип уйлыйм. Роза ханым Нуриханны соңгы юлга озатырга килгәч, бу хакта безнең арада сүз булды. Мин:

– Исән булсам, мин аларны Сезнең берәр юбилей уңаеннан матбугатка чыгарырмын, рөхсәт бирерсездер бит? – дип сорадым.

– Мине искә алучы булырмы икән? – диде ул һәм өстәп: – Бигрәкләр дә киребеткән иде шул Нурихан, син ничек түзеп яшәгәнсеңдер, – дип әйтеп куйды.

Әйе, төрле вакыт булгандыр, беребез дә әүлия түгел. «Гаиләдә бу холкыңны чүплеккә чыгарып ташла!» – дип, өлкән язучы Шәйхи Маннур юкка гына әйтмәгәндер Нурихан каләмдәшенә.

Руфина Фәттахова,
ТРның атказанган табибы, медицина фәннәре кандидаты,
Н.Фәттахның икенче (соңгы) хатыны. 23 гыйнвар, 2019 ел

Роза Хафизова – Нурихан Фәттахка

Нурыйхан, ни хәлләрең бар?!

Бүген шимбә көн. Эш – муеннан.

Мин бөтенесен к черту ташлап, сиңа хат язам. Синең 4/XI язган хатыңны моннан берничә көн элек алдым, бүген 10/XI язган хатыңны алып укыдым. Икесенә бергә җавап язам. Йә Алла! Көннең салкынлыгын белсәң иде, Нурыйхан! Просто коточкыч.

Бүген дәрескә барырга чыктым: аякта – ботылар, кулда – бер кат перчатка, өстә – җәйге пальто. Мәктәпкә көчкә килеп җиттем, кулым туңып, өзелеп төште, дип торам, коточкыч салкын. Проклинаешь все на свете!

Хәзер сайлаучылар списогын төзү өчен чыгып китәргә кирәк. Белмим, нәрсә эшләргә. Хәтта тәрәзәдән карарга да куркам. Бит бөтенләй рәт юк. Кайчаннан бирле итек хлопотать итәм – юк һаман. Бу корыган шәһәрдә берни табар хәл юк. Пальтоны тектереп алырга мамык юк. Мөмкин түгел. Бер дә рәхәт түгел әле, картлач. Кәеф тә шәп түгел. Арыта, эштә питание начар. Бала-чага нервыларга тия. Белмим, нәрсә эшләргә. Бөтен дөньясын ташлар идем дә синең янга кайтып китәр идем. Ичмаса, хәлне син аңлар, син күрер идең. Болай берүзең бит. Ярый әле шәл җибәрдең, юкса, бөтенләй начар иде эшләр. Хәзер мәктәпкә килеп керәм дә, шәлгә кулларны төреп, укып утырам. Шәл йомшак, җылы. Кешеләр мине шәлгә төренеп кенә утыра, дип уйлыйлар, ә мин шәл аша сине тоям. Әйтерсең, син җылы, йомшак итеп мине иркәләп утырасың. Һәрвакыт минем белән йөрисең кебек тоела. Әйе, сиңа да бүрек алып җибәрсәм, менә дигән булыр иде дә, белмим, тырышырга кирәк. Хәзер синең хатны алу белән сораштым. Монда базарда пешковая шапка дип саталар, ди кайчагында. 200-250 сумнарга алырга була, ди. Хәзер әле итек юк. Базарга чыгарга, тикшеренергә вакыт юк! Аннан пальто рәтләргә кирәк бит. Директордан бурычка алган 500 сумны кайчан түләргә булыр, белмим. Әле пальтоның эченә, тектерергә, җәһәннәмнәргә акча кирәк. Гомумән, тормыш ятьмәсенә буталганмын, ташлап китәсем генә килә. Ходай каргаганга мин монда килеп чыкканмындыр. Бәхете булган кеше шундый пыткомнарга дучар буламы соң? Һичкайчан да! Әллә син каргадың инде шунда, хәзер минем анда булмавыма шатланып ята бирәсең. Сиңа нәрсә, синең хәлең минеке кебек үк түгел бит.

Мин синең мәкаләне укыдым. Шәп булган, басканнар. Ярми абыйларга бераз гына подлизывать иткәнсең итүен, шулай да көчле язылган, кешегә ияреп, кеше сүзләре белән язылмаган. Котлыйм. (Әле Берия докладын, Вышинский чыгышын

укырга да вакыт юк, грехом пополам шунда карап чыктым.) Селкенергә дә вакыт юк. Ә акча рәтлерәк булса иде шул каторожный эш өчен. Бит студент тормышыннан бөтенләй аерылмый, черт возьми. Мин, гомумән, тормышны болай күз алдына китерми идем. Нишлисең бит. Шулай булгач, шулай булыр инде. Бәхетем булган булса, тормышка чыккач та берүзем яшәмәс идем. Нәрсә дисең?!. Бер чыккансың икән, ирең янында тор, чыкмасаң, бөтенләй чыкма икән ул.

Хатны өзеп, дәрескә кереп китәргә туры килде. Хәзер безнеңчә кичке 11, ә сезнеңчә, 8 генә. Радиодан үзбәк декадасы ачылуга багышланган тантаналы утырышны транслировать итәләр. Г.Тукайны да телгә алып киттеләр. Күңелле булып китте. Кич укытучылар өчен татар теле кружогы үткәрдем. Монда бер дә саф татар телендә сөйләшә белмиләр. Аларны өйрәтергә кирәк. Менә бүген беренче занятиесен уздырдым. Үзем бик канәгать булып калдым. Кызыксындылар, игътибар белән тыңладылар, сораулар бирәләр. Күңелле генә үтте. Һәр атнаның шимбә көнендә уздырачакмын. Иртәгә калдырдым бөтен эшне. Берәрсеннән итек алып, квартирларга йөреп чыгарга булыр инде. Йөрәк ярыла, кот оча!

Нурыйхан, мин сиңа тагы бер шатлыклы хәбәр язам. 12/XI педсовет булды. Безнең мәктәптә күптәннән бирле инде кайсы телдә сөйләшү мәсьәләсе карала иде. Берничә рус укытучы тарткалаша.Теге Люся – завуч, ГОРОНОга барып, обкомга барып жаловаться итеп йөргән. Имеш, учительскаяда укытучылар ТАТАР телендә сөйләшәләр. Зав. ГОРОНО Филлипов шундый тәкъдим ясый: имеш, һәрвакыт рус телендә генә сөйләшергә тиешсез, теге-бу. Безнең бөтен мероприятиеләр рус телендә уза. Шул учительскаяда аз-маз татарча сөйләшкәнгә дә риза түгелләр. Шуннан мин түзмәдем, сикереп торып, бөтен күңелдәгеен әйтеп бирдем. Чөнки мин үземнең дөреслекне беләм. Филлипов белән ачуланышып киттек. Директор шулай ук татар дигәндә үлә, ул да Филлипов белән әләгеште, дальше – больше, дальше – больше. Икенче көнне директор иптәш Сталинга телеграмма бирде. Эчтәлеге: татар мәктәбен рус кадрлары белән тутыру, укытучыларның үз телләрендә сөйләшүләрен тыю дөрес буламы, мәгънәсендә. Белмим, нинди җавап килер. Руслар – үзләренчә, без – үзебезчә. Әллә ничек кенә инде. Бит ачу килмәслек түгел. Татар населениесе өчен бернинди дә передачалар оештырылмый, татар телен ишетмиләр. Шушы мәктәп эчендә дә татарча сөйләшүне тыялар. Ничек җаның түзәр. Бит без дә кеше. Ниләр белән бетәр, әле белмибез. Нәрсә булса да, исем дә китми. Чөнки үземнең дөреслегемне сизәм. Тобольскига килеп, «сам хозяин Филлипов» белән ачуланышу үзе честь бит ул, ә?! Ха... ха... Бөтен кайгылар, борчылулар җиңә инде. Берничә көн рәттән Нинадан папирос алып тарттым. Бөтенләй бозылып бетәрмен мин монда. Бәйрәмдә вино эчкән идем, хәзер папирос тартам инде. Ачу килә шундый. Салкын.

Бу Себердә кеше ничек яши икән. Коточкыч салкын бит. Быел исән калсам, киләсе елга хәер бирер идем. Быел катармындыр кебек. Ну, ярый, Нурыйхан, син минем шундый хат язуыма ачуланма. Соң, сиңа язмый, кемгә языйм. Хәлгә керсәң, син керерсең. Әниләрне борчыйсы килми.

Инәкәй килдеме әле? Хәлең ничек? Нурыйхан, син минем Мәсхүдә апага җавап

яздыңмы? Нәрсә яздың? Гарафлар шәп тормый, диген, ә?! Тормыш шулайдыр инде. Көнләшәм, аларның бәбәйләре булачак, ә безнең юк. Фәниянең бар, ә безнең юк. Беркөнне учительскаяда бер рәсем килеп чыкты. Матур, күңелле семья, иренең куенында кечкенә кызчык. Шуннан мин әйтәм: «Менә Нурыйхан белән мин дә безнең кызыбыз», – дим. Директор шундый кызык җавап бирде, җир ярылса, җир астына керерсең. Бөтенебез – ха... ха... ха... күтәрелдек. Кая телгә андый сүз алу.

Нурыйхан, әтисе, ярый, хуш, сау бул! Сиңа күп сәлам белән, сәламәтлек, эшеңдә уңышлар теләп, синең җылак хатының Мин булып калам. Себер татарларының фразеологиясе бай гына. Берничә мисал җибәрермен. Кайчан сүзлек әзерлисең? Яз әле миңа. Монда Себер диалектын бик шәп өйрәнергә була. Җәләй абыйга хат язарга кирәк әле, сораулыклар җибәрсен иде.

Сиңа бүрек мәсьәләсен бераз хәл алгач карармын инде, яме, карт! Үземне рәтлим әле, бит салкын миңа монда. Итек, пальто рәтләргә кирәк. Син ачуланма, яме, мин ничек тә тырышырмын. Шәл бит бары 4 кенә көн килгән, просто замечательно. Әгәр бүрек рәтләсәм, ул да шулай гына барыр. Ләкин хәзергә булдыра алмыйм әле, атасы, гафу ит, яме.

Син хатларыңны еш яз, күп яз. Күрәсең, мин сирәк язсам да 4 бит язам, укый-укый туеп бетәрсең булыр. Барлык иптәшләргә дә сәлам әйт. Кара, колагыңны борырмын, кызларга күз салма, минем күңелем ерактан да сизә. Җибәр әле берәр карточкаңа төшеп. Нәрсә кыланып ятасың анда. Нигә урындыкны икене генә алдың? Ә мин кайткач, миңа утырырга кая?!

Иң кирәген язмаганмын.

Син, инәкәй килмичә, вак-төяк нәрсәләр алма. Инәкәй үзе белеп алыр. Матрац, простыня, одеяло... Барын да инәкәй үзе алыр. Ул күбрәк белә. Бәлки ул юрган да сырыр әле, үзенә дә, безгә дә. Аннан савыт-сабадан калай кружкалар алып маташма. Кирәге юк ул чүп-чарның. Без икебез дә университет бетергән кешеләр. Берьюлы бер 120 сумлык сервиз ал. Анда тулы бер семьялык савыт-саба була. Кеше-кара килгәндә дә йөзең якты була. Калай кружка белән яшәмәссең бит. Бальзакка язылырга кирәк булган, билгеле. Син бик пычрак йөрмә инде. Шапшак кешенең авторитеты нинди генә була бит. Хәтерлә, Мәҗиттән ничек көлә идең.

Койканы әйбәтне ал. Вак-төяккә акча әрәм итмә. Кайткач, колагыңны борырмын. Үзеңә кышкы пальто турында да уйла. Бит ул пальто белән йөри алмассың. Хәзер бит син просто «Нурый» түгел, ә **Н.Фәттахов**. Аңлыйсыңмы?!

Квартира хуҗаларың нинди кешеләр? Барына да сәлам әйт. Алар белән дуслыкта яшәргә тырыш. Ял итә-итә эшлә. Син үзеңне хәзер минем өчен дә сакларга тиешсең бит. Ә бер-ике елдан кечкенә Нурыйхан өчен сакларсың... Ха... ха. Әйеме?!

Ярый, хуш, бетерәм. Кичә яза башлаган хатны бүген бетерәм. Киләсе ял көнсез хат язмам сиңа, ә син 3 көн саен яз.

Синең Роза. 18/XI-51ел. (Конверт тышындагы адрес: г.Тобольск, Тюменская обл., ул. Пушкина, 46 (верх) Хафизовой Р.С.)» ■

ҖЫЛЫНДЫ СИНЕҢ УЧАКТА, ҖЫЛЫНДЫ НИЧӘ БУЫН!..

Эльмира Закирова

Болгариядән килгән кунаклар белән. Рәсемдә: беренче рәттә уртада – Роза Хафизова; басканнар: сулдан беренче – Айдар Үтәгәнов, Хәйдәр Гайнетдинов, Разил Вәлиев, Рафис Гыйззәтуллин, Эльмира Закирова, Фәния Хәйруллина, Фәиз Зөлкарнәй, Гүзәл Камалова. 1979 ел

ҖӘЛИЛЛӘР, АЛИШЛАР ЯЛКЫНЫ

«Ялкын» журналының зур юбилее алдыннан әлеге журнал редакциясендә эшләгән еллар кабат күз алдыннан үтә... Редакция тормышы, аерым бер шәхесләр, «Ялкын» юбилейлары... **Үземнән алдарак эшләгән баш редакторларымны рәхмәт хисләре белән искә төшерәм. Роза Хафизованың әниләрчә кайгыртучанлыгы, гаделлеге, Роза Туфитуллованың игелекле эшләре, гаҗәеп оештыру осталыгы, Җәүдәт Дәрзамановның гадилеге, ихласлыгы… Алар һәр балага шәхес итеп карадылар һәм безне дә шуңа өйрәттеләр…**

Энергиясе ташып торган Йолдыз Миңнуллинаны да искә алырга кирәктер.

Бүгенге көндә бу мәртәбәле журналның баш мөхәррире – Илназ Фазуллин.

Мин бу редакциядә эшләп рекорд куйдым, дисәм дә ялгыш булмас, чөнки хезмәт кенәгәмдә 1978 елдан 2011 елга кадәр бер генә эш урыны иде – «Ялкын» журналы редакциясе. Хәзер менә искә төшерәм дә... Ул истәлекләр, көндәлек битләре булып, шул елларга алып китә...

...Элеккеге журнал төпләмәләрен актарып, гарәп, латин язулы битләрдә тукталып калган тарихка әйләнеп кайтасың. Һәм журналны өр-яңадан ачкандай буласың. Якты, матур, самими, кызыклы булган икән бит «Ялкын»ыбыз! 40-50, хәтта 90-95 ел элек тә!.. Журналның иң беренче саны 1924 елның 20 мартында Мәскәүдә чыккан. Элеккеге Советлар Союзындагы балалар журналларының иң беренчесе, иң өлкәне булган ул. Исеме «Кечкенә иптәшләр» дип аталган. ВЛКСМ Үзәк Комитетында эшләүче 18 яшьлек шагыйрь егет Муса Җәлилгә беренче татар балалар журналын оештыру эшен тапшыралар. 1924 елда «Татарстан» газетасында иң элек аның 9-14 яшьлек балалар өчен журнал чыгарырга кирәклеге турындагы мәкаләсе басылып чыга. Соңрак Муса Җәлил әлеге журналга редактор итеп билгеләнә. Балаларның яраткан язучысы, Җәлилнең көрәштәш дусты Абдулла Алиш «Пионер каләме»нең җаваплы секретаре булып эшләгән. «Алиш редакциядә пионер галстугыннан йөргән», – дип, өлкән язучылар истәлекләр сөйли иде...

Журнал «Ялкын» булганчы берничә тапкыр исемен алыштырган әле. «Октябрь баласы», «Пионер каләме», «Пионер»... Илебездә «Пионер» исемле журналлар күбәеп киткәч, 1957 елда журналның исемен «Ялкын»га алыштыралар. Шул вакыттагы баш редактор Ләбибә Ихсанова тырышлыгы белән үзгәртелә ул.

Җәлил, Алишларның исемнәрен атауга ук, «Ялкын» гимнына әйләнеп киткән «Җәлилләр, Алишлар ялкыны» җыры искә төшә. Журналның 50 еллыгына әзерләнеп йөргән көннәрдә туа ул. Ул чакта Разил абый Вәлиев «Ялкын»да эшли, композитор Фасил Әхмәт редколлегия әгъзасы була. Икәүләп «Пионер ялкыны» дигән шул шәп җырны иҗат итәләр...

Разил абый Мәскәүдә Әдәбият институтын тәмамлап кайта «Ялкын»га. Шуңадырмы, ул җаваплы секретарь булуга, журналда гел кызыклы идеяләр, моңарчы күрелмәгән яңалыклар күренә, заманчалык, затлылык сизелә башлый. Журналның соңгы битендәге төрле халыкларның әкиятләрен тәрҗемә итеп бирүне дә ул уйлап таба. Ул әкиятләр хәзер дә бик популяр.

«Ялкын»да эшли генә башлаган чагым... Разил абыйның «Яшен тамыры» дигән шигырь китабы чыккан икән. Редакциядәгеләргә автографлар белән китабын бүләк итә. Һәркемгә үзенә генә туры килерлек сүзләрен дә тапкан.

«Күрерсең син күп нәрсәләр,
Очрамас кемнәр генә!
Тик онытма юл башыңны –
«Ялкын»лы көннәреңне!» –

дип язып бирде миңа.

Ә берсендә, Антуан де Сент-Экзюпериның «Нәни принц»ын татарчага тәрҗемә итеп чыгаргач, Разил абыйдан миңа мондыйрак теләкләр язылган китап эләкте: *«Һәрчак НӘНИләр кебек саф күңелле, ПРИНЦесса кебек гүзәл бул!»*

Бу теләкләр минем өчен тормыш шигаре булып тоелды.

Хәзер менә искә төшерәм дә... Сер, шатлык, кызыклы вакыйгалар, иҗат белән тулы рәхәт дөнья, хыял утравы булган икән ул «Ялкын».

БАРОН МЮНХГАУЗЕН... ГАБДЕЛХӘЙ АБЫЙ?..

«Мәктәптә укыганда ук «Ялкын»журналларында сан саен «баш редактор Роза Хафизова» дигән язуларны күрә идек. Ул чакта әллә ни игътибар ителмәгән: тизрәк әкият һәм хикәяләрен укырга, рәсемнәрен карарга ашыга идек бит. Көннәрдән беркөнне Роза апа мине эшкә алыр дип башыма да китереп карамадым.

1978 елның марты. Без, 5 нче курслар, диплом язып, эшләр белешкәләп йөрибез. Мин ул көнне бер-бер артлы ике хәбәрем белән төркемдәш кызларны телсез калдырдым бугай. Университетның Кызыл Позиция урамындагы атаклы 4 нче тулай торагына атылып кайтып кердем дә: «Мин бүгеннән «Ялкын» журналы редакторы!» – дип әйтеп салдым. Диплом җитәкчем Мөхәммәт абый Мәһдиевнең (ул да редколлегия әгъзасы иде!) «Ялкын»га барып карарга киңәш иткәнен белсәләр дә, кызларым журналда, редактордан соң тагын өлкән редактор, бүлек редакторы, баш редактор барын белми иде әле. Телем телгә йокмый, тезәм генә: Роза апа Хафизова – баш редактор, Разил абый Вәлиев – җаваплы секретарь, Фәннур Сафин белән Хәйдәр Гайнетдинов та шунда... Алар ушына килгәнче, икенче хәбәрем: «Ә минем өстәл – Габделхәй Сабитовныкы белән кара-каршы»!..

Юк, бу мактану түгел иде. Бу – шатлыгымның тышка бәреп чыгуы иде. Татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укучыларның күбесе – иҗади халык. Мәктәптә укыганда шигырь-хикәя язган, аны «Ялкын» редакциясенә юлламый калмаган. Һәм, әлбәттә инде, Габделхәй Сабитовтан хат та алган. Мастер-класска тиң хатлар ул. Менә кем белән янәшә утырам бит!.. Габделхәй абый, Хәйдәр, мин – өчәү бер бүлмәдә. Яңа кеше буларак, икесен дә күзәтеп, сүзләрен йотып, өйрәнеп утырам.

Берчак Разил абый кереп: «Безнең Барон кайда йөри микән?» – дип сорап куйды. Соңрак белдем: Эрих Распеның «Барон фон Мюнхгаузен маҗаралары»н тәрҗемә иткәне өчен, Габделхәй абыйны үзара шаяртып шулай йөртәләр икән. Рәссам Тавил Хаҗиәхмәтов та Мюнхгаузенны Габделхәй абый кебек озын какча йөзле, җирән чәчле итеп ясап куйган.

Габделхәй абыйның эш көне балалардан килгән хатларны укудан башлана иде. Күзлеген киеп куя да рәхәт бер дөньяда йөзә кебек. Еш кына аның: «Их-ма, егетләр! Шәп, шәп шигырь бит бу!» – дип сокланып, безгә эндәшкәләп куюы, йә, бүлмәне шәрран ярып, кычкырып көлгәне ишетелеп куя. Ул да булмый, кыштыр-кыштыр нидер яза башлый. Шигырь-хикәяләре өметле кызларга-малайларга ул шулай хат яза. Һәркайсына үз куллары белән, икешәр-өчәр бит тутырып... Хәтерлим, алар арасында Чуашстаннан Ркаил Зәйдуллин, Миңназыйм Сепперов, Актаныштан Ленарис Леронов, Чүпрәледән Рәмис Аймәтовлар бар иде...

Минем өстәлдә дә тау кадәр хатлар өеме. Барысына да җавап язарга кирәк. Габделхәй абый да, Хәйдәр дә, Фәннур да балаларга хатлар язып утыралар. Башкортстанның Миякә районыннан Галимов Айдар исемле малай, әнә, шигырьләрен җибәргән. Үскәч, ул атаклы җырчы Айдар Галимов булыр, дип, башыбызга да китермибез инде. Аңа «Ялкын»ның яшь хәбәрчесе» дигән таныклык җибәрәбез. Ә ул үзе соңрак, җырчы булып танылгач, болай искә төшерде: «Берзаман «Ялкын»да өч куплетлы шигырьнең берсе басылып чыкмасынмы! Миннән дә бәхетле кеше юк иде. Шуннан соң миңа бик күп хатлар килә башлады...»

Командировкалы, летучкалы, слетлы, марш-маршрутлы, пионер учаклы редакция тормышы миңа ошый, бик ошый! Минем өчен «Ялкын» – дөньяда иң шәп журнал, анда эшләүчеләр – дөньядагы иң талантлы кешеләр булып тоела...

РОЗА ХАФИЗОВА МӘКТӘБЕ

Баш редактор тыштан гына җитди, кырыс икән. Редакциягә килгән хатларның кайберләрен летучкада көлә-көлә кычкырып укый... Күптән түгел генә китап нәшриятында басылып чыккан китабын һәркайсыбызга автографы белән бүләк итә... Фәннурның кызы тугач, Роза апа исемне үзе сайлады: «Без әле кайтырбыз» повестендагы Айсылу!..

Бүгенге язучы-шагыйрьләрнең барысы да «Ялкын»да тәгәрәп үскән, Хафизова мәктәбен үткән, дисәм дә, ялгыш булмас. Мөдәррис Әгъләмов, Равил Фәйзуллин, Зөлфәт, Наис Гамбәр, Зиннур Мансуров, Рәшит Бәшәр, Рашат Низамиевлар... Ләбиб Лерон, Ркаил Зәйдулла, Ләис Зөлкарнәй, Газинур Моратлар...

Мөдәррис Әгъләмов Зәй районының Түбән Биш мәктәбендә укып йөргәндә үк кочак-кочак шигырьләр җибәреп тора, редакциядәгеләр аңа журнал үзе дә кереп утырырлык зу-ур конвертка салып хатлар юллыйлар, гонорар да язалар. Берчак шулай бу малай редакциягә үпкәләп хат яза: «Сез хатларыгызны миңа бала-чагага җибәргән кебек зур конвертта салмагыз бүтән!» – ди. Мәктәптә генә укыса да, исеме күренә башлаган шагыйрь бит! «Мөдәррис сүзенә колак салып, конвертларны кечрәйтергә туры

Рәсемдә: беренче рәттә сулдан беренче – Гүзәл Камалова, Эльмира Закирова, Роза Туфитуллова (баш мөхәррир), Рәшидә Сафина, Фәйрүзә Мөслимова; басканнар: Валерий Павлов, Халисә Нигъмәтуллина, Айдар Үтәганов, Хәйдәр Гайнетдинов, Газинур Морат, Ирек Нигъмәтҗанов. 31 декабрь, 1986 ел. В.Павлов фотосы

килде», – дип көлеп искә ала Роза апа. (Соңрак Мөдәррис Әгъләмов «Ялкын»ыбызга «Җылынды синең учакта, җылынды ничә буын!» дигән мәгълүм шигъри юлларын багышлый.)

Берсеннән-берсе талантлы шәхесләр редакторның «Ялкын»дагы таянычы була. Газиз Мөхәммәтшин, Илдар Юзеев, Габделхәй Сабитов, Разил Вәлиевләр... Ә редколлегиядә – Нәкый Исәнбәт, Гыйлем Камай, Җәүдәт Фәйзи, Нәби Дәүли, Әнвәр Бакиров, Фасил Әхмәтов кебек милләтебезнең асыл затлары! Әнә нинди абруйлы кешеләрне журналга тарта белгән ул.

Ул елларда журналның тиражы Советлар Союзында нәшер ителә торган күп журналларны узып китә. Мәктәпләрдән «Дружинабыз белән «Ялкын»га язылдык!», «Классыбызда бар да «Ялкын» алдыра!» дигән телеграммалар ява. Берәр язмасы йә шигыре, йә рәсеме басылган малайларга-кызларга «Яшь хәбәрче» таныклыгы җибәрүне дә Роза апа уйлап тапты. Никадәр баланы «Ялкын» юлламасы белән «Артек»ка, «Орленок»ка җибәрде ул...

Редакторыбызның журналистикада алтын кагыйдә булырлык киңәшләре байтак, алар инде күңелгә уелып калган.

Һәр мәкалә кечкенә бер хикәя кебек укылсын.

Кемгә атап язганыгызны бер минутка да истән чыгармагыз. Ун-унике яшьлек мәктәп баласын гел күз уңында тотыгыз!

Текстларны озын итеп язмагыз. Вак шрифт белән җыелган текстларны укып, баланың күзләре бозыла...

Балаларга «хөрмәтле» дип түгел, «кадерле» дип языйк хатларны.

Матур киенеп йөрегез, кайда эшлиләр, дигәндә, «Ялкын»да, диярлек булсын! Редакциягә, шәхсән Роза апа янына, Уфадан да, Чабаксардан да, Йошкар-Оладан да балалар журналлары редакторлары еш килә иде. Өйрәнергә, тәҗрибә тупларга дип... Без, журналистларның да офыклары киңәйсен, дөнья күрсеннәр, дип, йә Мәскәүгә,

Рәсемдә: беренче рәттә сулдан беренче – Эльмира Закирова, Җәүдәт Дәрзаман (баш мөхәррир); басканнар: Фәйрүзә Мөслимова, Әлфия Зәйнетдинова, Рәшидә Сафина, Ирек Нигъмәтҗанов, Гүзәл Камалова. Апрель, 1994 ел. Н.Седов фотосы

йә Ленинградка командировкаларга барырга җай чыгара. Һәм алар, әлбәттә, Роза апаның андагы коллегалары белән алдан сөйләшеп эшләнә. Берчак Гүзәл Камалова белән мине Ригага, латыш балалары өчен нәшер ителүче «Драугс» журналы редакциясенә җибәрде. Роза апаның алдан шалтыратып куюы бик ярады: баш редактор Эрика безне көтә иде инде.

Журналның 60 еллык юбилей санын әзерләгәндә ул мине Мәскәүгә командировкага җибәрде. Миңа Муса Җәлилнең хатыны Әминә апа, кызы Чулпан, оныгы Таня белән очрашып материал язарга (адресларын Рафаэль абый Мостафиннан алдым), генерал Якуб Чанышевтан истәлекләр сөйләтергә задание бирелде.

Шул 1984 елда журналыбызга СССР Верховный Советы Президиумы Указы нигезендә, яшь буынны тәрбияләүдәге нәтиҗәле эшчәнлеге өчен, «Почет билгесе» орденын тапшырдылар. Бу инде баш редактор Роза Хафизова эшенә дә олы бәя иде!

##ҺӘР БАЛАГА БАРЫП ҖИТӘРГӘ!

1986 елның җәй ахырында «Ялкын»га ВЛКСМның Татарстан өлкә комитетыннан яңа баш редактор китереп куйдылар. Хәер, китереп куйдылар, дигәч тә, безнең балалар матбугаты дөньясы өчен бөтенләй үк яңа кеше түгел инде. Күршедәге «Яшь ленинчы» газетасы редакторы, без белгән, аралашып йөргән Роза апа Туфитуллова сигезенче каттан тугызынчыга менеп кенә утырды. Дөресрәге, Мәскәүдән, ВЛКСМ Үзәк Комитетыннан баш редактор итеп раслап кайтардылар аны. Безнең күңелле, шул ук вакытта тынгысыз дөньябыз тагын да ямьләнебрәк китте. Әллә нинди кызыклы эшләр уйлап таба, үзе дә тик тормый, безне дә мавыктырып эшләтә, күңелләребезгә илһам сала белә торган булып чыкты баш редакторыбыз. Ул безне бөтенләй башка журналистикага алып кереп китте. Үзе дә Мәскәү журналистлары, үзәк матбугат вәкилләре белән якыннан аралаша. Редакциябездә Чехия, Польша журналистлары булып киткәне бар... Балалар дөньясын ничек тә җанландырып җибәрергә тели иде ул. Бала хокуклары турында хәзер күп язалар. Ә безнең «Ялкын»га ул тема Роза апа Туфитуллова белән бергә килеп керде шикелле. Балалар матбугатында самими, үзләре дә бала күңелле кешеләр эшләргә тиешлекне үз үрнәгендә безгә сеңдерергә тырышты ул. Журнал һәр баланың күңеленә барып җитәргә тиеш, дип, гел-гел әйтә килде. «Ялкын»да баш редактор булып эшләгәндә аны Татарстаннан ВЛКСМның XX съездына делегат итеп озаттык. Яшьләрнең һәм студентларның Мәскәүдә узган XII Бөтендөнья фестивалендә катнашуы да бездә горурлык уятты. Үзен әле «Вожатый» журналына, әле Бөтенсоюз пионер оешмасының Үзәк Советы аппаратына эшкә чакыра башладылар. «Юк, сезне ташлап беркая китмим», – дисә дә, ике елдан аны «Азат хатын»га баш редактор итеп билгеләп куйдылар. Роза апа белән күршеләр булып эшли башладык. Хатын-кызлар журналын җитәкләгәндә дә, соңрак Дәүләт Советы депутаты булгач та, Роза Рәхмәтулловна балалар дөньясына, балалар матбугатына һәрчак аерым бер игътибар, кайгырту белән карады. Журнал укучылар файдасына игелекле гамәлләр кылырга алынуларыбызның оеткысын да Роза апа салды безгә. Менә бу вакыйгада турыдан-туры катнашы бар аның.

Көннәрдән беркөнне редакциягә Мамадыш районының Катмыш мәктәбеннән бер хат килеп төште. Динар Вәлиәхмәтов исемле малайдан иде ул: «Исәнме, «Ялкын»! Берәрсе Динар «Ялкын»ны яратмый, дисә, ул дөньядагы иң зур ялганчы булыр иде. Әбием: «Салават күпере»енә генә язылырбыз инде, улым», – дигәч, велосипедка дигән акчамны бирдем – барыбер язылдым «Ялкын»га», – дип язган иде Динар. Велосипедка дигән акчасын жәлләми «Ялкын»га язылган малайны күрәсебез килде. Нindирәк икән ул? Чынлап та дөресен язганмы? Айсылу Галиеваны Мамадышка разведкага җибәрдек. Динарның тарихи китаплар укырга яратуын, әбисенә мал-туар карарга булышуын, тырыш бала булуын ачыклап кайтты журналистыбыз. Авылы Түбән Кыерлы гына мәктәптән ераграк икән – 5 километр. Җәй буена көтү көтеп акча җыюы юкка гына булмаган. Велосипед кирәк! Без Динарга сюрприз ясарга булдык. Менә шул чакта Татарстан Республикасы халык депутаты Роза апа Туфитуллова, безне хуплап, велосипедлык акчаны үзе бирде. Яңа ел алдыннан, машинага велосипед салып, Мамадыш районына баруларыбыз, Динар утырган класска керүләребез... Динарның сөенүләре! Ул велосипед... самолет булып күренде бугай инде аңа! Һәм үзебезгә дә!

Ә бу Роза апаның йөзләгән игелекле гамәлләреннән берсе генә әле...

«ЯЛКЫН»ЛЫ КӨННӘРЕМНӘН...

Роза апа Туфитуллованың мине Мәскәүгә, ВЛКСМ Үзәк Комитеты каршындагы Югары комсомол мәктәбенә укырга җибәрүен хәзер дә рәхмәтләр белән искә алам. Зур тәҗрибә мәктәбе булды ул. Латвия, Эстония, Грузия, Азәрбайҗан, Казахстан, Үзбәкстан – кыскасы, барлык союздаш республикаларның балалар журналларында эшләүчеләр белән аралашабыз, «Пионерская правда», «Пионер», «Комсомольская правда» редакцияләрендә булабыз, лекцияләрдә утырабыз. Безнең «Ялкын»ны барысы да белә! Соңрак, еллар узып, үзем «Ялкын»ның баш редакторы булгач, ул чакта Мәскәүдә ишетеп кайткан бер яңалыкны – балалар редколлегиясен үзебезнең журналга да керттем. Украинаның «Пионерия» журналы җаваплы секретаре сөйләгән иде ул хакта. Белмим, нигәдер Мәскәүдә тизрәк уйлый, җәһәтрәк кыймылдый башлыйсың кебек тоела. Анда, тизлек, масштаблар башкача. Кулымнан килсә, журналистларны берничә көнгә генә булса да Мәскәүгә җибәрер идем, дип күңелемә беркетеп куйдым. Бу хыялымны да тормышка ашырыр җай чыкты. 90 нчы еллар ахырында «Ялкын»да эшләп йөргән журфак студенты Айрат Бик-Булатов Юнпресс каршында чыгып килүче «Юношеская газета»га стажировкага барып кайтты. Ә «Ялкын»ның 75 еллыгын Мәскәүдә дә бәйрәм иттек (журналның беренче саны Мәскәүдә чыга бит!), башкалага бөтен редакциябез белән җыелып бардык. Кайларда гына булмадык, кемнәр белән генә очрашмадык! Татарстанның Вәкаләтле вәкиллеге, Асадуллаев йорты, Мәскәүдәге татар мәктәбе... Муса Җәлилнең кызы Чулпан ханым да оныклары белән килгән иде ул бәйрәмгә.

«Ялкын»ның актив хәбәрчеләрен РФ Дәүләт Думасына командировкага җибәрү тарихы да кызыклы булды. Дәүләт Думасы депутаты, журналыбызның якын дусты Илдар Гыйльметдинов редакциягә укучылар белән очрашуга килгәч, арадан берсе: «Ә безнең «Охотный ряд»ка, Дәүләт Думасына барасыбыз килә!» – дип әйтеп куймасынмы! Шунда: «Әйдәгез, оештырабыз! Бик рәхәтләнеп кабул итәрбез! Алина Кабаева белән очрашу кызык булыр сезгә», – дигән уңай җавап яңгырады.

«Оялчан алма», «Малайларга, кызларга», «Әдәбият дәресендә кунак бар», «Абитура», «Бер сүз белән»... Күптән хыялымда йөрткән, күп сораулар тудырган темаларым исә «Ялкын» рубрикалары булып китте. Үсмерләрне спорт, музыка, маҗаралар, мәхәббәт, төрле илләрдәге яшьтәшләре тормышы, бәхәсләр кызыксындырганын яхшы белә идек инде. Танылган кешеләрнең, язучыларның, артистларның беренче мәхәббәтләре турында яздыртырга и-и кызыгып йөрим! Шулай да башта үзебезнең редакция журналистларыннан башларга булдык. Ошаттылар укучыларыбыз! Аннары «Зөлфәт +..», «Наис +...», «Илсөяр +...», «Ркаил +...»ләр китте...

«Ялкын»га язып торучы малайлар-кызлар кыюлар, зирәкләр, күп укыйлар, күп беләләр, бәхәсләрдә катнашалар... Башка кызык идея килде: аларны Президент, Премьер-министр, министрлар белән очрашуларга йөртсәң!.. Фикерем авыздан очып та чыкты, безнекеләр күтәреп тә алдылар! Татарстанның Беренче Президенты Минтимер Шәймиев белән очрашуыбызны... балалар һәм үсмерләр редколлегиясе утырышы итеп, Кремльдә, Президент Сараенда үткәрдек. Ниләр турында гына сөйләшмәдек! Мактанасыбыз килеп, «Ялкын»да спорт, сәнгать, армия, бала хокуклары турында язабыз, дип саный башлаган идек, Минтимер Шәрипович: «Мәхәббәт тә бар!» – дип кушылып китте... Президент та укып бара журналыбызны дип и-и сөендек инде!.. Ул әле безгә «Кәеф» кушымтасының исеме турында да үз фикерен җиткерде. «Мин башка исемгә тукталмакчы булам. Менә хәзер генә уйлап таптым: «Чаткылар»! Очкыннан, чаткыдан ялкын кабына бит! Мин тәкъдим генә итәм. Үзегез карарсыз тагын»,

Безнең мирас №3 март 2019

– дигән иде ул. Минтимер Шәрипович белән булган эчкерсез сөйләшүдә нинди генә темалар кузгатмадык, Президентка нинди генә сораулар бирмәдек!

Безнең белән очрашуга, дип, авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Әхмәтовның сәгате-минуты белән вертолетта командировкадан кайтып төшүе, авыллардан килгән яшь хәбәрчеләребезнең чәй өстәле янында министр белән инвесторлар, фермерлар, авыллардагы юллар турында сөйләшеп утырулары истә...

2002 елда эчке эшләр министры булган Әсгать Сәфәров исә «Ялкын» кызларын-малайларын ул чакта әле Мәскәүдә дә, Питерда да булмаган гаҗәеп тирга алып кергән иде. Уңга-сулга, аска-өскә йөрешле мишеньнар... Безгә пистолеттан атып ка-

Кызу эш вакыты. Рәсемдә: сулдан уңга – Ләис Зөлкарнәй, Эльмира Закирова, Ләйсан Юнысова, Фәйрүзә Мөслимова, Гүзәл Камалова. 1990 нчы еллар

рарга рөхсәт иттеләр! Автоузышлар, самбо, детективлар яраткан генерал Сәфәровны без Эркюль Пуаро дип йөртә башладык...

...Журналыбызның да дәрәҗәсе, популярлыгы арта барды. Муса Җәлил, Абдулла Алиш премияләре лауреаты исеменә лаек булуы үзе үк күп нәрсә сөйли. «Ялкын» республика журналистларының «Бәллүр каләм» фестивале лауреаты булды, Россия матбугатының «Алтын фонды»на керде... Бу уңышларыбыз да «Ялкын» елъязмасында лаеклы урынын алды.

Автостоп, яки Татарстанның иң биек ноктасына «Ялкын» флагын кадап кайтулар... Флеш-моб, яки җир астында – Казан метросында – бер вагон халыкның «Ялкын» укып баруына ирешү... Летучка, яки «Ялкын»ның үсмерләр редколлегиясе белән берлектә журналның юбилей санын әзерләү... «85 еллыкта – 85 мәктәпкә!» исеме астында «Ялкын» десанты оештырулар...

Болар инде бар да тарихка кереп калды.

Ә Җәлилләр, Алишлар «Ялкын»ы бүген дә дөрләп яна, мәңгелек ут булып балкый! ■

ШАГЫЙРЬ ГОСМАН САДӘНЕҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Шагыйрь һәм журналист, «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» (1994) Госман Садә (Госман Мохтасар улы Зәйнетдинов) 1949 елның 23 февралендә Башкортстанның Аскын районы Әмир авылында туа. 1967-1972 елларда ул Уфада Башкорт дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый.

Г.Садә – 1988 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы.

Госман Садә басмада дөнья күргән өч шигъри китап авторы: «Мәхәббәт елы» (1985), «Җиләкле тәрәзәләр» (1987) һәм «Тайфун күзе» (1990».

Шагыйрь 2014 елның 14 гыйнварында вафат булды һәм Осиново зиратында җирләнде.

Госман Садә шигырьләре

ЯЗГЫ ҖЫР

Язгы кич... Бөреләр терелә,
Бөрегә бөреләр үрелә.
Күңелгә мәхәббәт юл яра.
Урамда күрше кыз Гөлнара,
Күзләре төнмени – чем-кара.
Гөлнара, яныңнан кем бара?

Кем бара, гитара уйнатып,
Гөлләрне җыр белән юатып?
Ул һаман кылларга кагыла.
Нинди моң! Кыллардан агыла,
Сыймыйча Агыйдел ярына:
«Йөрәкләр сөюдән ярыла-а-а».

Язгы су ярлардан артыла.
Ай чума агачлар артына.
Ояла, тартына-тартына,
Кочаклар кочакка тартыла.
Кайдадыр аккошлар коена.
Аккоштай ак нурлар коела.

О, керсез мәхәббәт! Каршыла.
Калыкты дүрт егет каршыңа.
Пычаклар... Салкын нур ялтырый.
Куркудан бөреләр калтырый.
– Яр юлы өеңә кайтара,
Курыкма, бар йөгер, Гөлнара!

Гөлнара, бар йөгер. Карама! –
Соңгы сүз яр буйлап тарала.
– Күрегез, сөюем бер кочак!
...Кадала кочакка дүрт пычак.
Язгы кич... бөреләр йомылган,
Бөреләр кан белән юылган.

Кайгыдай кара күз Гөлнара.
Яр буйлап кайларга ул бара?
И елый, өзелә, сызлана,
Сызлана гөнаһсыз кыз бала.
Күңелгә таныш җыр кагыла.
«Йөрәкләр сөюдән ярыла-а-а,
Йөрәкләр...»

ЮГАЛТУ

Бик кыендыр чаганга
Соңгы яфрагын кою.
Унлата кыен миңа
Синең юклыкны тою.

Сыгыла, елый чаган, –
Еларга кем дә белә.
Сыгылмас, сынмас өчен
Күңел ныклыгы телә.

Яфраклар оча бары –
Югалту шушы бугай.
...Ә күктә ай дерелди
Шул чаган яфрагыдай. ■



Госман Садә (беренче рәттә уртада) БДУда укыганда төркемдәшләре белән. 1967 ел

СӨЕМБИКӘ

Ольга Иванова

ТӘРҖЕМӘЧЕДӘН:

Ниһаять, хөрмәтле укучым, «Казан ханбикәләре» дигән гомуми исем белән аталган тарихи трилогиянең ахырына якынлашып киләбез. Узган саннарда урыс кызы Ольга Ивановнаны бу өч романны язарга этәргән сәбәпләрне күздән кичергән идек инде. Кыскача гына әйткәндә, әле яшүсмер чагында ук тарихи әсәрләр язарга омтылган кызның күңел түрендә әлеге хыял лаеклы урын алганын, каләменә тарихның (татар тарихының!) табигый рәвештә «уралган» булуын белдек.

Нугай Урдасы хакиме кызлары Нурсолтан белән Шаһназны Казан ханының ике улына килен итеп төшерүләре, аларның шактый катлаулы язмышы берәүне дә битараф калдырмагандыр, шәт. Шулай да киң катлам замандаш укучыларыбызга Сөембикә исеме үзрәк, танышрак, якынрак та кебек.

Иң элек, бу уңайдан, халыкта «Хан мәчете» дип йөртелгән һәм чынында да үз заманында мәчет манарасы булганлыгы шиксез Сөембикә манарасы турында берничә сүз әйтеп китмәсәк, килешмәс иде. Аны, имештер, Алексей патша яки аның атасы салдырган булуы күренекле тарихчы галимнәр (Габделбари Баттал, ә безнең заманда – халкыбызның газиз истәлеге булган манара-мәчет очына ярым ай куйдыру хәстәре белән утларга кергән Равил Фәхретдинов һ.б.) тарафыннан инде күптән кире кагылды. Әлбәттә, бу мәшһүр манара риваятьләр белән уралган. Шунысы бәхәссез: һәр риваятьнең төбендә чынбарлыкка мәгънәви ишарә ята...

Мәгълүм булганча, Сөембикә (ул чор галимнәре, мәсәлән, Һади Атласи язылышында – Сөенбикә) – Олы Нугай урдасы хакиме Йосыф бәкнең кызы, Казан ханлыгының соңгы чоры, фаҗигале язмышы шаһиты. Ул төрле чорларда Җангали һәм Сафагәрәй ханнарның хәләл җефете булып, ике яшьлек улы Үтәмешгәрәй, атасы Сафагәрәй вафатыннан соң, Казан ханы итеп күтәрелгәч (1549-1551 елларда), ханлык белән идарә итә. Казан ханлыгы бәйсезлеген югалтканнан соң, тәхеттән төшерелеп, улы белән бергә Мәскәүгә озатыла, җаны тартмаган Шаһгалигә (Карл Фукс язылышында – Шәехгалигә) хатын итеп бирелә. Атасы Йосыфның Сөембикәне Явыз Иван тоткынлыгыннан азат итүләрен сорап кат-кат мөрәҗәгать итүләре кире кагыла. Үтәмешгәрәй исә әнисе белән бергә Касыймның «курчак» ханы Шаһгали хозурына озатыла, шунда чукындырыла һәм Александр исемен алырга мәҗбүр ителә. Ул, егерме яшендә һәлак ителеп, Мәскәүнең Архангель зиратына күмелә.

Ольга Ефимовна исә, үз вакытында Казан түрәләренең берсенә мөрәҗәгать итеп, әдәби һәм гыйльми җәмәгатьчелек тарафыннан хупланган әсәрен бастырып чыгарырга ярдәм сорагач, аның: «Сөембикә?! Кем соң ул? Хәрәмханәләрдә ләззәт чигеп, манарадан ташланган бер хатын бит...» – дигән көенечле сүзләрен генә ишетә...

...Казанга Җыен кояшлы җомга көнне килде. Сөекле бәйрәмгә кичтән үк читтән кайткан кунаклар белән болай да ташып тулган башкала миһманханәләре юлчыларны түземсезләнеп көтә иде. Казанлыларның тирә-күрше авылларда яшәүче туганнары да таң атар-атмастан ук килеп җиттеләр. Тар урамнар һәм бистәләрне агач

«Сөембикә». Билгесез рәссам эше

тәгәрмәчләрнең шатланып шыгырдавы күмде, аллы-гөлле тасмалар белән бизәлгән атлар, куе ялларына уралган кечкенә кыңгырауларын шылтырата-шылтырата, арба-олауларын тартып керделәр. Олауларда киенгән-ясанган ирләр белән аларның хатыннары утырышкан. Яннарындагы тиктормас онык-сабыйлары, башларын бора-бора, чыпчык кебек чыркылдаша. Яшь киленнәр, як-якка караштырып, таныш урыннарны күргәндә сөенеп елмаюларын яшерә алмыйлар, шулай да кәрҗиннәрдәге күчтәнәчләренә күз салып алгаларга да онытмыйлар. Ә кәрҗиннәрдә – чигүле сөлгеләргә төрелгән вак бәлешләр, каклаган каз түшкәләре, мае тамып торган бавырсаклар. Боларның барысы да алдан ук әзерләп куелган, киленчәкләр аларны әле күптән түгел генә үзләре «очкан» ата-ана оясына алып кайтырга ниятләп торалар. Гәрчә гаилә тормышы аларны тирә-күрше авылларга һәм даругаларга тараткан булып, үзләре үк: «Насыйбыма язган ирем белән торам, мине кабул итеп алган йортта йокым татлы, Аллаһының рәхмәтенә шөкер», – дип яшәсәләр дә, барыбер хуш исле икмәк, нарасый чакта имгән сөт тәме туган нигезгә тарта.

Бистәләрдән күңелле шау-шу ишетелә, капкалар киң итеп ачылган, һәркайдан кадерле кунакларга: «Хуш киләсез!», «Түрдән узыгыз!» – дигән сүзләр яңгырый. Туган-тумачаның дәстәрханнары җәелгән, кызлар исә юл тузаннарын, арбада озак килүдән талган-талчыккан аякларын юып алу өчен тасларын, җылы сулы комганнарын чыгарып тора.

Халык өйлә намазына кадәр үк Хан болынына агылды. Авыллардан килүчеләр, ризык белән тулы эскәтерләрен җәеп, чирәмнән урын алды. Нугайдан һәм Хаҗитархан җирләреннән кайткан кунаклар түгәрәк чатырларына нәсел-нәсәбе белән кереп урнаштылар. Түгәрәк өйнең түре юк, диешеп, эчке якка ап-ак киез түшәп, кечесеннән алып олысына кадәр шунда утырттылар.

Сөембикә ханбикә сөенеп чөкердәшкән, чуклы-матур киемнәр кигән, чамасын белеп кенә бизәнгән кешеләр арасыннан яраннары уртасында узды. Тирә-юньдә бер-берсе белән байтактан күрешмәгән туган-тумачалар утыра, сәламләшә. Картлар, кочаклашып, саран күз яшьләрен сөртә, җитлеккән ир-егетләр тыелып, вәкарь белән генә баш кагып исәнләшә, хуплап, бер-берсенең җилкәсеннән кага. Ә хатыннар балалары белән мактаныша, чыр-чу килеп болынлыкта йөгерешкән ташбашларны тотып-тотып ала. Казан ханбикәсен һәркайда таныйлар, бил бөгеп озатып калалар. Нәсел аксакаллары аңа хөрмәтләрен күрсәтергә ашыга, аксакалның сәламен хуплап, якын-тирәдәге халык төркеме дистәләгән аваз белән күтәреп ала. Сөембикә, һәр түгәрәк каршысында туктап, кулларын күкрәгенә кушыра, кайберләренә ихтирамын күрсәтеп башын ия, ә кайсыберләренә мөлаем елмаюы һәм җылы сүзләре белән рәхмәт укый. Тамырлары мәшһүр Идегәйдән килүче нугай ыруы вәкиле Бунчукны ханбикә ерактан ук күреп алды. Сөембикә кан кардәшләре арасына җиңелчә дулкынланып керде, билен шулкадәр түбән иеп сәлам бирде ки, хәтта башындагы алтын һәм мәрҗәннәр белән чигелгән биек калфак та авышып-селкенеп куйды. Аңа каршы аксакал Байтирәк морза торып басты һәм йола буенча, касәгә салынган кымызны сонды. Бу борынгы тирән касә – чит-читләре инде теш эзләре белән кимерелә-кимерелә «бизәкләнеп» беткән савыт – буыннан-буынга күчкән иң изге, иң кадерле ядкәрләрнең берсе. Риваятьләрдә аңардан Идегәй үзе кымыз эчкән санала. Сөембикә, гаять дулкынланып, касәне кулларына алды, судай вакыт агышы төсен үзгәрткән агачка иреннәрен тидерде, нугай кымызының таныш әчкелтем татымын тойды. Аның гомерендә дә мондый тансык эчемлек татыганы юк иде. Риваятьләр белән урап алынган бу борынгы касә гап-гади кымызга тылсымлы һәм башларны әйләндерерлек тәм

биргән. Йосыф бәк кызы, салкын чишмәгә капланган кебек, салкын кымыздан туймыйча, касәдән иреннәрен аера алмады.

Ә алда инде, күк күкрәткән тавышлар белән, сөрән салучылар көрәшкә чыгасы ир-егетләрне һәм тамаша карарга килгән халыкны мәйданга өндәде:

– Көрәш! Иң гаярь батырларның бил алышуы башлана!

– Мәйданга ашыгыгыз!

Сөембикә хан чатырына ашыгып кайтса, анда Сафагәрәйнең хатыннарын һәм балаларын гына күрде. Ул затлы келәм өстенә җәеп куелган бай дәстәрханга тезләнде, чия ширбәте белән тулы кубокны аякчы кулыннан алды да янәшәсендә торган хатынга шыпырт кына эндәште:

– Фирүзә бикә, монда хуҗа күренмәдеме?

Кече хатын башын чайкап куйды:

– Ул Кырымнан килгән кунаклар белән ауга киткән, дип әйттеләр.

– Җыен вакытындамы?! – дип гаҗәпкә калды Сөембикә. – Көрәш батырларына һәм егетләргә бүләкне кем тапшыра инде?

Ханның, казанлылар бәйрәмен ташлап, гамьсез генә кәеф-корып йөрүенә хәтере калып, урынында утыра алмыйча, чатырдан чыгып китәргә мәҗбүр булды ул. Сафагәрәй үз-үзен онытып ауга бирелгән төшкә – Кабан-Сарайга ашыкты. Хаким иренең аягына ташланып, аны акылга килергә өндисе, үз-үзен болай тотышы белән шәһәр халкын һәм аның кунакларын мыскыл итүен аңлатасы иде Сөембикә... Хакимнең яр буендагы хәрәмханәсе янында төсле пыялалар белән бизәлгән киң урындыгы булган зиннәтле көймә дә көтеп тора икән әнә. Ханбикә инде ау аланына барырга җыенган иде, тик бу якка чаптырып килүче җайдакларны күреп кенә тукталып калды. Иң алдан, акбүз атын камчылап, Сафагәрәй үзе килә иде. Сөйгәнен йөрәге белән ерактан ук сизеп-чамалап, ханбикә ярты юлда тукталып калды. Хан үзе кебек үк мәһабәт юртакка тәмам берегеп утырган иде. Сөембикә кулларын күкрәгенә кушырды, Сафагәрәйнең атыннан җиңел генә сикереп төшүен, тезгенен ат иярләп килүче хезмәтчесе кулына ташлавын, үз ягына карап-карап алса да, якын ук килмичә, сәламен баш кагып кына алуын дәшми-тынмый күзәтеп торды. Ханбикәнең күзләре тыелгысыз ачы яшьләр белән мөлдерәмә тулды, тик аның, яшен тыеп, бары тик Сафагәрәй һәм аның бәйрәм уртасына җәһәт кенә кереп югалган юлдаш-җайдаклары артыннан өметсез карап калудан башка чарасы юк. Соңгы көннәрне аларны бер сәбәпсез, аңлатып булмастай аерган тойгы югалмады, ә Сөембикә, бу күренекле бәйрәм яңадан кавыштырыр, өсләренә ябырылган кара пәрдәне алып ташлар әле, дип ышана язган иде бит. Ханбикә, үзенең Җыен хуҗасы икәнлеген аңлап, сагышка бирелергә хакы юклыгын истә тотканга, йөрәк сыкравын басып, көрәш мәйданына юнәлде.

Тәңрекол бәк мәйданнан ерак та түгел үз чатырын корган икән. Айнур килен, биек калфагы белән чатыр түбәсендәге чаршауга тимәс өчен башын ия төшеп, аланга чыкты. Бәк төрекмән-текиннар кабиләсе яшәгән ерак сахрадан кайтарткан яшь айгырны чабышка куйган иде. Тәңрекол җәмәгате белән Данияр морза, бер төркем ачыгавызлар чолганышында, айгырны төрле яклап тикшергән-тасвирлаган булдылар. Кәрван юллары борын-борыннан аларның комлыкларыннан узганда, фарсы, мисыр айгырларының бәрәкәтле орлыгы, шул аргамакны дөньяга китергән биянең затлы канына кушылып, уңдырышлы туфракка төшеп өлгергән, күрәсең...

Дәвамы бар

*Урысчадан **Мөдәррис Вәлиев** тәрҗемәсе* ■

ӘМИРХАН ЕНИКИНЕҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ

ӘМИРХАН АГА САГЫНДЫРА

Әгъзам Фәйзрахманов

Язучының күпчелек вакыты менә шулай өстәл янында үтте. Наил Курамшин фотосы

Миңа Әмирхан Еники белән шактый еш очрашып, аралашып яшәргә туры килде. Университетны тәмамлап, «Социалистик Татарстан» газетасы редакциясендә эшли башлагач, ул вакытта ук инде үзенең талантын күрсәтергә өлгергән әдип белән якыннан таныштым. Әлеге чорда редакция секретариатында сугыш ветераны Шәрәф ага Мөдәррис тә эшләде. Уртак фикерләре күп булгандыр, күрәсең, алар тәрәзә янына барып утырып, тәмләп сөйләшергә яратты. Ш.Мөдәррис белән сүз-әңгәмәсен тәмам иткәч, Әмирхан ага безнең янга килеп, тормыш-көнкүрешебез белән кызыксынып ала иде.

Телевидениедә эшләгән вакытта да миңа Ә.Еникине студиягә еш чакырырга, чыгышларын әзерләргә, аның турындагы тапшыруларны редакцияләргә туры килде. Соңрак газета-журналларда эшләгәндә дә элемтәләр өзелмәде. Аның әсәрләрен, иҗатын пропагандалауда, өлешчә генә булса да, мин дә катнаштым. 1999 елда, мин бахырыгыз «Татарстан» журналы баш мөхәрриренең беренче урынбасары булып эшләгән чорда, без әдипкә 90 яшь тулу уңаеннан интервью бастырдык. Әңгәмәнең исеме дә үзенчәлекле иде: «Минем кем икәнемне, әнә, хикәяләрем әйтер...» Бу Әмирхан аганың үз сүзләре.

Кызганыч, әлеге юбилей язучының туган көннәрен соңгы үткәрүе булды. Ул туксан бер яшь туларга ике атна калганда безнең арадан китеп барды. Бу уңайдан «Татарстан» журналында республика Язучылар берлеге рәисе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Фоат Галимуллинның мәкаләсе басылды. Ул мондый сүзләр белән тәмамлана: «Ә.Еники үзенең бөтен гомерен туган халкына хезмәт итүгә багышлады. Шуның өчен халкыбыз аның үзен дә чын күңелдән яратты, йөрәгенә якын итте. Аны соңгы юлга озатканда да бу аермачык күренде. Әмирхан ага Еники өчен кояш баеды, әмма халкыбыз кояшы офыктан биегрәк, күк гөмбәзенең уртасыннанрак күтәрелсен иде. Аксакал язучының бөтен теләге шул булды».

Соңгы елларда язылган әсәрләренә Ә.Еники «Соңгы китап», «Кояш баер алдыннан», «Санаулы көннәр», «Таң ата да кич була» дигән моңсу, бераз сәеррәк тоелучы исемнәрне биргән. Билгеле, язучы гомер финишы якынаюын тоймый калмагандыр, гомер озуына уфтангандыр.

Татарстанның халык язучысы, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Әмирхан Еникинең «Бер генә сәгатькә», «Тауларга карап», «Кем җырлады?», «Матурлык», «Төнге тамчылар», «Әйтелмәгән васыять», «Тынычлану» кебек хикәяләре, «Саз чәчәге», «Йөрәк сере», «Рәшә», «Гөләндәм туташ хатирәсе» повестьлары – әдәбиятыбызның иң камил, иң күркәм үрнәкләре. Чын язучы буларак, ул үзе кирәк тапканны, намусы кушканны язмый булдыра алмады. Аның күңелен һәрчак дөньяның киләчәге борчыды, хәзерге заманның рәхимсезлекләре газаплады.

Ә.Еники геройларының күңел дөньяларын җентекләп тасвирлауга игътибарлы булды. Кайсы гына әсәренә карасаң да, шушы үзенчәлек алгы планга чыга, геройларының җанында барган уй-хис хәрәкәте укучыны биләп ала. «Классик әдибебез чагыштырмача аз язды, ләкин һәр әсәренең нигезенә мөһим фикер салды, аны укучының җанын кузгатырлык итеп әйтә белде. Шуның белән әдәби иҗат кешесенең абруен күтәрде, үзенең байтак каләмдәшенә остаз булды. Дөрес, ул остазлыгы турында сиздермәскә тырышты, аны әйтеп йөрмәде. Хәзерге татар әдәбиятында затлы әсәрләр тууда Әмирхан ага Еники үрнәгенең әһәмияте аз булмады», – дип язды Ф.Галимуллин.

Ә.Еники – авыр тормыш юлы узган шәхес. Аның «Сәүдәгәр малае», дип беркая укырга алмыйлар, язган әсәрләрен дә бастырмыйлар. Сталин каһәрләре заманы башлангач, ул әдәбияттан читкә китә, 1930-1941 елларда язмыйча тора. Сугыш чорында иҗаты активлашса да, сугыштан соң аңа мөнәсәбәт тагын үзгәрә. Әсәрләрен басмыйлар.

Әдипне 90 яше белән Фәрит Мөхәммәтшин тәбрикли.

Наил Курамшин фотосы

Әмирхан ага балалар арасында

Әмирхан ага хатыны Наҗия ханым белән.

Василий Александров фотосы

Язучының әйтүенә караганда, «Тауларга карап» дигән әсәре, дөнья күрмичә, 16 ел ята. «Рәшә»не, «Саз чәчәге»н дә бастырмый йөдәтәләр.

Инде нык танылып өлгергәч тә, Ә.Еники рәсми хакимият белән үзе арасында һәрвакыт тиешле араны саклады. Бу исә аңа теләсә кайчан үз сүзен кистереп әйтү мөмкинлеген тудырды. Әмирхан ага, татар халкы өчен генә түгел, бөтен төрки әдәбиятларның да үз язучысы иде. Аны казакъ, үзбәк, кыргыз, төрекмәннәр дә якын күрде.

Язмамны әдипнең үз сүзләре белән тәмамларга булдым. Ул болай дигән иде: «Язуга мин талымсыз булмадым. Һәрвакыт теләгем бер иде: кеше кулына алгач, әсәрең укырлык булсын, укып чыксын, укып чыккач, тиз генә онытмасын. Мин акча өчен дә, дан өчен дә язмадым. Аларда саф мин үзем. Башкасын бер Ходай үзе ярлыкасын!»...

Бөек язучыбызның тууына 110 ел тулган көннәрдә аның бу сүзләре бигрәк тә актуаль яңгырый кебек. Алар халкыбыз тарихына да кереп калды инде, киләсе буыннар өчен дә үрнәк булып торыр. ■

Бакый Урманче

«Зур эшләргә көч, кабилият, мәхәббәт сизелә үзегездә»

(Бакый Урманче һәм Флора Әхмәтова-Урманче хатлары)

Бакый Урманче һәм Флора апа белән аз булса да аралашып калдым. Флора апа Әхмәтова-Урманче байтак еллар «Сөембикә» журналының редколлегия әгъзасы булып торды. Утырышка килүенең берсендә минем иҗатны күзәтеп барулары, газета-журналларда чыккан шигырьләремнең Бакый Урманченың да, үзенең дә күңелләренә хуш килүе турында әйтте. 1984 елда «Яңгыр җиле» исемле китабым чыккач, Бакый абый китабымны соратып алды. Мин аны автограф белән бүләк иттем. Алга таба «Мизгел» һәм «Гөлләр елы» исемле китапларымны да.

Барганнарымда Флора апа чәй тәкъдим итмичә җибәрми иде. Мөнәсәбәтләре шулкадәр матур, иргә шулкадәр тәрбия-хөрмәт – соклангыч татулык! Күңелләрендә аерым шәхесләргә аерым бер хөрмәт. Хәтта бервакыт Әмирхан Еникиләр белән бер табынга чакырулы булдым. Флора апа кечкенә табаларда, өстен камыр белән капламыйча, төрле төстәге пироглар пешергән. Мүк җиләгеннән – кызыл, лимоннан – сары, кара карлыганнан – күгелҗем. Алар табынны шулкадәр матур итеп бизәп торалар. Тәмнәре дә ашап туйгысыз иде.

Бакый Урманче искиткеч авыр да, катлаулы да тормыш юлы үткән кеше бит инде. Әмма хәтере яхшы, белеме зур, сүзгә оста, истәлекләргә бай. Шул ук вакытта күтәренке күңелле, шаян да. Бер барганымда, аш өстәле янында кечкенә, тирән агач савытта (бәлки кул килесе дип атарга кирәктер?) нәни агач тукмак белән киндер ор-

лыгы изеп утыра. Иҗатын олылаучыларның берсе көчтәнәч итеп китергән икән. Һәм ул орлык ир-атларның егәр-көчен киметмәс өчен бик файдалы, имеш...

1986 елда Бакый Урманче портретымны күмер белән ясады. Остаханәсендәге журналына (бәлки ул көндәлек булгандыр) кызларымның исемнәрен, туган елларын сорап, язып куйды. Нигә ул, дигәч, мин үлгәч бер килеп чыгар, дип җавап бирде. Портретымны майлы буяу белән эшләргә теләвен әйтте. Ләкин аның өчен 180 сәгать кирәклеген белгәч, йөреп бетерә алмам, дип, ризалашмадым.

1997 елда, Бакый Урманченың вафатыннан соң, «Мәгариф» журналы өчен, «Урманче мәктәбе» исемле мәкалә яздым. (Ул мәкалә 2005 елда дөнья күргән «Казаныңа ни салсаң?..» исемле китабыма да керде.) Флора апа бик шатланды. Редакциягә алып килеп, Бакый Урманченың Татарстан китап нәшрияты бастырып чыгарган: «Бакый Урманче. График портретлар» исемле китабын бүләк итте. Рәссамның 100 еллыгына нәшер ителгән бу альбомга Флора апа минем дә портретымны керткән иде.

Бүгенге көндә архивымда Бакый абый белән Флора апаның китапларымны укыгач язган берничә хаты да саклана.

Эльмира Шәрифуллина

ӘЛМИРӘ!

Шигырьләрегезне инде берничә тапкыр кулга алдым. Китабыгыз һаман да алдымда. Шигырьне барысын берьюлы, хикәя укыган кебек укып чыгып булмый бит. Кулга аласың, берничә шигырьне күңел биреп укыйсың, шуннан алган тойгыларны күңелдән кичерәсең.

Китапны, изге хатирәләр тулган тылсымлы тартма кебек (әгәр чыннан да шигырь булса), саклык белән генә каплап куясың. Вакыты белән янә ачып карыйсың, янә укыйсың. Яхшы ясалган сурәткә кат-кат карыйсы килгән кебек, гүзәл аһәңле музыка әсәрен кат-кат тыңлыйсы килгән кебек, сәүгән ярың һаман синең янында булуын теләгән кебек – Сезнең самимият тулы, изге хисләр кизләве кебек, татар теленең матурлыгын белеп язылган шигырьләрегез әнә шундый. Алардагы тойгылар да һәм ул тойгыларны чибәр ана телебездә ифадә итә алуыгыз да – татар поэзия хәзинәсенә тапшырган кыйммәтле бүләгегез.

Әгәр минем алган әсәрләнүем берәр кыйммәткә ия була алса, мин дә бу язганымны самимият белән, чын күңелдән яздым.

***Габделбакый.** Казан, июнь, 1984 ел.*

КАДЕРЛЕ ЭЛЬМИРА!

Сезгә бик күп сәламнәр белән Бакый ага һәм Флора апагыз.

Бик зур рәхмәт – 1 Май бәйрәменә матур бүләк ясагансыз «Мизгел» дигән китабыгызны җибәреп. Иң әүвәл яңа китап чыгаруыгыз белән котлыйбыз. Актив эшләвегезгә шатланабыз һәм үзенчәлекле һәйкәл куйгансыз Фаилгә. Кем уйлаган шулай да язып була дип: зур иҗат биографиясен дә, олы мәхәббәт, самими хисләр картинасын да бер кечкенә «Мизгел»гә сыйдырып була икән! Димәк, кабатланмас сәнгать әсәре. Язуыгыз гадәттәгечә: агып тора торган хикәяләү, тыгыз фикер, ташып торган хисләр, олы җанлылык. Чын татар хатыннарына хас сабырлык, каядыр тирән яшерелгән көч, чыдамлык, балаларны ярату, горурлык.

Боларга сокланмый мөмкин түгел. Бер урында төртелеп, канәгатьсезлек хисе кичереп, тукталып калмыйсың. Китап бер тында укыла.

Кичә бәйрәм көнне алдык та кич укып чыгарга булдык. Бакый ага иртә йоклый, шулай да тын да алмыйча тыңлады. «Бу – поэзия, йә проза белән язылган мөнәҗәт», – ди. Минем алай әйтәсем килми, шулай да эпиклык монда да бар.





Казан, 02.05.86.

Кадерле Эльмира!

Сезгә бик күп сәламнәр белән Бакый ага һәм Флора апагыз.

Фаил Шәфигуллин

«Яңгыр җиле»н бик яраткан идек, шигырьләре әле дә күңелдә, рецензияләр дә хәтердә. Ләкин үзебез яза алмадык. Бакый ага бусына да талпынды язарга. Әмма элеккечә күп яза алмый шул хәзер. Инде миңа диктофон да көйләргә вакыттыр аңа. Сөйләвендә әле логик эзлеклелекне югалтмый. Шул ук сүзләрне язып куяр өчен дип утырса, «үз эшләрем», дип, вакытын кызгана башлый. (90!)

Икенче повестьны үзем генә укыдым, ул йоклап китте. Бүген гел сөйләшәбез үзегез, әсәрегез турында. Кызларның рәсемнәрен күрсәтеп китмисезме? Кайсы сәнгатькә маилләр? Сез икегез дә талант иярләре булгансыз. Мин ничек, кайчан язып өлгерүегезгә дә шаккатам. Ул өлгерү үзе бер талант бит, яхшы тәрбия алгансыз, кызларыгызны да яхшы тәрбиялисез. Шулай нык торыгыз, сынмагыз, сыгылмагыз (киңәшләрдән туясыздыр, бу – теләк). Уйландыра әсәрегез, мине бигрәк тә. Зөлфия олы мәхәббәтен сурәтләү белән Зөлфия булды. Надираның олылардай лаеклы кешесе булмаган. Сез лаеклы саф мәхәббәтегезне дә олылап күрсәтә аласыз. Киләчәктә дә зур-зур уңышлар телибез сезгә, Эльмира.

Сезнең багышламагыз ук ошады Бакый абыйга. Хәтта шагыйрь кешеләр дә: «Бакый агага», – дип язсалар: «Бу – гага икән», – дип куя. Сез тагы, гади һәм оста итеп, ул «гага»дан котылгансыз, шагыйрә булуыгыз шунда ук сизелә. «Бакый ага белән Флора апага...» – гади һәм дөрес! Ничек башкалар башына килми шул? Зур рәхмәт, Эльмира! Яңа китапларыгызны көтәбез.

Сәлам белән **Флора, Бакый ага**.

Эльмира Шәрифуллина һәм Фаил Шәфигуллин кызлары Раушания (сулда) һәм Резеда белән

P.S. Мин оныттым: «Яңгыр җиле»н укыгач язган хатларыбызны Сезгә җибәрдекме? Бакый ага кадимчә, мин болай язган идек. Флора.

Казан, 02.05.86.

ЭЛЬМИРА!

Бу беренче тәэссорат кына, аны берәр мәкалә язганда файдаланырбыз, дип саклаганбыз. Ә мәкаләне «Яңгыр җиле»нә озак көттек, Әмир[1] дә, Нурихан[2] да ул кызыксынуны басмады. Әмма үзебез дә яза алмадык, тиешле кешеләреннән көтү сәбәпле.

Мин һаман гаҗәпләнәм, нигә булмады ул: «Туды! Яңа шагыйрәбез туды, ура!» – кебек авазлар? Әлегә үзегездәге кебек сабырлык һәм нәтиҗә Союзга алу булды, күрәсең.

Менә бит, кат-кат килеп укып, гаҗәпләнәсең:

«Сездер минем сер сандыгым,
Серемә – йозакларым.
Тылсымлы көзгедер лә сез –
Кызларым – кыз чакларым!»

Кем шулай әйтә алды Сезгә хәтле?!

Ә «Мизгел» һаман яши безнең өйдә. Хәтта Фаилнең бу ишектән килеп кереп, аяк киемнәрен салып: «Исәнмесез, Бакый абый!» – дия-дия үтүе күз алдына килә торган булды. «Ашыгыч кына язарга туры килде», – дип, мәкалә язган иде Бакый ага хакында[3]. Мәкаләсе әйбәт булган иде.

Шулай ук Ерак Көнчыгышларда, Зеленодольскиларда йөрүе күз алдына килеп басты.

Димәк, Сез аны фанига кайтара алгансыз. Әле тагы зур эшләр башкарырсыз Сез, шуңа көч, кабилият, мәхәббәт сизелә үзегездә.

Чын күңелдән зур уңышлар телибез Сезгә, Эльмира.

Сәлам белән, Флора апагыз (Әхмәтова-Урманче). 1986. ■

[1] Әмир Мәхмүдовның «Татарстан яшьләре» газетасындагы «Иделдән Сөнгә кадәр» (1984, 19.07) дигән мәкаләсе.

[2] Нурихан Фәттахның «Казан утлары» журналында басылган «Татар шигърияте күгендә... » (1984, №10) исемле бәяләмәсе.

[3] Фаил Шәфигуллинның «Социалистик Татарстан» газетасында чыккан «Өзлексез әйләнеш» (1977, 23.02) дигән мәкаләсе күздә тотыла.

Безнең мирас №3 март 2019

Әфган дастаны

(бәяннан өзек)

Марат Закир

***

Дубинин окобын җиренә җиткереп казыды.

Ә яугиргә моның ише вак таш, ком, ак балчык бергә буталган тауда чокынудан да авыррак шөгыль юктыр. Бу урыс малаеның сын-сыйфаты да, җегәре дә бар. Ә менә ми дип аталган соры сыекчасы урынына тавык шулпасы салынган, ахрысы... «Вовка» дип әйтү җайлырак булса да, ротадагыларның һәммәсе аңа «Дубинин» дип эндәшә. Дубинин тек Дубинин. Фамилия кушаматка әйләнгән. Ә кушаматны аны тиктомалдан гына такмыйлар. Сап-сары чәчле, йомры гәүдәле Па-ша-ки-вя-чус, әнә, «салам кибәне»нә әйләнде. Вильнюс малае Янның үз гомерендә чын салам эскертен дә күргәне юктыр әле, баксаң. Мыгыр-мыгыр гәпләшеп утыручы ике дус – Әбелгаян белән Әсәннең дә кушаматлары бардыр. Юк икән, кушабыз аны!

– Әй, килегез әле монда!

Килделәр. Шомырт кара күзле, чем-кара чәчле, кәкре борынлы Габбазов та, керпе чәчле дәү башын кыңгыррак салып атлаучы Әбелгаян... Боларга ниндиерәк кушамат тагарга икән, ә?

– Панамаларыгыз кайда?

Яшь яугирләр җәлт кенә баш киемнәрен киеп куйдылар.

– Ни турында сөйләшәсез?

Җиргә чүмәшкән Әсән мылтык түтәсенә чиртеп алды:

– Кешенең Ватаны берәү генә була. Шул турыда сөйләшәбез. – Болай да кырыс күренгән чечен егетенең бу сүзләрне әйткәндә чырае тагы да җитдиләнебрәк китте.

– Ә нәрсә, синең ике Ватаның бармы әллә? – Солтан тарафыннан исә бу сүзләр сүз юктан гына әйтелде.

– Тарихи сәбәпләр аркасында икегә әйләнгән...

Ахыры. Башы журналның 2 нче (2019) санында.

– Син дә тарихчымы әллә?

– Өлешчә.

– Кайсы «мәгарәдә» укыдың?

– Алма-Ата университетында. Бер курс.

– Алайса, сез икегез дә «профессорлар» икән. – Солтан көлеп куйды. – Ә менә мин аны укымасам да беләм! Дөрес, Ватан берәү генә була. Ул – СыСыСыР!

– Безнең Ватаныбыз Татарстан булырга тиеш! – Ике куллап автоматына ябышкан Әбелгаян да бу гәпкә үз сүзен кыстырырга ашыкты. – Чөнки без – татарлар!

– Кем-кем, ә менә син – Ульян мишәре – миңа акыл өйрәткән буласың тагы! – Бу акыллы башларга аның кинәт ачуы килде. – Әле мин Казаннан була торып та... Барыгыз үз урыннарыгызга – марш! Ә син, Әбел, кал. Утыр әле бирегәрәк...

Солтан, бронежилет кесәсеннән теге серле хәрефләр белән чуарланган куен дәфтәрен алып, Әбелгаянга сузды:

– Мә, икенче юлы югалтма – җыебрак йөр! И аң бул – моның ишене монда башы ике булган кеше дә үзе белән йөртми...

Әбелгаян, авыз ачып сүз әйтмичә, дәфтәрен куен кесәсенә яшерде. Әйтәм аны... Таң алдыннан купкан тентү вакытында дәфтәрнең табылмавына сәерсенгән иде шул ул. Баксаң, хикмәте булган икән ләбаса. Бу дәфтәр аркасында күпме кара тавыш чыгардылар! Әгәр белгән булса... Кем уйлаган ди аны... Теге штаб күсесенә ни язганын да сөйләп карады, югыйсә. Ышанмадылар. Дәфтәрне табып бир, имеш. Яугирнең шәхси милке булырга тиеш түгелме икәнни?! Тап та тап... Сержант Солтан Рәхимов белән ни хакында сөйләштегез, имеш...

– Нигә кешечәрәк язмадың соң аны?

– Ә?

– Дәфтәреңә, дим, дошман хәрефләре белән язып тутыргансың бит.

– Иске татар язуы ла ул. Элек бездә шулай язганнар...

– Элек-элек... Ни яздың соң анда?

– Шигырьләр...

– Ну-ка, ну-ка, укып җибәр әле берәрсен!

> – Көмеш айлы биек манара,
> Килә моңлы азан тавышы.
> Пәрәнҗәсен ябына агачлар,
> Дога кыла ялгыз тау кошы.
> Ак еландай сукмак каршына
> Таш дуваллар калка тын калып.
> Комнар туза иркен далада –
> Җил актара Шәрык китабын.
> Кыныдагы кылыч шикелле
> Тау үзәне тыныч йокыда...

Әмма шулчак, Әбелгаянның шигырь укуын кырт кисеп, кайдандыр (әмма бик якыннан), күкне ярып, дәһшәтле сызгыру тавышы үтеп китте. Бер тапкыр үтте, ике тапкыр, өч, дүрт... Колак пәрдәләрен теткәләп, бәгырьне айкап ташлый торган сызгыру! Бераздан исә еракта, бик еракта, сабын куыгы сүнгән сыман, тонык шартлау тавышлары ишетелде. Замана артиллериясе – гыйфрит-туплар әнә шулай Әфган җирен, Әфган кышлакларын «эшкәртә». Фашист мәлгуньнең кайчандыр иманын өшкергән «Катюша» әбинең үзеннән дә мең мәртәбәләр дәһшәтлерәк оныгы «Ураган» эше бу. Аның артыннан төбе-тамыры белән йолкынган йөзем куаклары, инҗир, тут, йә булмаса анар агачлары гына ятып кала. Ишелгән дуваллларның, балчык өйләрнең, мал-туарның,

мәчет манараларының һәм бичара адәми затларның теткәләнеп беткән кисәкләре генә... Кем-кем, ә менә Солтан бу Алла каргаган илдә күпне күрде инде.

Әбелгаян... Сызгырудан тәмам әсәренгән егет, ике колагын да томалап, әле һаман да җиргә иелгән иде.

– Әй, син, сәҗдәче! Укып бетер, әйдә!

–...Кояш-шаһның серле төбәге...
Дөньяның ла соң бу кай ягы?
Кайсы галәмнәргә юл алган
Мең өркәчле таулар кәрваны?

Әбелгаян, укудан туктап, күзен тауларга текәде.

– Бетте дәмени?

Гыйфрит-тупның ачы тавышы егетнең башын тәмам бутады, ахрысы – ул теләми генә баш какты. Моның ишегә генә тиз күнәсең монда, ни-че-го, син дә өйрәнерсең, якташ...

– Тукайныкы мәллә?

– Нәрсә?

– Укыган шигырең, дим?

– Юк.

– Ә кемнеке?

– Үзем яздым.

Солтан көлеп җибәрде. Әбелгаян да, ихтыярсыздан, аңа кушылды. Шушы малайны Тукай тиклем Тукай белән бута инде, йә! Китапка, бигрәк тә әкият укырга хирыслыгы булса да, Солтан шигърият белән мавыга торган кеше түгел. Каян белсен ди ул һәр шагыйрьнең ни язганын?! Ә татар сүзе барыбер шәп! Ерак җирдә – өйдән меңәр чакрым ара киткәч кенә, бәлки, шулай тоеладыр? Ни генә димә, үз телең үз телең шул инде!

Солтан өен, әнисен, сеңелкәшен, энесен күз алдына китерде. Мәрхүм әтисе дә хәтергә килде. Авыл, авыл... Исән-сау гына кайтсын – авылдан беркая да китмәс ул! Нәзерме – нәзер! Таш каланы җене сөйми. Һавасына тиклем сулышны кыса. Ул шырпы капларында ничек яшиләрдер?!. Кырмыска-халык...

Әбелгаян... Шәп кенә шигырьләр яза икән бит, шайтан. Ни калган аңа монда?! Шагыйрь булып, укуын укып кына йөрисе әүлия бит, югыйсә. Соң инде Солтан үзе дә... Кайтып, Шыя буендагы Кыңгырау чишмә суын эчәргә гомере буе хыяллана бит инде ул. Төбендәге алтын комнары тибеп-тибрәнеп торган үзе көмеш, үзе салкын чишмә суы!..

«Дөньяның ла соң бу кай ягы?» – диме?!. Кай ягы булсын – Алла каргаган ягы! «Шүрәле каргаган», дигән кебек инде. Каргалмаса, ун ел буе сугышып ятмас иде кана. Теге юлы, бер кышлакны «чистартканда» әсир төшкән әфган кешесе, капитан Таратутаның йөзенә бәреп:

– Илбасар, илбасар! – дип, очына-очына төкеренгән иде. Таратута да, Солтан да, шушы ук Әбелгаян да үз илен – СыСыСыРны саклыйлар ләбаса! Кеше иленә басып керепме? Юк, юк! Без кермәсәк, барыбер американнар кергән булыр иде. Ә СыСыСыРның көньяк чикләрен саклау – изге бурыч ул! Безнең илебез Татарстан булырга тиеш, имеш. Бар бит инде ул ил болай да. Ил эчендә илме? Ватан бер генә була, имеш. Нигә, икәү булсын. Аннан миңа ни зыян? – Бүген ул шулай фикер йөртте.

Бу каһәрләнгән илдән кайчан кайтылыр? Иртәгә, дип кырт кисәргә ашыкма, Солтан. Алла боерса, диген. Әмма иртәгәсен әйтмә! Алдан кычкырган күкенең башы тишелгән ди, әнә...

«Мең өркәчле таулар кәрваны» – шә-ә-әп! Шул мең өркәчле таулар арасында күпме йөреп тә алай ук уйлаганы юк иде. Укыган кеше – укыган кеше шул инде. Ә менә Солтан автомәктәптән ары китә алмады.

Бакчы, хәтта бу тау битләрендәге төксе чырайлы чокырларда да ниндидер арыган-

лык, нидәндер гарык булу бар. Йокысыз төннән интеккән картлачның төпкә утырган күзләремени! Әмма җитә шундый мәл – алар да очкынлана, алардан да еш кына, һай, бик еш, ут-ялкын бөркелә. Һәм бу күзләрдәге ялкын-ут, еракка оча торган «Стингер»га, граната яисә ДШК ядрәсенә әверелеп, шуравиларга агыла башлый.

***

...Якыннан гына кемдер үтеп китте.

Киемгә сеңгән тәмәке исе борынны ярып керде. Ян Әсәнне уята булса кирәк. Уникедән икегә тиклем сакта Әсән торырга тиеш. Аннары исә чират – Солтанның үзенә. Ай саен унсигез кап бушлай бирелә торган казна тәмәкесе – «Донские» исе бу. Ул үзе йоклый, ә үзе барыбер сизә – Ян Әсәнне уята.

Ян, аты-юлы белән сүгенә торгач, ниһаять, Габбазовны уята алды. Тегесе, кыштыр-мыштыр килеп, каядыр ташланган бронжилетын эзләп тапты. Аннары исә чәптерәп аккан тавыш ишетелде. Ул да булмады, нидер шалтырап куйды – корыч каска ташка килеп бәрелде, ахрысы.

Солтан уянган иде инде. Йокларсың монда, пычагым... Ул торып ук утырды. Бүген аның тауда соңгы мәртәбә кунуы түгелме соң?! Ә менә калган төннәрне туган җирдә үткәрергә язса иде, язса иде!

Төн. Кара төн... Әнә, күк гөмбәзенә җем-җем итеп торган йолдызлардан тукылган төн келәме эленгән. Әнә, яшәгән елларын авыр таҗ итеп күккә чөйгән анар агачы шәйләнә. Ә янәшәсендә – горур сынлы үренте. Оныгы булса кирәк. Кайчандыр Солтаннарның урам яктагы бакчаларында да шундый ук – әбиле-оныклы – ике алмагач үсә иде. Әмма берсен кыш салкыннары орды...

Ә-ә, әйе, мәрхүмә әбисенең тагы бер көйләп укый торган китабы да бар иде бит әле. Әлеге дә баягы, бормалы-бормалы хәрефләр иде анда. Баксаң, ул хәрефләр иске татар язуы булган икән...

«Зиндан чиккән җиде ел, михнәт чиккән җиде ел,
Таһир ярың килгәндә уян, Зөһрә солтаным.
Хәсрәтеңдә зар булган, тумышыңнан яр булган
Моңлы Таһир килгәндә уян, Зөһрә солтаным...»

Әбисе укыганнардан шулар истә калган. Нигә бу кешеләр бер-берләрен үтерә икән? Егерме яшенә җитеп тә, бу хакта уйлаганы юк иде аның... Йолдызларга таба юл салган фикер җебен ычкындырмаска теләп, үз соравына үзе җавап эзләп, ул күзләрен йомды. Нигә?

Моннан мең ел элек тә бу кара төн шундый ук булгандыр. Янә мең ел үтәр... Кайчандыр Таһир белән Зөһрә дә бу төн гөмбәзенә сокланып карап торганнардыр... Нигә бу кешеләр бер-берләрен үтерә икән? Нигә?

Ул төн болытлы иде. Авыл күгендә бу тау иленең төшенә дә кермәгән кибән-кибән болытлар йөзә шул... Ул чагында аның – Рәсимәнең иреннәреннән нигәдер тоз тәме килә иде. Шунысы хәтердә калган. Ә нигә тоз тәме? Елаган булган, күрәсең... Хатын-кыз затының төп эше бит инде ул – елау.

Инде, шәт, анар агачлары да йоклыйдыр. Соң, әнә бит, шаян-шук йолдызларга тиклем: «Йоклагыз, йокла», – дип күз кысалар... Ул сәгатенә карады. Тагы кырык минуттан Әсәнне алыштырасы булыр. Йокы, йокы... Йоклый алмас инде ул бүген. Кайткач, йоклар. Ике, өч, юк – биш тәүлек рәттән, Алла боерса... Туктале, тукта! Анар агачлары өчкә әверелде түгелме соң? Өч, валлаһидыр – өч!

Солтанның корылган автоматы сәер анарга төбәлде генә һәм арттан кинәт килеп ирешкән авырлык, «Әсән, сука, йоклаган», дигән уй белән кискен кул хәрәкәте бер чакка туры килде: сул кулы белән ул сыртына сикергән бәндәнең хәнҗәр тоткан кул

беләзегеннән эләктерсә, уң кулының имән бармагы да барыбер үз эшен эшләде – чакмага басты. Трассер көлтәсе күкне телеп узды.

Солтанның яшен тизлеге белән тибелгән аягы йомшак әйбергә эләкте. Йомшак әйбергә дигәне күннән тегелгән су савыты – турсык булды, ахрысы – аның колагына шапылдан ярылган күн, шыбырдап аккан су тавышы гына килеп сыланды.

– Нист уоррас-с.. Ажгун уах, шоурави![1]

Капма-каршы барган кискен хәрәкәтләр вакытында теш арасыннан сытылып, беркадәр ысылдабрак та чыккан өзек-өзек бу сүзләрнең иясе чал сакаллы, чалмалы карт мөҗәһит иде.

– Мөртәт, шоурави!

Әмма шулчак тирә-юньгә атыш, ачы итеп сүгенү тавышлары таралды. Карт мөҗәһитнең ысылдавы, комга сеңгән су кебек, әлеге шау-шуда бөтенләй йотылды.

...Икенче мизгелдә корычтай салкын бармаклар Солтанның бугазын эләктерде, өченче мизгелдә аларның күзләре очрашты. Ут-ялкын бөркелеп торган күзләрдән әсәренгән егет аяк астындагы җирнең каядыр убылуын сизми дә калды...

Үзләре артыннан таш, ком-тузан ташкынын ияртеп, Хак Тәгаләнең ике бәндәсе кыядан түбән тәгәрәде. Алар өстәл зурлыгыдай ташка килеп сыландылар. Солтан өстә иде. Картның умыртка баганасы шартлап сынды булса кирәк, чөнки әлеге шартлау бичараның бар гәүдәсен калтыратып кулларына, кулларыннан Солтанның бугазына ук таралды.

Җан биреп барган әфган картының җыерчыклар җәтмәсенә эләккән күзләреннән әйтеп-аңлатып бетерә алмаслык микъдарда нәфрәт бөркелә иде. Ә сөякчел бармаклар Солтанның бугазына шулкадәрле дә нык ябышкан иде ки, ул тимер келәшчәдәй кул чугын җан ачысы белән генә кубарып ташлый алды. Күтәрелеп, картның гәүдәсен түбәнгә тибәрим дигәндә генә, аның йөрәге жу-у итеп китте. Өстәл чамасындагы таш плитәнең упкын өстендә торуын абайлап та түгел. Юк-юк! Күзе күргәне башына барып ирешсә дә, ул бөтенләй бүтән нәрсәдән тораташка әйләнгән иде. Мәетнең җыерчыклар җәтмәсендәге күзеннән әсәренгән егетнең шул мәлдә үпкә күреге сүрелде, ә йөрәге «дөп-дөп» кагудан, әйтерсең лә тәмам тукталды. Мизгел... сәгать... биш сәгать, ай, юк-юк, гомерлек, мәңгелек халәт бу!

Бары тик баш очында ишетелгән сәер аваз гына аны бу халәтеннән, ниһаять, аралап алды:

– С-с-с-ч! С-с-с-ч...

Курмар! Бу илнең җирле халкы аны шулай атый – кур-мар! Елан! Буйлы-буйлы тау еланы – «бакыр елан»! Өстенә буаз корсаклы дөя чүмәштемени – аны йокы баса башлады. Һәм Солтан баш очында үрә катып чайкалган тау еланының тылсымлы ысылдавы астында изрәп йокыга да талды.

Ул төш күрде. Имеш, баскыч-баскыч булып киртләчләнгән биек тауга алыплар менеп килә икән дә, каш өстенә кулын куеп, капка төбендә көтү кайтканын көтеп утыручы әнкәсе әйтә икән: «Юк, улым, бу алыплар да, бу тау да безнеке түгел. Андый биек таулар безгә кая килсен, ди?! Безнең таулар – Нократка коя торган Шыябыз буенда гына... Соң инде, кышның-кышында үзең чаңгы сындырып кайта торган таулар – Ындыр тавы, Маш тавы... Алыплар, арып ялга туктагач, чабаталарын салып, юл тузанын кага торган булганнар. Безнең таулар әнә шул чабата тузаныннан хасил булганнар да инде...» – ди икән, имеш... ■

---

[1] Бәхетсез бул, нәселсез кал! (таҗикчадан).

БЕР ФОТО ТАРИХЫ

Җырлап китте Мәңгелеккә

Госман Гомәр

Һай, безнең буын яшьләре, яшьнәп яшәделәр!..

Язмамны ничегрәк башларга да аптыраган, валлаһи! Сәбәпчесе мәгълүм: әле генә бакыйлыйкка күчкән, дөньякүләм мәшһүр җырчыбыз Илһам (мин аңа һәрвакыт, мулла кушкан исеме белән, Илһаметдин, дип эндәштем, үзе шуңа бик тә куана иде) Шакиров – әйе, җыр-моң сәнгатендә бердәнбер якты йолдыз Илһам Шакиров!

Сүзем шагыйрь Разил Вәлиев 1995 елда төзеп бастырган «Илһам» дигән китаптагы бер фото тарихы, анда сурәтләнгән яшь иҗатчылар турында.

Фотосурәттәгеләрне тәртибе буенча сул яктан аңлатсам, дөресрәк булыр шикелле. Без фәкыйрегезне таныгансыздыр инде, чибәр чаклар бар иде анысы! Йә, җитеп торыр, алайса артык мактануга китәр...

Элеккеге Чүриле районын икегә бүлеп, Саба районын эреләндергәч, дүрт битле газета чыгару өчен, партия өлкә комитеты үземне Байлар Сабасына җибәрде. Бу хәбәрне ишеткәч, яшьлек дустым, консерватория студенты Фасил Әхмәтов (сулдан икенче), куанып: «Безнең районга барасың икән, мин – Лесхоз бистәсеннән бит. Анда сиңа язарлык әйберләр күп», – дип озатып калды. Соңыннан алар, академик Әбрар Кәримуллин белән икәүләп (мөхтәрәм галимебез вакытында иҗатыма югары бәя бирде, Аллаһның рәхмәтендә булсын!), мине «безнең якташ» дип йөрттеләр. Казанга ялга кайткач, 1957 елның 4 маенда «Бакыр бабай» бакчасында (аннары «Ленин бакчасы» дип йөртелде)

дуслар белән әлеге фотога төштек. Фотоаппарат Фасил дусныкы иде. Төшерүчебез – Фәтхерахман Әхмәдиев, үзе бу нөсхәгә эләкмәде, Фасил төшергәнендә бар.

Инде сузылып ук яткан шәхескә тукталабызмы? Азнакай районының Сукаеш авылы егете, шагыйрь, җыр текстлары остасы Мәгъсүм Латыйфуллин ул. Университет тәмамлагач, Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында әдәбият-сәнгать бүлеге мөдире булып эшләде. Йортсыз-куышсыз буйдак – иҗат кешесе буларак, фатирдан фатирга күченеп йөрде. Соңгы тапкыр аны Спартак урамындагы бер әбигә илтеп куйдым. Ә таланты бар иде. Г.Тукай маршын язган Заһидулла абзый Яруллин, гомумән, Яруллиннар турында язарга хыялланды. Калын-калын ике папка истәлекләр туплады. Әмма китап булып басылмады – тормыш авырлыклары аяк чалгандыр, дип уйлыйм. Шулай да юка гына «Курайчы малай» дигән басмасы дөнья күрде. Аннары композитор Рәис Сафиуллин белән бергәләп, күпләрнең күңеленә үтеп кергән «Бик сагындым, авылым» дигән җыр иҗат иттеләр. Менә ул җыр юллары:

Туган як, көн саен
Искә төшәсең.
Күңелемнән чыкмыйсың,
Төшкә керәсең.
Сагындым, сагындым,
Бик сагындым
Без үскән авылның
Айлы тын кичләрен,
Былбыллы бакчаның
Шомырт исләрен...

Шуның белән вәссәлам.

Гафу үтенәм, тәртип бераз бозыла. Илһам Шакировка урынны күбрәк калдырасым килә.

Бишенче шәхескә – Мирсәет Яруллинга күчәм. Аны «безнең гаилә композиторы» дип йөрттек. Ник дигәндә, җәмәгате Луиза ханым «Социалистик Татарстан» газетасының мин эшләгән хатлар бүлегендә хисапчы вазыйфасын башкарды. Эш сөючән, итагатьле, инсафлы хезмәткәр буларак истә калган. Мирсәет бер килүендә үзенең күптәнге борчуы турында бәян кылды.

– Госман дус, эшең күп, гел язасың, беләм. Мине игътибар белән тыңла әле, – дип, җайлап-майлап сүз башлады бу. – Газета-журналлар укыйм, радио тыңлыйм, һаман бер хатаны кабатлыйлар. Мамадышның Сон елгасын Актанышның Сөн елгасы белән бутыйлар. Архивта казындым, безнеке – Сон суы, Сөн түгел!..

Шушы урында бүлдердем дә үзен, әйдә, яз мәкалә шушы хакта, дидем. Атна, дигәндә, Мирсәет өстәлемә китереп тә салды язмасын. Газетабызның чираттагы санында «Сөн бар, Сон бар» дигән язма басылып чыкты. Дуслыгыбыз тагы да ныгый төште. Газетада күләмлерәк очеркым яисә фельетоным чыкса, беренче булып Мирсәет котлый. Җөмһүриятебезгә мөстәкыйльлек даулаган еллардагы хезмәтләремне игә алып, 1991 елда Татарстан Югары Совет рәисе М.Шәймиев үземә «Татарстан Совет Социалистик Республикасының (ул чакта шушы статуста идек) атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән исем бирү турында Указ чыгарды. Шуннан ни дисезме? Иртәнге газетаны укыган Мирсәет телефоннан шылтырата:

– Котлыйм үзеңне, Госман дускай, син – ТССРда бердәнбер атказанган, – ди. Чын дуслык менә шундый буладыр инде ул! Мирсәет үзе дә матур-матур җырлары белән безнең күңелләрдә саклана.

Инде хәзер Фәтхерахман Әхмәдиевкә күчик. Бусы – бөтенләй райондаш. Без аның белән Чистай каласында таныштык.

1950 ел. Үзем Чистай ат үрчетү мәктәбендә укып йөрим. Фәтхерахман Сәгать заводының мәдәният сараенда баянчы булып эшли икән. Бинийая талантлы баянчы, һәвәскәр композитор, җор телле дус.

Ә болай, Ф.Әхмәдиев үзешчән композитор дип йөртелсә дә, һичшиксез, талант иясе иде. Якташыбыз Роберт Әхмәтҗанов сүзләренә язылган «Кама буе – туган як» җыры Балык Бистәсен генә түгел, республикабыз гимны булырлык әсәр. Шул ук шагыйрь сүзләренә язылган «Солдатлар» җырын күп кенә белгечләр «марш» дип бәяләде. Зәки Нури сүзләренә иҗат ителгән «Чистай вальсы» туй мәҗлесләрендә, яшьләр кичәләрендә алыштыргысыз бәйрәм вальсы булды.

Чаманы югалтып җибәрдем, ахрысы. Илһаметдинемнең рухы рәнҗеп ятмасын тагын, кичерә күрсен!..

Иң әүвәл ошбу фотога килик – төшү мизгеленә. Күрәсез бит, берүзе кепкадан төште. Берәм-берәм нотация укыдык тегеңә:

– Илһам, сал картузыңны!

– Нигә?

– Килешми болай – сал!

– Сез салгач, җиткән, – ди бу.

– Бездән аерылып торасы киләдер инде?!

– Авыл малаена болай әйбәтрәк, – дип акланмакчы Илһамыбыз.

– Монда барыбыз да авыл малайлары, шәһәрнекеләр юк. Шәһәргә без хуҗа, – дип йомгаклады шактый шомарган М.Латыйфуллин. – Төшсен, әйдә!

Бу вакыйганы, дәвамы булганга искә алдым. Байлар Сабасында өч ел эшләп, 64 авылны кат-кат айкап чыккач, мине Кама ярындагы Красный Бор районына күчерделәр. Авылның исеме – Пьяный Бор, бурлаклар заманыннан калган. Сала уртасында зур таш чиркәү, ул мәдәният сарае ролен үти. Илһам Шакировның ерак авылга тәүге гастроле нәкъ менә Пьяный Борга туры килде. Кама буйлап «Агыйдел», «Вера Засулич» кебек пароходлар йөреп кенә тора, уңайлыгын искә алганнардыр инде.

Яшь җырчы, көчле тавыш, моң чишмәсе агыла да агыла. Менә Илһам Шакиров «Карурман»ны башкаргач, «Кама буе – туган як» җырына күчте. Кама буе, дип әйтүгә, зал аягүрә басты, Илһам белән бергә җырлады, аннары яшь пәһлеванны алкышларга күмде. Ул кечтә чиркәү диварлары чак-чактан җимерелмичә калды.

Төште Илһам минем янга.

– Йә, ничек? – ди.

– Шәп ярым! – дим.

– Менә кара, картузны салып ыргытканга шулай чыкты, – ди, кара көдрә чәчен сыйпап.

Архивымда Илһам Шакировның Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театрындагы тәүге концертыннан алынган фотосы да саклана. Мин аны, азрак шаяртып әйтсәм, «шәхси фотографым» Шамил (чын исеме Альберт) Баһаветдиновтан төшерттереп алдым. Заманында Шамилнең әнисе белән бер заводта эшләгән идек. Талантлы фотограф – Мәскәүгә китеп төпләнде.

Илһамыбыз, башкортлар, казакълар, үзбәкләр һәм башка милләтләр чакырса да, Казанын ташламады, туган халкына хезмәт итте. Шәһәр «боҗрасы»ндагы Г.Тукаебыз һәйкәле артындагы «Обкомчылар йорты»ндагы фатирында күп мәртәбәләр булырга туры килде, күрешеп, хәл-әхвәл сорашып яшәдек. Соңгы күрешүебез 2016 елның җәендә «Казан нуры» мәчетендә булган икән. Күңеле тартып китергәндер инде. Урыны оҗмахта булсын!..

22 гыйнвар, 2019 ел ■

Безнең мирас №3 март 2019

МИЛЛӘТЕБЕЗ ГОРУРЛЫГЫ

Зөлфәт Хәйруллин

Милләтебезнең горурлыгы, мактанычы, мохтаҗларга, ятимнәргә, авыр хәлдә калган меңнәрчә кешеләргә матди ярдәм оештырып, гасырыбызның шәфкать символына әверелгән Әсгать Галимҗанов белән мин һич уйламаганда танышып һәм дуслашып киттем. Төрле дәрәҗәдәге түрәләрнең, хөкүмәт җитәкчеләренең, журналистларның, гади халыкның аны ничек хөрмәт итүен үз күзләрем белән күрдем. Әйе, чыннан да, ул кешеләрне бик яратты, шаян-шук, бик ярдәмчел кеше иде.

Әсгать Галимҗанов Казакъстаннан күчеп кайткан, яшәргә үз фатирына сыендырган Габдулла һәм Наилә Һадиевлар белән. Артта – Зөлфәт Хәйруллин. 2008 ел

Әсгать абый Апас районының Болын-Балыкчы авылында туа. Армиягә киткәнче колхозда төрле эшләрдә эшләп йөри. Тәтеш районының Тархан авылы янында Идел елгасын киңәйтүдә катнаша. Шунда эш белән Буа районына бара. Шул районлагы Чәчкап авылына кунакка Роза исемле кыз кайта. Әсгать, аның белән танышып, сөйләшеп йөри башлый. Армиядә өч ел диңгезче булып хезмәт итеп кайтканнан соң, Казанга килеп, Ленин районы (хәзер Мәскәү районы) милициясенә эшкә урнаша. Роза белән аралары якынаеп, гаилә корып җибәрәләр. Роза әнисе белән Ухтомский урамындагы ике катлы агач баракта яши. Фатирлары өч бүлмәле була. Каравай поселогында арзанлы гына бер йорт карарга ниятләп йөргәндә, Роза аны үзләренә яшәргә чакыра һәм ул шунда яшәргә кала. Әсгать абый, өч ел милициядә эшләгәннән соң, Вахитов исемендәге химия

комбинатына шофер булып урнаша. Әле, өстәвенә, колхоз базарында каравылчы булып та эшләп йөри (йортлары шуның янында гына була). Ә анда бик күп бозылган яшелчә, җиләк-җимеш кала, әрәм бит, исраф. Кая куярга байлыкны, дип уйлап йөргәннән соң, ул Таҗи Гыйззәт урамындагы бер йортта баз казып, шунда дуңгызлар асрый башлый. Башта берничә баш, аннан биш, ун, унбиш... Өстәвенә, базарда карбыз саклый – янчелгән, изелгәннәре һәм читтән алып кайтканда машинага төшәлгән салам да аңа кала. Барысын да турап, дуңгызларга ашата. Химкомбинатта унбиш ел эшләгәннән соң, Әсгать абый Чернышевский урамындагы 110 нчы кибеткә йөкче булып урнаша. Ат алып җибәрә.

Дуңгызлар үсә, ишәя. Аларны Казан вертолет заводыннан килеп алалар. 150-200әр сум акча керә. Идәндә таз тора, акчаны шунда салып баралар. Әсгатьнең исә акчада гаме юк, эшли, чаба. Хатыны белән әбисе дә акчаны белеп кенә тоталар. Бервакыт әбисе аны үз янына чакырып ала да: «Әсгать, җаным, минем мондый хәл күргәнем юк, акча тазда тора, идәндә, без аны тибеп йөрибез. Син һаман чабасың, болай булмый бит, мин курка башладым», – ди. «Әйдә, әби, ул акчаны балалар йортына бирик!» – ди Әсгать абый, моңа җавап итеп. Әби, күңеле тулып, елап җибәрә, чөнки ул үзе дә балалар йортында үскән кеше була, шатланып, риза була. Икенче көнне 5000 сум акчаны тотып, Әсгать абый сәламәтлек саклау министры урынбасарына бара. «Син кайдан аласың бу акчаны?» – дип кызыксыналар аннан. «Минем яшерен эшем юк, ничек бар, шулай сөйләп бирдем», – ди Әсгать абый. Шуннан китә инде... Межлаук урамында чүп өелеп ята торган җир була, вакытлыча файдаланырга, дип, Әсгать абый әлеге җирне үз исеменә рәсмиләштерә һәм ферма салып, бөтен гаиләсе һәм бертуган энесе Тәлгать белән шунда нәселле үгезләр асрый башлый. 200әр баш үгез! Ул вакытта цирк, Кремль тирәләрендә үлән бик күп үсә торган була, шуннан чабып, атка төяп алып кайта. Базардагы яшелчә, җиләк-җимеш калдыкларын да алып кайтып сыйлый үгезләрне ул. Аннан 70-80шәр баш үгезне ит комбинатына тапшыра. Акча күп керә һәм баеган саен юмартлана бара Әсгать абый. Балалар йортлары, сырхауханәләр, Чечня, Чернобыль, Әрмәнстандагы җир тетрәүләр... Барысын да санап бетерерлек түгел. Аннан аны, хәйрияче, дип, Мәскәүгә чакыра башлыйлар, Ленин исемендәге Совет балалар фондының шәрәфле әгъзасы итеп сайлыйлар. Аны президиумга, беренче рәткә – С.Михалков, Ш.Амонашвили, Ю.Власов, Р.Паулс, Е.Чазов, Р.Горбачева, С.Образцов, танылган космонавтлар Попов, В.Терешкова кебек атаклы кешеләр янына утырталар. Төрле илләрдән килгән дәрәҗәле вәкилләргә Фондның ул вакыттагы җитәкчесе Альберт Лиханов: «Россиядә Балалар фондын иң беренче булып Әсгать Галимҗанов оештырды», – ди. Аны инде урамда да таный башлыйлар. Ул Мәскәүдәге төрле җыелышларга Россия балалар фондының Татарстан бүлеге җитәкчесе Роберт Миңнуллин белән бара башлый.

Әсгать абый шуннан соң 200ләп чебеш сатып ала. Райком башлыгы: «200 әтәч, 20 сембернар асрый, мине табутка кертә бу кеше», – дип, газетада да язып чыга. Аны барыбер обкомдагылар да, райкомдагылар да яраталар, хөрмәт итәләр. Белеп-күреп торалар ич инде: үзе өчен тырышмый, тапкан малын барысын да диярлек ятимнәргә, инвалидларга, бәлагә таручыларга биреп бара. Әсгать абый, сөте балаларга булыр, дип, Әлмәттәге нәселле сыерлар берләшмәсеннән Айшир токымлы сыерлар алып кайтып асрый башлый. Боларга алты атны да кушсаң... Кошларны да онытмый: күгәрченнәр белән каргаларга ярма, ак ипи ашата. Алар, тәрәзә ачык булса, туп-туры өенә килеп керәләр, үзенә дип аш салып куелган тәлинкәләрне дә ватып бетерәләр. Әсгать абыйда мохтаҗ җан ияләрен кызгану хисе көчле була. Ә үзенең, күпме мал асрап, гомер буена тавык та суйганы булмый, ничек инде аларга кул күтәрәсең, ди...

Ятимнәргә, авыруларга ярдәм итәргә кирәк, дигән нәрсәне кечкенәдән күреп, ба-

Әсгать Галимҗанов (унда) һәм Зөлфәт Хәйруллин. 2009 ел

шына сеңдереп үскән була ул. Аның әти-әнисе бик гадел кешеләр була. Әтисе, сугыш башлангач, авылдаш хатын-кызларны окоп казырга йөртә. Бала табарга вакытлары җиткән хатыннарны 40 градус салкында, кызганып, яшереп кенә өйләренә алып кайта торган була. Аннан әтисен сугышка алалар һәм ул аннан ике аяксыз кайта. Әтисе аягым юк, дип тик утырмый: Зөя елгасына балык тотарга йөри һәм зур балыкларны күп балалы, тол хатыннарга бирә. Өстәвенә, кемгә чалгы кайрый, кемгә тавык суеп бирә – хәленнән килгәннең барын да эшли. Әти сугыш михнәтләрен күргән, сугыш мәхшәрен күрүчеләргә бик авыр, дип, Әсгать абый Көньяк Осетиягә 10 мең сум акча сала. Ятим, авыру балаларга ярдәм итә башлавын әйткәч, әтисе бик сөенә.

Әнисе дә бик игелекле кеше була. Улының хәйриячелек белән шөгыльләнүен ул да бик хуплый: «Дөрес эшләгәнсең, улым, зур уку йортларында укымасагыз да, кешеләргә яхшылык эшләвегез укыганнан артык булыр», – ди. Әнисе балаларына һаман: «Үзегездән авыррак яшәүчеләргә ярдәм итегез, сез ашап утырганда өегезгә кеше килеп керсә, табынга чакырыгыз, аерым ашамагыз, барын бүлешегез, нәселне хурламагыз», – дип әйтә торган була.

«Бай, бәхетле яшим, дисәң, эшләргә кирәк. Без бик бай илдә яшибез бит. Авыл саен бер-ике күл бар. Шунда балык үрчетергә яки каз-үрдәк җибәрергә була. Һәр авылда 200әр баш ат асрарга кирәк. Авыл кырыйларындагы үләнне чабып бетерә торган түгел! Бай яшәргә омтылырга кирәк. Әни миңа гел: «Күршең бай булса, әйбәт, улым, байлардан көнләшмә, мул яшәү өчен үзең дә тырыш», – ди торган иде. Бездә атлаган саен акча ята. Мин, колхоз базарында аунап яткан агач яшнекләрне төзәтеп, сәүдәгәрләрнең үзләренә сата идем. Хәзерге исрафны уйлыйм да, башым авырта башлый. Хөкүмәттән хезмәт хакы көтеп ятарлыкмы инде?! Аннан кайбер ирләр, хатынны яратам, дип, аны үбеп-иркәләп, аракыга, тәмәкегә акча сорыйлар. Килешә торган эшме шул?! Үзең эшлә син, үзең өйгә акчаны өеп алып кайт, вәт шунда хатының яратыр. Мине хатыным: «Әсгать, җаным, бераз ял ит инде», – дип, эшләгәндә маңгаемнан килеп үбә иде. Без

Әсгать Галимҗановка 65 яшь тулуны билгеләп үткәндә. Милли мәдәни үзәк, 2001 ел

аның белән бер малай, бер кыз үстердек. Бик акыллы, гадел, курчак кебек матур иде хатыным. Кызганыч, ул, авырып, үлеп китте. Әби дә юк инде, энем Тәлгать вафат, улыбыз да йөрәк белән китеп барды... Алар белән гөрләтеп эшләп йөргән чакларны сагынганда гармун сыздырып җибәрәм. Якыннарымның кабер ташларына: «Ятимнәргә, мохтаҗларга ярдәм итүчеләр», – дип яздырдым. Татарстан урамында ике бүлмәле фатирым булса да, базар янындагы шушы баракта яшим», – дип сөйләгән иде ул. Элеккеге ферма урынына базарга яшелчә китерүче машиналар өчен стоянка оештыра Әсгать абый. Кыш көне анда чүп-чар ташучы машиналар тора, машина йөртүчеләр өчен мунчасы да була. Торыр җире булмаган сәүдәгәрләрне фатирында да тота ул. Шулардан кергән акчаны мохтаҗларга биреп бара. «Кыскасы, гел файда китерү турында уйларга кирәк, хөкүмәткә генә ышанып ятарга ярамый. Эшләсәң, үзеңә дә, мохтаҗларга да әйбәт, җитәкчеләр дә ярата. Президентларыбыз да ярата мине, олылый, рәхмәт! Миңа алтын сәгать бүләк иттеләр. Мәскәүдә бик күп бриллиантлар белән бизәлгән медаль белән бүләкләделәр, Хезмәт Кызыл Байрагы орденым бар. Мактау кәгазьләренең исәбе-чуты юк. Мохтаҗларга өлеш чыгармасам, кыен була башлый, тамагымнан ризык үтми. Ә ярдәм иткәч, иркенәеп китәм, рәхәт була. Ярдәмемнең исәбен белмим инде, ул миллионнар белән исәпләнә, мәктәпләргә, интернат-йортларга 70ләп «Газель» генә бирдем. Туган авылыма таш һәм агач йортлар салдым, мәчеткә акча, келәм бирдем. Хәзер тагын бер хыялым бар әле: Минтимер Шәриповичка һәйкәл салдырасым килә. Алтын утлары белән еpактан балкып торсын! Кибет киштәләре тулы ризык, республикабызда тынычлык – республикабыз җитәкчесенең зирәк сәясәте, тырышлыгы бит бу. «Минем Сезгә һәйкәл куясым килә», – дигән идем, ул беренче булып өлгерде, минем үземә һәйкәл куйдырды, рәхмәт аңа!» – дигән иде ул, үзен шулкадәр зурлауга кыенсынып та, сөенеп тә.

Әйе, Әсгать абый Галимҗанов дөнья бәһасе кеше иде. Аның кылган гамәлләре турында кайта-кайта уйланырбыз әле, киләчәк буын да шундый ук хисләр кичерер. Ул – милләтебезнең йөз аклыгы, горурлыгы иде шул һәм шулай булып кала да. ■

Истә, һаман да истә!

Язучы Миргалим Харисовның тууына 80 ел

Язучы, тәрҗемәче һәм журналист-мөхәррир Миргалим Харис улы Харисов 1939 елның 16 мартында Актаныш районының Чат авылында крәстиян гаиләсендә туа.

1952-1956 елларда Минзәлә педагогия училищесында укый.

1956-1961 елларда исә М.Харисов Мәскәүдә М.Щепкин исемендәге югары театр училищесының татар студиясендә (Т.Миңнуллин, Н.Ихсанова, Р.Шәрәфиев, Р.Таҗетдинов, Н.Дунаев, Г.Исәнгулова һәм башкалар белән бергә) белем ала, тәрҗемә өлкәсендәге тәүге адымнарын да шунда ясый: А.Чеховның «Туй», Т.Миңнуллин белән берлектә В.Маяковскийның «Мунча» пьесаларын тәрҗемә итә. Театрда уйнаган рольләре: Сәхи – «Көзге җилләр» (А.Гыйләҗев), Дус – «Рәхим итегез!» (Х.Вахит), Альберт – «Без аерылышмабыз» (Ш.Шаһгали) һ.б.

Яшүсмерләргә багышланган «Тәзкирә» повесте (1966), «Кызыл планетага сәяхәт» исемле фантастик әсәре (1967), «Сабыйлар хакына» дигән пьесалар җыентыгы (1969) һәм «Ватан нидән башлана?» дигән хикәяләр җыентыгыннан тыш, грузин язучысы Н.Думбадзеның «Мин кояшны күрәм» (1968) әсәрен, театрлар өчен В.Розов, А.Арбузов һәм башка драматургларның сәхнә әсәрләрен тәрҗемә итә.

1988 елда М.Харисовка «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелә.

М.Харисов – 1989 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы.

2009 елның 15 сентябрендә Казанда вафат була, Актаныш районының Чат авылы зиратында җирләнә.

Шагыйрь Ринат Рәхимовның тууына 80 ел

Шагыйрь Ринат Рәхим улы Рәхимов 1939 елның 17 мартында хәзерге Татарстан Республикасының Арча районындагы Урта Сәрдә авылында туа.

1956 елда Биектау районындагы Мүлмә урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, бер ел туган авылында гади колхозчы һәм ындыр табагы бригадиры булып эшли. 1957-1962 елларда Казан авыл хуҗалыгы институтының агрономия факультетында укый, аны тәмамлагач, Питрәч районының Ильич исемендәге колхозында башта агроном, аннары колхоз рәисе булып (1965-1973 елларда) эшли.

Беренче мөстәкыйль китабы – «Тормыш атомнары» исемле шигырьләр җыентыгы – 1964 елда дөнья күрә. Аннан соң «Сабан тургае», «Туган җирем» һәм русча тәрҗемәдә «Тепло земли» исемле шигырь китаплары басылып чыга. Шагыйрь иҗаты турында үз вакытында «Казан утлары» журналында Сибгат Хәкимнең «Җир шагыйре» дигән язмасы дөнья күрде (№9, 1971).

Р.Рәхимов – 1972 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы.

Ул 1984 елның 16 августында вафат була.

Тарихчы галим Сәләм Алишевның тууына 90 ел

Тарихчы галим, тарих фәннәре докторы (1989), Татарстанның атказанган фән эшлеклесе Сәләм Хатыйп улы Алишев 1929 елның 20 мартында ТАССРның Чистай кантоны (Татарстанның хәзерге Аксубай районы) Шәрбән авылында туа. Хәзерге Нурлат районына кергән Яңа Әлмәт авылында үсә.

1951 елда Казан педагогия институтын тәмамлагач, тарих фәннәре буенча кандидатлык (1968) һәм докторлык (1990) диссертацияләрен яклый.

Басылып чыккан китаплары: «Урта Идел буе татарлары Пугачев явында» (1973), «Каһарман бабайлар» (1976), «Үткәннәр эзеннән» (1986), «Урта Идел буе халыкларының тарихи язмышы. XVI г.-XX г. башы» (1990), «Казан һәм Мәскәү: XV-XVI гасырларда дәүләтара бәйләнешләр» (1995), «Азатлык өчен газаплы юл» (1999), «Тарихчылар. Татар халкы» (2000), «Борынгы төрки дөнья» (2001), «Башкорт феномены» (2002), «Казан ханлыгы чоры: татарча чыганаклар» (2002), «Казан ханлыгы тарихыннан» (2003), «Татар тарихчылары» (2006) һ.б.

С.Алишевның биографиясеннән бер кызыклы факт: галимнең «Урта Иделне Рус дәүләтенә кушу» темасына язылган беренче докторлык диссертациясен (1978) Мәскәүдә Тарих институтында үткәрмиләр. Ул 1990 елда «Урта Идел буе халыкларының тарихи язмышы. XVI г.-XX г. башы» темасына икенче диссертация әзерләп, шуны якларга мәҗбүр була.

С.Алишев 2015 елның 23 июнендә Казанда вафат була.

Рәссам Рәшит Имашевның тууына 80 ел

Күренекле рәссам, нәкышче, график, ТАССРның (1986) һәм Башкортстан Республикасының (1998) атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан Республикасының халык рәссамы (2003), Ф.Кәрим (1996) һәм Акмулла исемендәге (2006) премияләр иясе Рәшит Фатыйх улы Имашев 1939 елның 31 мартында Башкортстан АССРның Бишбүләк районы (кайбер чыганакларда – Миякә) Азнай авылында дөньяга килә.

1963 елда – Казан сынлы сәнгать училищесын, 1970 елда исә В.И.Суриков исемендәге Мәскәү дәүләт сынлы сәнгать институтын тәмамлый.

1970-1971 елларда Уфада яшәп ала, 1971 елдан янә Казанда.

1972-1974 елларда Казан сынлы сәнгать училищесында укыта.

1974 елдан – СССР Рәссамнар берлеге әгъзасы.

Р.Имашев ясаган портретларның кайберләре:: «Студент кыз» (1971), «Хәсән Туфан» (1976), «Сибгат Хәким» (1979), «Муса Җәлил» (1980), «Салих Сәйдәшев» (1983), «Рөстәм Кутуй» (1991), «Рудольф Нуриев» (1995), «Марсель Сәлимҗанов» (2001), «Акмулла» (2005) һ.б.

Р.Имашев 2007 елның 11 мартында Казанда вафат була.

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Безнең мирас №3 март 2019

БОРЫНГЫ ТАТАР МИЛЛИ МУЗЫКА УЕН КОРАЛЛАРЫ

Сорнай

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2019) санында.

СОРНАЙ

Музыка белгечләре фикеренчә, тынлы уен кораллары төркиләрдән таралган. Күренгәнчә, «сорнай» («сернай», «сырнай», «сурнай») сүзенең нигезендә үк төркилек ята.

Күренекле галим Шиһабетдин Мәрҗани «сор-» сүзен «мөгез» дип тәрҗемә итә; «-най» өлеше «камыш», «көпшә» дигәнне аңлата.

Коръәндә дә «сур» сүзе уен коралы буларак язылган. Кыямәт алдыннан Исрафил фәрештә сурга, ягъни мөгезгә өрер, диелгән анда.

Галим Герхард Миллер үзенең «Казан губернасында яшәүче мәҗүси халыклар: марилар, чуашлар, удмуртлар» исемле хезмәтендә «татар сорнае» яки «куш сорнай» дип волынкага охшаган уен коралын атый. Шундый ук уен коралы мариларда «шыбыр» дип атала, ди.

Күренекле казакъ галиме Чокан Вәлиханов 1864 елда Омск тирәләрендә яшәүче төрки халыкларның «муиз сырнайда» уйнаулары турында яза: «Алар аны еракка хәбәр бирү өчен файдалана», – ди.

«Сорнай» сүзе татарлар яшәгән күп төбәкләрдә очрый. Кайчакта ул үзгә төрле уен коралларына карата да кулланыла. Мәсәлән, Курган якларында: «Сыздыр, әйдә, сырнаеңны», – дип, гармунга әйтәләр. Шулай ук тугандаш казакъ халкы да гармунны «сырнай» дип атый. Җөмләдән, Татарстанның Балтач районында «сорнай» дигән басу бар. Шул җирләр кергән күмәк хуҗалык та «Сурнай» исемен йөртә. Күргәнебезчә, бу сүз татар өчен һич кенә дә чит түгел.

Без беренче тапкыр сәхнәдән сорнайда уйнап күрсәткәч: «Бу бит урысларның жалейкасына охшаган», – диделәр. Мин бу хакта тирәнгәрәк төшеп уйларга киңәш итәр идем. Беренчедән, урыс гаскәре IX-X йөзләрдә Россиянең хәзерге Новгород, Псков җирләрендә күренә башлаганчы ук сорнай һәм аңа охшаш уен кораллары төрки дөньяда булган. Бу – билгеле факт. Икенчедән, сорнайга яисә жалейкага охшаган уен коралы, Россиядән кала, бер генә славян илендә дә юк, элек тә булмаган.

КАМЫЛ СОРНАЙ

Сорнайның хәзерге көнгә кадәр сакланып калган иң гади варианты – камыл сорнай. Кайбер төбәкләрдә аны «камыл курай» дип тә йөртәләр.

Камыл сорнайны ясау өчен диаметры якынча 3-4 мм булган 180-200 мм озынлыктагы арыш саламы кисеп алына. Саламның бер башы буынтыклы булса яхшы. Буынтыгы булмаса, сагыз белән томалап куярга мөмкин. Ябык башыннан үткен пәке яки лезвие белән телеп, 3-5 мм киңлектәге, 20-25 мм озынлыктагы тавыш ярысы (тел) ясыйбыз. Саламның икенче башыннан, һәр тишем саен бер бармак киңлеге ара калдырып, 5-6 тишем тишәбез. Башта аларны кечерәк тишәргә кирәк. Тавыш югарылыгы килеп җитмәсә, аска яки өскә таба зурайтып көйләргә мөмкин. Тишемнәр оваль формасында якынча 2х4 мм булырга тиеш. Саламның тел ясалган 25 мм өлешен авызга кабабыз һәм, иреннәр белән каплап, уртача көчәнештә өрәбез. Уйнаганда дөрес итеп өрүгә игътибар итегез. Чөнки өрү көченә карап, тавыш югарылыгы үзгәрә. Лады – пентатоника. Диапазоны – октава.

Камыл сорнайны тишемнәрсез, кыскарак ясап, төрле табигать тавышлары чыгарып, бала елаганын һәм башка күренешләрне тасвирлап була.

Безнең бабалар шулай ук елга, күл камышыннан да «камыш сорнай» ясап уйнаган. Аның өчен елга камышыннан 250 мм озынлыктагы көпшә кисеп алына. Үткен пәке белән аңа алты тишем тишелә. Камышның буынтыклы башыннан 30 мм аралыкта

«Сорнай» ансамбле

тел ясыйбыз һәм аның өске ягын электр наждагы яки надфиль ярдәмендә юкартып, тавыш ярысын көйлибез.

Камыш сорнай бик чыдам. Бер ясаган уен коралы ике-өч елга җитә.

ТАТАР СОРНАЕ

1974 елгы гастрольләрдә мин Әгерҗе районының Салагыш авылында яшәп, үзе сорнай ясап анда уйнаучы бер абый белән таныштым. Исеме хәтердән җуелган. Ләкин ул бүләк иткән сорнай миндә бүген дә саклана. Татар авылында шундый көчле, матур тавышлы уен коралын табуыма чиксез шат идем. (Озакламый сорнай турында

Таһир ясаган сорнай

бик күп кызыклы мәгълүмат тупладым. Ул елларда миңа күренекле галим Рәгъде Халитов бик булышты.) Әлеге сорнайның тавыш чыгару җайланмасы да, тавыш ярысы да, алты тишем тишелгән көпшә өлеше дә агачтан ясалган. Көпшәнең икенче башына мөгез киертеп куелган. Агач көпшәнең үзәге һәм тишемнәре кызган тимерчыбык белән яндырып тишелгән.

Рәгъде Халитов «Татарские народные духовые инструменты» дигән хезмәтендә «сорнай», дип, кәүсәсе якынча 200 мм озынлыктагы, 10-12 мм диаметрлы кипкән үсемлек көпшәсеннән ясалган, аңа 5-6 тишем тишелгән уен коралын атый. Әлеге көпшәнең бер башына – салам, камыш, яисә каз каурыеннан эшләнгән тавыш ярысы, ә икенче башына, кайбер очракларда, мөгез беркетелгән.

Соңгы елларда сорнай бик нык камилләште. Тавышының көче дә, тембры да, тышкы кыяфәте дә яхшы якка үзгәрде. Оста башкаручы сорнайда озын көйләрне – моңлы, тиз көйләрне дәртле итеп уйный ала.

Бүгенге таләпләргә туры килгән сорнайны ясау һәм аны билгеле бер тавыш югарылыгына көйләү өчен зур осталык кирәк. Ясарга керешкәнче, нинди дә булса бер сорнайны алып, аның уңай һәм җитешмәгән якларын өйрәнсәң яхшы. Хәзер бу эш өчен бөтен мөмкинлекләр бар. Яхшы, сыйфатлы сорнайны Казанда бүген Таһир Вәлиуллин ясый.

Сорнай өч өлештән тора. Сыбызгы өлеше (мундштук), җиде тишемле көпшә һәм, уен коралының тавышын тагын да көчәйтү өчен, мөгез өлеше. Түбәндәге үлчәмнәр «ре мажор» тональлегенә көйләп эшләнгән сорнай буенча бирелә. Сыбызгы өлеше дә, көпшә өлеше дә эбониттан ясала. Тавыш тәрәзәсе өстенә пластик материалдан яры (тел) беркетелә. Аның бер башы лезвие белән юкартыла, юкартылмаган башы 6-7 мм диаметрлы һәм 4-5 мм киңлектәге резина балдак ярдәмендә тыгыз итеп сыбызгы кәүсәсенә беркетеп куела. Тавыш югарылыгы килешеп җитмәсә, резина балдакны күчереп көйләргә була.

Көпшә өлешенең озынлыгы – 230 мм, эчке диаметры – 0,8 мм. Аның бер башы – тавыш сыбызгысына, икенче башы яхшылап эшкәртелгән мөгезгә тоташкан.

Сорнайның диапазоны – бер октава. Диатоник (мажор) лад аралыгына көйләнә.

Ринат Гыйләҗев,
«Сорнай» фольклор ансамбленең сәнгать җитәкчесе

Дәвамы бар ■

Иңнәргә канат куйган еллар...

Моннан нәкъ илле ел элек Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе тарихында, бигрәк тә эстрада өлкәсендә, заманасына күрә бик мөһим вакыйга була: оешма җитәкчелеге бер төркем артистларны Мәскәүгә – Бөтенроссия эстрада сәнгате иҗат остаханәсенә укырга җибәрә. Филармониянең сәнгать җитәкчесе Мәхмүт Нигъмәтҗанов аларны Мәскәүдә укыту өчен бөтен тырышлыгын куя, татар эстрадасын яңа исемнәр белән баета. Студиядә белем алган һәм аны уңышлы тәмамлаган яшьләр яңа репертуар, заманча алымнар, алар өчен махсус тегелгән заманча сәхнә киемнәре белән кайтып, эстрада бүлегендә уңышлы эшли башлыйлар.

Өстәмә белем бирүче әлеге оешма 1961 елда артистларның профессиональ осталыкларын камилләштерү, яңа концерт программалары, номерлары әзерләү җәһәтеннән Мәскәүдәге «Яшел театр» бинасында оештырыла. Иҗат остаханәсен озак еллар буе цирк һәм эстрада сәнгате остасы, режиссер Л.С.Маслюков җитәкли. Шулай ук бирегә укыту өчен Г.П.Виноградов, И.П.Яунзем, Н.П.Смирнов-Сокольский, Л.О.Утесов, К.И.Шульженко, Л.А.Русланова кебек сәхнә осталары, режиссерлар җәлеп ителә.

Бирердә ике ел уку чорында эстрада сәнгатенең барлык жанрлары колачланып, нәфис сүз, вокал, вокал-инструменталь, хореография, оригиналь жанр юнәлешендә кадрлар әзерләнгән. Остаханә, артистларның кайсы бүлектә укуына карап, алар өчен әдәби һәм музыкаль әсәрләр, сәхнә костюмы, реквизит, декорация, бутафория, музыка уен кораллары җитештергән, шул рәвешле эстрада сәнгате традицияләре буенча да теоретик мәгълүмат биргән.

Туксанынчы елларның башына кадәр артистлар бирегә дәүләт концерт оешмаларында уздырылган конкурс нәтиҗәләре нигезендә кабул ителгән.

Ошбу уку үзәгенә укырга җибәрү өчен, Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә дә 1969 елда зур конкурс үткәрелә. Жюри рәисе булып Мәскәүдән Леонид Семенович Маслюков үзе килә. Бәйгедә 400гә якын кеше катнашып, арадан бары тик 14е генә укуга сайлап алына.

1969 елның 18 февралендә филармония директоры Михаил Юрьевич Первин имзалаган 27 нче фәрманга күз салыйк: *«24 февральдә Мәскәүгә, Бөтенроссия эстрада сәнгате иҗат остаханәсенә түбәндәге артистлар укырга җибәрелә: сөйләм жанры буенча – Нәзифә Кашапова, Виктор Шәрәфетдинов, Надия Низамиева, Мәрзия Вәлиева, Зәйтүнә Яруллина; вокал жанрына – Зиннур Нурмөхәммәтов, Клара Хәйретдинова, Рабига Сибгатуллина, Римма Ибраһимова; бию һәм оригиналь жанрларга – Мөнир Мөхәммәтдинов, Эльба Закирова, Рөстәм Юнысов, Татьяна Романова, Галина Васильева. Әзерлек мәсьәләләре буенча филармониянең сәнгать җитәкчесе Мәхмүт Нигъмәтҗанов биш көнгә Мәскәүгә юллана»...*

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты **Мәхмүт Нигъмәтҗанов** 2002 елның 18 октябрендә «Ватаным Татарстан» гәҗитендә бастырган «Еллар һәм юллар» мәкаләсендә әлеге вакыйга турында болай дип бәян итә: *«Инде 20-30 нчы елларда ук татар артистлары Урта Азиядән алып Себер якларына кадәр гастрольләрдә йөргәләде. 60 нчы елларда татар эстрада-*

Филармониянең сәнгать җитәкчесе Мәхмүт Нигъмәтҗанов. 1970 нче еллар

сы шактый таптала башлаган иде – бригадада бер-ике баян, баян белән гармун, 2-3 җырчы, 1-2 биюче, бер үк биюче 2-3 биюне костюмнар алыштырып бии... Һәм гадәттә, конферансье. Бездә беренчеләрдән булып Илһам Шакиров, Әлфия Авзалова вокал-инструменталь ансамбльләр белән чыгыш ясый башладылар... Татар эстрадасын баетырга, үзгәртергә, заманча алымнар файдаланырга кирәклеге көн тәртибенә килеп басты. Шул максат белән, әле күптән түгел Мәскәүдә Бөтенроссия эстрада студиясе ачылудан файдаланып, бер төркем яшьләрне туплый башладык. Кызганыч ки, Казанда консерватория, берничә музыка училищесы булуга кармастан, республикага кирәк кадрларны кайгырту юк иде (сүз милли ансамбль, эстрада турында бара). Безгә саф татарча сөйләрлек, җырларлык, биерлек яшьләр кирәк иде. Газеталарда игъланнар биреп, берничә йөз кешене тыңлап чыкканнан соң, 14 кешене сайлап алдык, алар арасында музыка әлифбасын белгәннәре дә юк иде... Яшьләрне сайлаганда Айрат Арсланов, Әдһәм Нарыков даими катнашты. Студиядә уку программаларын андагы педагоглар белән сайлый идек. Безнең булачак җырчылар илнең иң күренекле артист-педагоглары Ирма Яунзем, Георгий Виноградов кебек шәхесләрдә белем алды...»

Мәхмүт Нигъмәтҗанов җырчыларга һәм музыкантларга һәрдаим бик нык ярдәм итә. Тора-бара аларның күбесе халкыбызның яраткан артистларына әверелә.

Уку еллары турында сөйләүләрен сорап, әлеге сәхнә осталарының кайберләренә мөрәҗәгать иттек.

Рабига Сибгатуллина, Казанга килгәч, Сара Садыйкова җитәкләгән хорга йөри башлый. Композиторның киңәшенә колак салып, 1969 елда Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенә эшкә килә. 1970 елга кадәр Бөтенроссия эстрада сәнгате остаханәсендә (Россиянең халык артисты И.П.Яунзем классында) белем алып, халыкчан пландагы эстрада җырчысы булып өлгерә.

Татарстанның халык артисты Рабига Сибгатуллина: *«Мин Казанга килеп Теплоконтроль заводында эшләгән чакта Горький клубында (ул Бауман урамында урнашкан иде) Сара апа Садыйкова җитәкләгән хорга йөрдем. Беркөнне Сара апа миңа: «Мәскәүгә конкурс нигезендә укырга җыялар икән, әйдә, син дә бар», – диде. «Минем андый ерак җиргә барасым, артист буласым килми», – дидем. Шунда Сара апа, өстәл сугып: «Ул нинди сүз, иртәгә үк филармониягә барасың, шушы талантың белән бармыйча калырга хакың юк!» – диде. Без анда Рәйсә исемле кыз белән бардык. Жюри алдында Мансур*

Рабига Сибгатуллина халкыбызның сөекле композиторы Сара Садыйкова белән. 1968 ел

Мозаффаровның Мөнир Мазунов сүзләренә язылган «Туган як», Сара Садыйкованың Мостафа Ногман сүзләренә иҗат ителгән «Актаныш таңнары» җырларын башкардым. Мине шунда ук сайлап алдылар. Шулай итеп, заводтан китеп, тиз арада Мәскәүгә юл тотарга туры килде. Сара апа вокзалдан кул изәп озатып калды.

Әйтергә кирәк, Мәскәүдә уку – иҗатыма зур этәргеч булды, иңнәремә канат үскәндәй хис иттем үземне. Җырчы Зиннур Нурмөхәммәтов белән без филармониягә башкалардан алдарак кайттык һәм, яшьләр бригадасына оешып, бергә эшли башладык. Калганнар да кайткач, мин Габдулла Рәхимкулов төркеменә күчтем...»

Зәйтүнә Яруллина. 1969 ел

Зәйтүнә Яруллина, Казан театр училищесын тәмамлагач, Татар дәүләт филармониясендә эшли башлый. Мәскәү остаханәсендә белем эстәп кайткач та, эстрада бүлегендә утыз елга якын төрле концертлар алып бара.

Татарстанның атказанган артисты Зәйтүнә Яруллина: *«Мәктәпне тәмамлагач, театр училищесының кичке бүлегенә кереп, анда дүрт ел укыдым. Көндезен Теплоконтроль заводында эшләдем. Рәшидә Җиһаншина, Асия Хәйруллина кебек күренекле сәхнә осталарында укып, ирекле диплом алып чыктым һәм Татар дәүләт филармониясенә эшкә килдем. Мине җырчы Габделхак Шаһиев бригадасына алып баручы итеп билгеләделәр. Тик, авырып китү сәбәпле, сәхнәгә чыгуым кичектерелде. Филармониядән китеп, Бөтенроссия иҗат оешмасына инструктор булып эшкә урнаштым. Өч ай эшләгәнмендер, Габделхак абый Шаһиев килеп кермәсенме! «Качкын кыз, нәрсә эшлисең монда? – диде ул, гаҗәпләнеп. – Дүрт стенага карап торасыңмы? Иртәгә*

Клара Хәйретдинова. 1969 ел

үк филармониягә кил, Мәскәүгә укырга җибәрер өчен конкурс үткәрәләр». Мин әлеге конкурстан үттем.

Укучылар арасында Зиннур белән иң өлкәне без идек. Анда миңа, асылда, урысча проза әсәрләре, мәсәлләр укырга бирделәр. Сәхнә телен театр училищесында өйрәнгән кеше буларак, ул өлкәдә әллә ни яңалык алмадым. Кызганычка, миңа татарча концерт программасы әзерләнмәде. Шулай да, Мәскәүдә укуның тәэсире булгандырмы, әдәби әсәрләр сөйләгәндә, төрле образлар табып, аларны музыкаль элементлар, җырлар, хәрәкәтләр белән баета башладым. Тамашачы матур кабул итә иде...»

Клара Хәйретдинова да 1969 елда филармония оештырган конкурстан үтеп, Мәскәүгә, Бөтенроссия эстрада сәнгате иҗат остаханәсенә укырга китә.

Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Клара Хәйретдинова: *«Мин ул конкурс хакында гәҗиттә басылган игъланнан укып белдем. Вертолет заводы клубында үзешчән сәнгатьтә актив катнашканлыктан, үземне сынап карарга булдым. Конкурстан үткәч, Мәхмүт ага Нигъмәтҗанов, үз балаларыдай якын итеп, безне Мәскәүгә кадәр озата барды. Уку елларында да, Мәскәүгә килә калса, хәлебезне белми китми иде.*

Безнең татар булуыбызны белгәч, халык шакката иде: «Татарлар мондый буламыни?» Алар безне чыңгызый кыяфәтле, кысык күзле итеп уйлаган, күрәсең. Бу елларда яныбызга Айрат абый Арсланов ешлады. Гаять чибәр, мәһабәт гәүдәле Айрат абыйны күргәч, безнең белән укучылар барысы да таң калды. Ул төс-кыяфәте, үз-үзен тотышы, иҗаты белән һәрчак соклану уятты.

Остаханәдә иртәнге якта бию, пантомима, нәфис сүз, сәхнә теле дәресләре бирелә иде. Төштән соң Г.П.Виноградовта вокал буенча шөгыльләнә идем. Бу елларда Людмила Зыкина, Юрий Левитан кебек мәшһүр артистларның чыгышларын карау миңа искиткеч мәктәп булды...»

Римма Ибраһимова, Эльба Закирова. 1971 ел

Римма Ибраһимова 1967 елда урта мәктәпне тәмамлап, Казанга килә һәм Горький исемендәге Мәдәният сарае каршында Сара Садыйкова җитәкләгән сәнгать түгәрәгенә йөри башлый. Ул, күренекле композитор киңәшенә колак салып, Мәхмүт Нигъмәтҗанов хозурына килә. Филармониянең сәнгать җитәкчесе аны бер төркем артистлар белән Мәскәүгә Бөтенроссия эстрада остаханәсенә укырга җибәрә. Римма Ибраһимова студиядә вокал буенча Георгий Павлович Виноградовта белем ала.

Аның булачак ире, оригиналь жанр остасы **Равил Таишев** та 1969-1970 елларда Мәскәүдә укый.

Татарстанның халык артисты Римма Ибраһимова: *«Казанга килеп, университетның*



Оригиналь жанр остасы Равил Таишев. 1970 нче еллар

Оригиналь жанр остасы Татьяна Романова. 1970 ел

тарих бүлегенә керермен, дип, тәүге имтиханны уңышлы гына биргән идем. Анда билге куелган кенәгәне югалттылар, китәргә мәҗбүр булдым. Ул арада, бәхетемә, күрәсең, бу конкурс турында белеп алдым. Жюрига Алмаз Монасыйповның Роберт Әхмәтҗанов сүзләренә язылган «Кояшларың белән кил син миңа» җырын башкардым. Ничектер, үттем.

Мәскәүнең без урнашкан «Северный» кунакханәсендә төрле халыклар яши иде. Иртә китәбез, кич кайтабыз, әйбәт, күңелле яшибез. Укудан соң төрле концертларга йөрибез, безне бушлай үткәрәләр. Без инде, билгеле, мөмкин кадәр күбрәк, ешрак йөрергә тырыштык.

Мине вокал буенча атаклы җырчы Георгий Павлович Виноградов укытты. Безгә махсус программа әзерләделәр. Клара Хәйретдинова белән бергә дуэт җырладык. Композитор Әгъзам Фәттах Сибгат Хәким сүзләренә «Бер тауда ун чишмә» җырын махсус безнең өчен иҗат итте. Шулай ук, «Ай, борма-

Җырчы Зиннур Нурмөхәммәтов. 1970 нче еллар

лы су буйлары» (Н.Исәнбәт сүзләре, З.Хәбибуллин музыкасы), татар халык, поляк җырларын да башкара идек.

Равил Таишев Украинада туган кеше, аның әти-әнисе Пенза ягыннан. 1964 елда ул Киевның «Сәхнәдә цирк» группасында артист-велофигурист булып эшли. Бер елдан цирк-эстрада студиясен тәмамлый. Шунда укыган чакта «Омичи на эстраде» исемле эстрада-цирк төркеменә килеп эләгә һәм алар белән Мәскәүгә килә.

Безне күргәч, тамырларында татар каны уянып киткәндер, гел яныбыздан китмәде. Укулар ахырына якынлашкач, бригадасыннан китеп, безнең белән Казанга кайтты һәм филармониягә эшкә урнашты. Аның бик үзенчәлекле цирк номерлары бар иде. Самавыр өстенә тәлинкә, аның өстенә чәйнек куеп, аягы белән бер тәгәрмәчле велосипедны йөртеп, сәхнә буйлап әйләнә иде. Ник берсе төшеп китсен! Казанга кайтып бер ел узгач, өйләнештек...»

Акробатика буенча оригиналь жанр артисты **Татьяна Романова** да 1971 елда әлеге курсларны тәмамлап, танылган җырчы һәм тормыш иптәше, Татарстанның халык артисты **Зиннур Нурмөхәммәтов** иҗат төркемендә эшли башлый. Ул концертларда төрле пластик бию этюдлары, акробатик номерлар башкара.

Оригиналь жанр остасы Татьяна Романова: *«Мин филармониядә Габделхак Шаһиев, Галия Гафиятуллина бригадасында 1967 елдан эшли башладым. Зәйтүнә Абдуллина, Нәҗия Минкина, Әнвәр Латыйпов, Хәй Мушинскийларга рәхмәтлемен. Алар белән гастрольләрдә аралаша торгач, әкрен генә татарчага да өйрәндем. Тик ерак сәфәрләр ялыктыра иде. Ике елдан, бүтән эшләмәм инде, дип, китәргә булдым. Шулчак Мәхмүт Нигъмәтҗанов әлеге конкурска чакырып телеграмма җибәрде. Ул мине филармониядә эшләгәндә үк исендә калдырган икән.*

Мәскәүдәге педагогым Глеб Борисович тумышы белән Казаннан иде. Сәхнәдә хәрәкәт итү, ритмика буенча Тамара Птицина укытты.

Һавада башкара торган берәр номер өйрәнәсе килде. Ул вакытта Мәскәү циркы түгәрәк кыршау эчендә чыгыш ясауга өстенлек бирә иде. Педагоглар бераз хәйләләргә булды: Татарстанда ярым ай символик мәгънәгә ия, дип, кыршауны ярым ай рәвешендә

Виктор Шәрәфетдинов, Эльба Закирова «Цирк килде» номеры белән. 1970 нче еллар

эшләделәр. Режиссерлар Т.Птицина, Л.Маслюков тарафыннан сәхнәгә куелган бу номер бик үзенчәлекле килеп чыкты.

Шулай итеп, «Яңа туган айда – татар кызы Зөһрә» исемле әдәби-хореографик номер минем төп чыгышыма әверелде. Композитор Алмаз Монасыйпов аңа махсус көй иҗат итте, күренекле нәфис сүз остасы Айрат Арсланов легендадан өзекләр укыды. Ул номерны Мәскәүдән кайткач та бик еш башкардым.

Мине Мәскәү циркы да, Москонцерт та эшкә чакырып карады. «Казан акча түләп укытты, ничек биредә калыйм, һичшиксез, Казанга кайтам!» – дидем.

Мәхмүт абый Мәскәүгә килгән саен педагоглар аны: «Главный татарин приехал!» – дип, хөрмәт белән каршы алалар иде. Ул һәрвакыт безнең турыда кайгыртып торды.

Казанга кайтып төшүебез фейерверк атуга тиң иде. Чөнки аңарчы эстрада сәхнәсендә гадилек, бертөрлелек хөкем сөрә иде сыман.

Зиннур Нурмөхәммәтов белән безне сәхнә һәм гастрольләр бәйләде. Аның чыгышы һәрвакыт концертларның кульминациясе була иде. Ул сәхнәгә очып, биеп чыга, үзенең җиңеллеге, күркәмлеге, моңлы тавышы белән тамашачыны әсир итә иде. 1970 елда Мәскәүдә, Бөтенсоюз конкурсында «Песняры», «Воронежские девчата» төркемнәре, Лев Лещенко, Рита Суварова, Аида Ведещева кебек башкаручылар белән беррәттән катнашып, җиңү яулады, дипломант исеменә лаек булды. Шуннан соң аны «Юность» радиосына чыгыш ясарга чакырдылар. Ул анда «Идел» вокал-инструменталь ансамбленә кушылып җырлады...

Казанга кайтуга, без Идел буе төбәкләренә чыгып киттек. Әле дә хәтерлим: Әстерханга килгәч, безне атлы милиция саклады, чөнки концерт залына керергә теләүчеләрнең иге-чиге юк иде. Пыяла ишекләрне ватып та керделәр хәтта...»

Студиядә укучылар арасында **Виктор Шәрәфетдинов** иң яше була. Ул анда нәфис сүз, пантомима, жонглерлык, фокус серләрен үзләштерә.

Татарстанның атказанган артисты Виктор Шәрәфетдинов: *«Конкурсның йомгаклау турында дулкынланып кына Һади Такташның «Мокамай» поэмасыннан өзек, «Кырмыска футбол уйный» (авторын хәтерләмим) дигән шаян шигырь сөйләдем. Леонид Семенович Маслюков һәм башка жюри әгъзалары, яшь булуыма карамастан, чыгышымны уңышлы дип таптылар, күрәсең – мине нәфис сүз төркеменә керттеләр...*

Остаханәнең бер ягында – акробатика, икенче ягында бию заллары иде. Җәен бирелә ачык сәхнәдә цирк программалары күрсәтелде. Көннең беренче яртысында безгә бию дәресләре керә, аннары үз педагогларыбызда шөгыльләнә идек. Сөйләм техникасы буенча педагог-актриса Александра Алексеевна Харламова классында һәм Алла Юрьевна Шапоринада укыдым.

Иҗатыма карата иң беренче киңәшләрен биргән, миңа, гомумән, юл күрсәткән олуг шәхесне – филармониянең сәнгать җитәкчесе Мәхмүт ага Нигъмәтҗановны хөрмәт белән искә алам. Ул ярты елга бер мәртәбә безнең янга килеп китә, филармония директоры Михаил Юрьевич Первинны да үгетләп китерә иде кайчакта. Шөкер, без әле дә аның белән аралашып торабыз...»

1968 елда Татар дәүләт җыр һәм бию ансамблендә эшли башлаганда биюче **Эльба Закировага** 17 яшь була. Иҗатташлары Рузалия һәм Рәшит Мостафиннар аны конкурста катнашып карарга үгетлиләр. Ул, филармониянең сәнгать җитәкчесе Мәхмүт Нигъмәтҗановтан фатиха алып, бәхетен сынап карарга була, татар һәм урыс биюләрен башкара. Нәтиҗәдә, Эльба Закирова да бер төркем яшьләр белән Мәскәүгә укырга китә.

Татарстанның атказанган артисты Эльба Закирова: *«Укучылар арасында биючеләр дүртәү идек: Рөстәм Юнысов, Мөнир Мөхәммәтдинов, Галина Васильева һәм мин. Педагогларыбыз – танылган бию осталары, РСФСРның атказанган артистлары Анна Аркадьевна Редель, Михаил Михайлович Хрусталев булды. Безне парларга бүлделәр һәм биюләрне өйрәнү, сәхнәгә кую эше башланды. Мөнир белән икебезгә үзенчәлекле «Татар биюе» һәм акробатика алымнары кергән «Көтелмәгән очрашу» дигән бию куйдылар.*

Аннары мин «Катюша» җырына нигезләнгән «Казачок» исемле шаян бию өйрәндем. Барлык номерлар өчен дә үзенчәлекле, заманча киемнәр һәм матур аяк киемнәре тегелде. Без, Мәскәүнең төрле оешмаларында концертлар куеп, Казанга кайттык, татар эстрадасына яңа сулыш өреп, матур гына эшли башладык.

Бөтенроссия эстрада сәнгате иҗат остаханәсе белән элемтәбез әле аннары да дәвам итте. Филармония җитәкчелеге мине Виктор Шәрәфетдинов белән яңа дуэт итеп, янә Мәскәүгә җибәрде. Режиссерыбыз – Алексей Карпенко, хореограф Ирина Дагаева булды. Безгә өч өлештән торган «Цирк килде» дигән эстрада номеры куйдылар. Бу биюдә дөнья гизүче артистлар ролендә «тәгәрмәч», «шпагат»лар ясадык, кечкенә туплар белән жонглерлык иттек... Каһарман-шагыйрь Муса Җәлилгә багышланган «Өзелгән җыр» исемле героик пантомима репертуарыбызда төп номер булып китте. Шул репертуар белән бөтен Советлар Союзын йөреп чыктык, чит илләрдә чыгыш ясадык...»

Язманы Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе музее мөдире ***Алсу Хәкимова*** *әзерләде.* ■

Безнең мирас №3 март 2019

Сүзләр иленә сәяхәт*

(Лингвистик хикәятләр)

Гәрәй Рәхим

Тарихта бер халыкның икенче халыкка үзенчә исем кушуы гадәти хәл. Мәсәлән, урыслар Германиядә яшәүче төп милләткә «немец» дигәннәр. Гәрчә дөньяның башка илләрендә бу халыкны, Германиянең үзендәгечә, чын исеме белән «дойч» дип атыйлар. Ә «немец» сүзе ул – гап-гади урыс сүзе һәм «немой» (телсез, чукрак) дигән сүздән килеп чыккан.

Эш болай булган: урыслар беренче мәртәбә немецларны күргәч, болар, билгеле инде, үз телләрендә сөйләшкән. Табигый ки, урыслар аларны аңламаганнар һәм сөйләшүләрен телсез кешеләрнең төрле мәгънәсез аваз чыгаруларына охшатканнар. Нәтиҗәдә, алар хакында, урысча әйткәндә, немец икән (немой + ец) дигән нәтиҗәгә килгәннәр. Вакыт үтү белән бу исемнең мыскыллы төсмере онытылган, ул Россиядәге барлык халыклар өчен «дойч» милләтенең атамасы булып киткән.

Төрки-татар теле дә үзенә тугандаш булмаган ике халыкка исем бүләк иткән. Аларның берсе – славян халыклары вәкиле булган украиннар, икенчесе – монгол халыклары вәкиле булган калмыклар. Әйе, «украин» һәм «калмык» дигән сүзләрнең икесе дә төрки-татар сүзеннән килеп чыккан. Калмык сүзе бүгенге телебезгә бик тә якын тора, шуңа күрә башта аны карап китик.

Алтын Урда дәүләте таркалганнан соң, Көнчыгыштан килеп күп илләрне басып алган, кайчандыр гаять көчле булган монголлар тәмам көчсезләнеп-зәгыйфьләнеп калалар. Халыклар, милли азатлык хәрәкәте белән рухланып, аларга каршы көрәшә. Мондый шартларда монголларга кире үз далаларына кайтып китәргә яки башка милләтләр арасында яшәүне дәвам итәргә, аларның телләрен, гореф-гадәтләрен алып, милләт буларак алар арасында эреп югалырга гына кала. Монголларның бер өлеше, шул рәвешле, үз илләрендәгедәй далалар табып, Кавказның төньягында төпләнеп кала. Төрки халыклар боларны «калган кеше», «калмык кеше» дип атый башлый. Мондый юл белән ясалган сүзләр бездә еш очрый: *ик + мәк* (игелгән, игеннән ясалган ризык), *кис + мәк* (кисеп ясалган савыт), *так + мак* (кемгәдер тагылган (багышланган) җыр), *тук + мак* (тукмау яисә төю өчен ясалган эш коралы) һәм башкалар.

«Украин» сүзе исә «калмык» кебек чип-чиста төрки сүз түгел. Аның тамыры гына төрки-татарныкы. «Край» – татарча «кырый» дигән сүз, ягъни нәрсәнең дә булса чите, чиге. Безнең илдәге административ-территориаль бүленеш буенча үзәктән читтәрәк урнашкан өлкәләр нәкъ менә шушы «кырый» дигән сүз белән аталып йөртелә дә: Краснодар крае (илнең Краснодар дип аталган *кырые*), Ставрополь крае...

*Журнал варианты. Ахыры. Башы басмабызның 2 нче санында.

Украинаның хәзерге территориясе, бигрәк тә аның көнбатыш һәм көньяклары борынгы славяннар дәүләтенең чиге, кырые булган. Чик буйларына күчеп килгән кешеләрне «кырыйда яшәүчеләр» («живушие у края») дип йөрткәннәр. Әкрен-әкрен «у края» дигән сүзгә урысларның *-ин* суффиксы кушылып, бу сүз «украин» (у + край + ин) дигән рәвешкә кергән.

Кайбер галимнәр исәбенчә, безнең «казанлы», ягъни «Казанда яшәүче» дигән сүз дә тарихи яктан, «украинлы» дигән шикелле, «кырыйда, читтә яшәүче» мәгънәсенә ия. Профессор А.Х.Халиков карашынча, «Казан» сүзенең «каз» өлеше җир өстендәге «кәз»не («кәс») аңлата. Белгәнебезчә, кәс – җирнең иң өсте, чите, кырые. Казан, галим карашынча, чыннан да, Болгар дәүләтенең төньяк-көнбатыш чигендә хәрби нытма буларак салынган шәһәр. Һәм анда яшәүчеләрнең «казанлы», ягъни читтә, кырыйда яшәүче булуы табигый да.

***

Сез, «Тын Тын», «Кытай Кытай савыты», «елга елгасы», «сары үлән үләне» дигәнне ишетсәгез, аптырар идегез, билгеле. Шулай да, тел тарихы ягыннан карагандa, бу әйтелмәләрдә бернинди ялгыш юк, аларның барысы да сезгә таныш гыйбарәләр.

Беренчесе – атаклы урыс язучысы Михаил Шолоховның һәрберебез яратып укыган «Тын Дон» әсәре. Дон елгасы үзе үк төрки-татарча Тын елга дигән сүз. Бик борынгы заманнарда, бу елганың исеме әле юк чакта, күчмә төркиләр, дала буйлап күченә-күченә, шушы елга ярына килеп чыкканнар. Көн матур, җилсез булган, күрәсең, төркиләр тып-тын гына агып яткан дала елгасына сокланып карап торганнар да: «Бу – Тын булыр», – дигәннәр. Урыслар, моны ишетеп, сүзне аз гына үзләренчә авыштырганнар һәм елганы «Дон» дип атап киткәннәр. Күрәсең, тын, тыныч булып агу бу елгага, чыннан да, хас күренештер, әнә бит, Шолохов та аны «Бурный Дон» димәгән, ә нәкъ борынгы төркиләр сыман «Тихий Дон» дип атаган.

Инде «Кытай савыты», «таш савыт»ка килсәк, болары да гади генә сүзләр. «Кытай кытай савыты» дигән тавтология «кытай чынаягы» дигән сүз. «Чынаяк» ике сүздән тора: *чын* һәм *аяк*. *Аяк* – хәзерге тел белән әйткәндә, *савыт* дигән сүз. Аның шулай әйтелеше бүгенге көндә, шул ук «чынаяк»тан тыш, «ташаяк» (таш савыт) һәм «кашыгаяк» (кашык-савыт) дигән сүзләрдә сакланып калган. «Чынаяк»ның беренче өлешендәге «чын» сүзе һич кенә дә *асыл (настоящий)* дигән мәгънә белдерми. Бу очракта аның чын фарфордан эшләнү-эшләнмәве игътибарга алынмый. «Чын» – кытай дигән сүз ул. Кытайлар үзләре дә, Европа халыклары да кытайлыларны «чиннар», ә Кытай илен *Чин иле* дип йөртәләр.

«Елга елгасы»н да шушы ук юл белән сүтәбез. Монысы «Идел елгасы» дигән сүз була. Чөнки борынгы болгар-татар телендә теләсә нинди елга, инеш «идел» дип тә аталган. Мәсәлән, Чулман иделе (Каманың борынгы исеме), Ак идел, Кара идел, Чирмешән иделе һ.б.

Инде «Сары үлән үләне»нә килсәк, безнең якларда бик күп үсә торган һәм телебездә гаять актив йөргән *сарут* ул. «Ут» борынгы төркичә «үлән» дигәнне аңлата (*ут + ар, ут + лау, ут + сулык* сүзләрен искә төшерегез).

Шунысын да искәртергә кирәк: чыннан да, бу үлән, җирдән башын калкытуга саргылт-яшел төскә керә, ә киң коры далаларда ул җәй һәм көз буе сап-сары булып утыра. Шушы сарылыгы өчен аңа борынгы бабаларыбыз «сарут», ягъни «сары үлән» дип исем биргән дә.

***

Телбизәрнең бөтен әгъзалары сүздән генә тора, дигән идем. Аның кием-салымы да сүзләрдән тегелгән. Кинәт мина Телбизәр кызганыч булып китте: аның бит

гомерендә дә чын кием-салым күргәне юк! Шуннан мин аны шәһәребезнең иң күркәм кибетләреннән берсе булган «Богатырь»га алып киттем. Телбизәр, кибет янына килеп җиткәч, туктап калды, кибет түбәсенә неон лампалары белән зур итеп «Магазин «Богатырь» дип язылган иде. «Кибеткә кергәндә белеп кер, – диде миңа Телбизәр, – «магазин» сүзе урысларга гарәпләрдән кергән, гарәпчә ул «мәһгазин» дип яңгырый, ә «богатырь» дигәне – төрки-татар телендәге «баһадир» сүзенең җиңелчә үзгәртелеше генә. Ул әллә кай заманнарда ук урыс теленә кереп калган бик борынгы сүз».

Телбизәр белән кибеттә тыныч кына әйбер карап йөреп булмый иде. Ул һәр товар янында туктала да миңа аңлата башлый: «Менә бу күлмәкне кара әле. Урыслар аны «сорочка» дип атыйлар. Аларда саесканны «сорока», ә кырык санын «сорок» диләр. Болар барысы да татар халкының борынгы баш киеме – «сүрәкә»дән килеп чыккан. Хәзер инде бу татар сүзе керәшеннәрдә генә сакланган. Игътибар белән тыңла, мин сиңа сүрәкәнең ниндирәк баш киеме булуын сөйлим...»

Телбизәр сөйләгәндә кылт итеп исемә төште: мин туган керәшен саласында, элекке Шөгер (хәзерге Лениногорск) районының Федотовка авылында, әле илленче елларда да *сүрәкә* киючеләр бар иде. Күк йөзендә канатларын какмыйча гына очып барган саесканны күргәнегез бардыр? Сүрәкә нәкъ әнә шул кыяфәттә. Әнә шул саескан-сүрәкәнең (ул тукымадан тегелә) койрыгын артка табан куеп, башка каплыйлар, ике канатын колак өстеннән артка табан үткәрәләр дә, башның артында, муен турысында икесен очраштырып, бәйләп куялар. Сүрәкәнең маңгайда калган ягы кәйтән (позумент) белән бизәп чигелгән була, баш киеменең ул өлеше өстән яулык бәйләгәндә матурланып күренеп тора.

Шундый охшашлык булганга күрә, урыслар саесканны *сүрәкә (сорока)* исеме белән атаганнар да. Җиңнәре турыга гына утыртып куелган, якасыз, гап-гади тегелгән элекке озын күлмәкне җәеп салсагыз, сез аның да нәкъ сүрәкә һәм саескан кыяфәтендә булуын күрерсез: ике җиңе – ике канат, озын итәге – койрык. Урысларга безнең төшенчә бик тә охшап киткән, күрәсең: алар бу күлмәкне дә, иркәләү-кечерәйтү кушымчасы ялгап, «сорочка» (сүрәкәчек) дип атаганнар.

Инде «сорок» санына килсәк, галимнәр арасында аның турында, кем әйтмешли, кырык төрле фикер яши. Беренче чиратта шуны әйтергә кирәк: урысларда бу сан башка унлы саннарга һич охшамаган, чөнки аларда һәр унлы санның азагы «десятъ» дигән сүзгә бетә: *два + дцать, три + дцать, пять + десят, шесть + десят* һ.б. Ә менә *кырык* санын аңлатучы «сорок» сүзе бу канунга буйсынмый, үзенә аерым булып бүлтәеп тора. «Сорок»ның каян килеп чыгышына төп ике фикер бар һәм аларның икесе дә төрки телләргә килеп тоташа. Бер төркем телчеләр болай дип фараз итә: имеш, урыс сәүдәгәрләре үз заманында базарларда күлмәк (сорочка) сатканда, аларны кырыгар данә итеп, төргәкләп сатканнар, һәр сатып алучы бәйләмдә нәкъ кырык күлмәк икәнен яхшы белгән һәм бу бәйләмнәрне «сорок» дип атый башлаганнар.

Башка телчеләр төркеме карашынча, «сорок» турыдан-туры безнең «кырык» дигән сүзгә килеп тоташа, ягъни шуның үзгәртелмеше генә. Монда «к» авазының ничек итеп «с» авазына әверелүе аңлашылса, бөтен нәрсә үз урынында булыр иде: *сорок – корок – кырык*. Чуашларда, мәсәлән, бу сан «хырых» дип атала. Күренә ки: беренче авазның үзгәреш кичерүгә маһирлыгы бар. Димәк, «кырык»ның «сорок»ка әверелүе бик ихтимал, дип саный Телбизәр.

Кадерле дуслар! Шушы урында Телбизәр һәм бу юлларның авторы сезнең белән вакытлыча саубуллаша. Ни өчен, вакытлыча, дим?! Чөнки мәгълүм язучы-галим әйтмешли, тел – иксез-чиксез дәрья ул. Алда безне, һичшиксез, шул дәрьяга яңа сәяхәтләр көтә. ■

ЯХШЫ ХАТЫН – ИР КҮРКЕ

*(Хатын-кызлар хакында халык мәкальләре һәм әйтемнәре)**

Казан татарлары

- Белемле кыз – бирнәле кыз.
- Кызлар – кыл өстендә.
- Кылдан төшкәч, тел өстендә.
- Кызын ормаган, тезен орыр.
- Кызыңның төсен мактама, эшен макта.
- Уналты яше җиткән кыз энә өстендә бии.
- Артык буяну чын матурлыкны күрергә комачаулый.
- Битеңне бизәмә, акылыңны бизә.
- Буянган кыздан оялган кыз матур.
- Матурлык күлмәк белән сәдәптә түгел, оят белән әдәптә.
- Оялчан кыз мәхәббәтле булыр.
- Аулак өйдә кыз сайлама, урак кырында сайла.
- Ирләр якасы иснәмәгән кыз булсын.
- Яңгырда ат сайлама, бәйрәмдә кыз сайлама.
- Дәүләт-байлык – дус-иш, яхшы исем – хатын аркасында.
- Яхшы хатын – дөнья җәннәте, яхшы хатын – җан юлдашы, яхшы хатын – ил күрке.
- Яман ат – иясен, яман хатын ирен картайтыр.
- Хатынның – сараны, ирнең юмарты яхшы.
- Бер хатын иренең йөзенә карап көлсә – ун савап; Үпсә, утыз савап; Кочса, кырык савап!
- Аерырга булгач – хатын, күчәргә булгач, авыл яман.
- Хатын-кыз эше тавык чүпләп бетергесез.
- Хатын-кыз юк өйдә ертык ямалмас, малның кадере булмас.
- Алган ире яратса, кара хатын да ак булыр.
- Ирен сөйгән хатынның өенә нур явар.
- Бер хатын алдында икенче хатынны мактама.
- Бигрәк тиз ачулана торган кешеләр – сабыйлар белән хатын-кызлар.
- Тату гаиләнең бишеге буш булмый.
- Анаңны аркаңа йөкләп өч кат Мәккәгә алып барсаң да, бурычыңны үтәп җиткерә алмассың.
- Анасын танымаган, Алласын танымас.
- Ана балага авызыннан өзеп каптырыр.
- Ана баланы ашатканда – дәрьядан юмарт, балалар ананы ашатканда – һәр көне исәптә.
- Ата-ананы тыңлаган – адәм (кеше) булган, тыңламаган – әрәм булган.

*Басмага **Фатих Кутлу** әзерләде.* ■

---

*Нәкый Исәнбәт.Татар халык мәкальләре. Икенче том. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2010.

Татарстан Республикасының Милли китапханәсе



ҮЗБӘК БАЙЧУРА ТУПЛАНМАСЫ

Үзбәк Шәриф улы Байчура 1923 елның 6 гыйнварында Казанда туа. Әтисе – танылган журналист Шәриф Байчура, әнисе – табибә Әминә Алимбәк.

1948 елда ул Казан юридик институтын, 1949 елда Казан дәүләт педагогия институтын тәмамлый. Озак еллар дәвамында Казанның төрле югары уку йортларында эшли: 1954-1959 елларда Казан дәүләт университетында һәм, беррәттән, 1953-1963 елларда СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институтында фәнни хезмәткәр булып эшли. 1966-1971 елларда ул Мәскәүгә, СССР Фәннәр академиясенең Тел белеме институтына күчә. 1966 елда шунда докторлык диссертациясен яклый.

Үзбәк Байчура 1972 елдан Ленинград университетында укыта. Татар теле, төрки, фин-угыр, алтай телләре буенча фонетик тәҗрибәләр ясаган күп фәнни хезмәтләре дөньяга чыга. Ул рентген сурәтләре һәм палатограмма ярдәмендә татар телендәге фонема бүленешенең асылын, төрки телләрдәге сүз басымын, сузык һәм тартык авазлар системасын сыйфат һәм артикуляция ягыннан ачыклап, фәнни тасвирлауга ирешә.

Үзбәк Байчура 1996 елның 13 мартында Санкт-Петербургта дөнья куя.

Дәвамы. Башы журналның 2017 елгы 10 нчы санында.

Үзеңнең надан икәнлегеңне беләсең килсә, күп китап укы.

Татар халык мәкале

400 китап һәм архив документларыннан торган Ү.Байчура тупланмасын гаиләсе 1997 елда Милли китапханәбезгә тапшырды. Галим гомере буе туплаган китаплар җыелмасының төп нигезен төрле халыкларның (татар, төрки, фин-угыр, алтай һ.б.) тел белеменә, тел тарихына караган хезмәтләр, XX гасырда басылган төрле телләрдәге сүзлекләр хасил итә.

Тупланманың яртысы рус телендәге басмалардан, калганы якын һәм ерак чит илләрдә төрек, фарсы, алман, инглиз һ.б. телләрдә чыккан сирәк китаплардан тора. Архив документлары, хатлар һәм фоторәсемнәр исә танылган галимнең шәхси тормышын, фәнни эшчәнлеген ачыкларга ярдәм итә. ■

Иске Казанда – саклану һәм һөҗүм иту кораллары

*«Иске Казан» музей тыюлыгы 2010 елда «Таттелеком» АҖ генераль директоры **Лотфулла Нурислам улы Шәфигуллин** һәм аның җитәкчелегендәге хәйриячеләр ярдәме белән өр-яңадан төзекләндерелде. Музей территориясенә урта гасырдагы саклану һәм һөҗүм иту кораллары да урнаштырылды. Биредә шуларның икесен тәкъдим итәбез.*

Диварваткыч (мангонель) – урта гасыр сугыш коралының «йөзек кашы». Зур көчкә ия булган диварваткыч җайланмалар XIII гасырның башларында ук киң кулланыш таба. Диварваткыч – шулардан иң камиле, ул көчле җимерү куәтенә ия. Төзелеше: ыстан, ике зур чыгыр, ату рычагы (10-12 метр), аның башында – каршы авырлык (10 тоннага кадәр), нык баулардан үреп ясалган ядрә кәрзине. Диварваткыч 100-150 кг.лы ташларны 200 метрга кадәр ыргыткан. Сәгатенә ике тапкыр ату мөмкинлеге булган бу коралны 50-120 кеше хәрәкәткә китергән. Аннан ике тапкыр төгәл итеп атып, теләсә нинди диварны җимерергә мөмкин булган. Җимерелгән урыннан җәяүле һәм атлы гаскәрләр дивар эченә җиңел үтеп керә алган.

Туп (баллиста) – грекча – «ыргыту», б.э.к. 450 нче елда барлыкка килә. Бу – ике иңсәле машина. Ул таш яки ук ату өчен кулланылган. Туп агач сап ярдәмендә юан бауны чорнап тарттырып хәрәкәткә китерелә. Ул үзенең угы белән якын аралыкта ике дюйм калынлыктагы тактаны тишеп чыга. Атыла торган таш ядрәнең авырлыгы 60-80 кг булып, 360 метрга кадәр барып җиткән. Әлеге туп саклану корылмаларын, ату машиналарын, дивар сакчыларын юк итү өчен кулланылган. ■

ФЕВРАЛЬ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында

● Февраль аенда галим Булат Лирон улы Хәмидуллинның «...Окаянная дщерь Златой орды...»: очерки и историографические заметки по истории Золотой Орды и Казанского ханства» (Казан, Татарстан китап нәшрияты) дигән китабы дөнья күрде.

● 1 февральдә «ТНВ» каналы бинасында бер төркем драматурглар татар ситкомы турында сөйләшүгә җыелды. Чарада, драматурглардан тыш, канал җитәкчеләре И.Әминев белән А.Сибагатуллин да катнашты.

● 6 февральдә Казанның элекке Матбугат йорты бинасында – хәзерге «Ногай» кунакханәсендә Татарстан Республикасының халык язучысы Рабит Батулланың 10 томлыгын тәкъдим итү чарасы узды.

● 7 февральдә Каюм Насыйри исемендәге музейда, күренекле мәгърифәтче галимебезнең туган көнен искә алу уңаеннан, аның замандашы булган олуг фикер иясе, дин һәм җәмәгать эшлеклесе Шиһабетдин Мәрҗанигә багышланган әдәби-мәдәни кичә үткәрелде. Анда «Безнең мирас» журналының баш редактор урынбасары, язучы Фирдәвес Зариф, ТР Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге тарих институтының фәнни хезмәткәре, фәлсәфә фәннәре кандидаты Айдар Хәйретдинов, «Апанай» мәчетенең имам хатибы, тарих фәннәре кандидаты Нияз хәзрәт Сабиров, мөнәҗәт әйтү остасы Динар Шәймәрданов катнашты һәм чыгыш ясады.

● 8 февральдә күренекле галим һәм җәмәгать эшлеклесе Индус Таһиров «ТАТМЕДИА»ның конференц-залында баш мөхәррирләргә лекция укыды.

● 8 февральдә танылган меценат, Ульяновск өлкәсенең Иске Кулаткы районы башлыгы, Бөтендөнья татар конгрессы президиумы

һәм Милли Шура әгъзасы, татар халкының милләтпәрвәр улы Эдуард Ганиев вафат булды. 9 февраль көнне ул Сарытау өлкәсенең Усть-Курдем авылындагы татар зиратында җирләнде.

● 9 февральдә Лаеш районының Кече Елга авылы мәдәният йортында Кече Елга халык театры язучы-драматург Ләбиб Леронның «Иман» драмасына нигезләнгән спектакль премьерасын күрсәтте. Тамашаны автор үзе дә карады һәм кечеелгалылар уеныннан канәгать калды.

● 12 февральдә Әмирхан Еникинең тууына 110 ел тулуга багышланган тантаналы кичә булды. Сценарийның авторы – Ркаил Зәйдулла, режиссеры – Илдар Хәйруллин.

● 13 февральдә Татарстан Язучылар берлегендә Халыкара «Муса Җәлил укулары» бәйгесе үтте. Жюри әгъзалары К.Идрисова, Р.Аймәт, И.Абдулла булган әлеге чарада М.Җәлил исемендәге премия лауреатлары Ләбиб Лерон, Рәмис Аймәт һәм Луиза Янсуар җәлилчеләргә нисбәтле чыгыш ясады.

● 15 февральдә «ТАТМЕДИА»да танылган фотограф Рамил Галиевнең шәхси күргәзмәсе ачылды. Анда «ТАТМЕДИА» АҖнең генераль директоры Андрей Кузьмин чыгыш ясады.

● 15 февральдә Мөслим районы мөхтәсибе Габделкәрим хәзрәт Моратов юл һәлакәтендә фаҗигале рәвештә вафат булды.

● 17 февральдә Казанның К.Насыйри исемендәге урамының 26 нчы йортында бер төркем зыялылар Татарстанның халык язучысы Мөсәгыйт Хәбибуллинны искә алды.

● 18 февральдә Самара өлкәсенең Камышлы районында «Безнең мирас» журналы хезмәткәрләре – баш мөхәррир Ләбиб Лерон белән җаваплы мөхәррир Ленар Гобәйдуллин район хакимияте башлыгы Рафаил Камил улы Баһаутдинов белән очрашты.

● 19 февральдә «Безнең мирас» журналы хезмәткәрләре Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты рәисе Илфат Шәйдуллин һәм Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты рәисе Ринат Фәсәхов белән очрашып, журнал хакында эшлекле сөйләшү алып барды.

● 21 февральдә Арча районы хакимияте башлыгы Илшат Нуриев районда туып үскән язучыларны, журналист һәм сәнгать әһелләрен кабул итте.

Мирасворд

Төрки каганлыкның башында торган ыру

Алдан бара торган гаскәр (бор.)

Мактау шигыре

Актриса ... Җиһаншина

Шагыйрь ... Рәхмәт

... Шагыйрьҗан

Рафис Корбан романы

«Әлдермештән Әлмәндәр»дә Равил Шәрәфи башкарган роль

Сьерра - ... (Африкадагы ил)

Сүз төркеме

Рус рәссамы, Иван Айвазовскийның укытучысы

Конус рәвешендәге печән кибәне

Мәшһүр немец шагыйре

Металлдан эшләнгән очлы түбәле борынгы хәрби баш киеме

Борынгы грекларда халык җыелышы

Көйгә салынган шигъри әсәр

Аксыл кызыл

Аллага якын, изге кеше (иск.)

Арагон, Пастер

Совет истребителе

... Бәширов

Иоганн Себастьян ...

... мылтыгы

Артист Наил ...

Күренекле рус әдибе

Хан, би, дворяннарның ир баласын тәрбияләүче

Берәр илдә, өлкәдә, төбәктә яшәгән барлык кешеләр (иск.)

Әгъзамов, Бүләков

Дөньядагы иң мәртәбәле премия

Батыр сугышчы, рыцарь (иск.)

Моңарчы күрелмәгән, искиткеч хәл

Хатын-кызларның элекке бизәнү әйбере

... Коржавин (рус шагыйре)

Борынгы Спартада коллык хәленә төшерелгән крестьян

Амударьяның борынгы исеме

Фукс, Либкнехт

Ярослав Гашек романындагы солдат

Ашлык әрҗәсе

Борынгы Рим ораторы, язучы, шагыйрь

Теркәгеч

Чулманның сул кушылдыгы

2 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:

Сулдан уңга: әдрәс, «Дуга», Мәүла, вафа, кәнтәк, легат, шор, Оки, әвернә, утрак, Алисә, оран, Лец, арека, ипи, рамс, Найроби, Юныс, Федор, колаша, Лорка.

Өстән аска: Вәлиуллин, чура, Апе, Гораций, «Карасакал», Тики, Софокл, Сөмбел, әләшә, Аида, Әлменов, ар, ошак, Роберт, юра, «Рәүфә», Рейн, Кончак, Суар, Наис.

Рәис Габдулла төзеде.

Безнең мирас №3 март 2019

Әлмәт татар дәүләт драма театры бинасы

«Безнең мирас»
елъязмасы /март

150 ел элек (1869)

Язучы, педагог Мәхбүбҗамал Акчурина (1869-1948) туа.

135 ел элек (1884)

Актер, режиссер, татар профессиональ театрына нигез салучыларның берсе, Хезмәт Батыры Ильяс Батыргәрәй улы Кудашев-Ашказарский (1884-1942) якты дөньяга аваз сала.

130 ел элек (1889)

Күренекле тәнкыйтьче, әдәбият галиме, педагог Габдрахман Гайнан улы Сәгъди (Сәгъдиев, 1889-1956) туа.

125 ел элек (1894)

Революция хәрәкәтләре эшлеклесе Камил Лотферахман улы Якубов (1894-1919) дөньяга килә.

95 ел элек (1924)

Татар балалар журналы «Ялкын»ның беренче саны чыга.

90 ел (1929)

Советларның VII Чаллы кантон съезды ачыла.

80 ел элек (1939)

Казанда «Элекон» фәнни-җитештерү берләшмәсе оештырыла.

75 ел элек (1944)

Әлмәт күчмә театрына нигез салына (1985 елдан – Әлмәт татар дәүләт драма театры).

*Журналга **Лəбиб Лерон** əзерлəде.* ■

СОДЕРЖАНИЕ. МАРТ 2019

И останется в мире слово моё…: Анвар Давыдов.

Историческое наследие: «Всеобщая история тюркских народов». Х.Габаши**;** «Род Тарджеман-аль-Анджераи». А.Назми; «Татарские печатные машинки»; «Донские казаки и татары». И.Газизуллин.

Татарский мир: «Артист Буинского театра Ильфир Султанов: «Наше место работы – это мир».

Религиозное наследие: «Исламский мир». Габдурашит Ибрагимов.

Литературное наследие: «Первая жена моего знаменитого мужа»; «Стихотворения Гусмана Сады»; «Сююмбике». О.Иванова.

В глубине памяти: «Амирхан ага в моем сердце». А.Файзрахманов; «Афганский дастан» (отрывок из повести). М.Закир; «До сих пор в памяти!».

Художественное наследие: «Древние татарские музыкальные инструменты». Р. Гилязев; «Годы, взрастившие крылья надежды…».

Слово – украшение языка: «Путешествие в страну слов» (лингвистические рассказы). Г. Рахим.

На страже памяти: «Национальная библиотека Республики Татарстан».

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

CONTENT. FEBRUARY 2019

There will be left my word in the world…: Anvar Davydov.

Historic heritage: «General history of Turkic people» by Kh. Gabashi; «The kin of Tardjeman-al-Andjerai» by A.Nazmi; «The typewriters of the Tatars»; «The Don Cossacks and the Tatars» by I. Gazizullin.

Tatar world: «Ilfir Sultanov, the actor of the theatre of Buinsk: «The world is our working place».

Religious heritage: «Islamic world» by Gabdurashit Ibragimov.

Literary heritage: «The first wife of my prominent husband»; «The poems of Gusman Sada»; «Suyumbike» by O.Ivanova.

In the deepest store of memory: «We are still missing Amirkhan aga» by A. Fayzrakhmanov; «Afgan poem (narrative passage)» by M. Zakir; «Still keeping in the memory, still keeping!».

Creative heritage: «The ancient Tatar national musical instruments» by R.Gilyazev; «The years raised wings of hope…».

Word is a decoration of language: «The voyage to the words' world (liguistic stories)» by G. Rakhim.

On the guard of the memory: «The National library of the Republic of Tatarstan».

The magazine constantly brings to light all the most important events of our nation's life.

«Кырчы». 1954. Киндер, майлы буяу

«Совет хакимиятенең беренче еллары». 1967. Киндер, майлы буяу

Лотфулла Габделман улы Фәттахов

«Язгы рәссамнар». 1962. Киндер, майлы буяу

«Авыл хат ташучысы». 1959. Киндер, майлы буяу

АЛДАГЫ САНДА УКЫГЫЗ:

Әлфия Авзалова – Мәләкәстә.
(Рауза Хуҗиәхмәтова «Иске альбом хатирәсе»).

Татарлар Грузияне дә коткарган. Айрат Галимҗанов
Экспедиция көндәлекләреннән. Миркасыйм Госманов
Галимнең ике җиңүе. Фоат Садриев
Иске альбом хатирәсе. Рауза Хуҗиәхмәтова
Хатларда – юллар, юлларда – еллар. Назыйм Мәхмүтов
Татар сандугачы. Әгъзам Фәйзрахманов
Күршем Хәсән Сарьян. Фәйрүз Якупов
Германия төшемә керде. Гөлфия Дәүләтшина

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
журналына башкача язылу:
• ***uslugi.tatarstan.ru*** *сайты ярдәмендә*
• *редакциядә*
• ***podpiska.pochta.ru*** *сайты ярдәмендә*
электрон версия

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – П2343
РОССИЯДӘ – П7074
www.beznenmiras.ru

4 612750 670172

«БЕЗНЕҢ МИРАС» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» кибетеннән (Бауман ур., 19 һәм 29/11), «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.

№02 /2010